www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 8 (1373) 4 март 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga


11

Милләттәшебез Шакир Гыйниятуллин Бөек Ватан сугышын генерал дәрәҗәсендә каршылап, армия штабында зур хезмәт куя.

12

«Әлмәт театрында артист булырга хыялланмаган бердәнбер артисттыр мин», – дип шаярта кайчак Татарстанның атказанган артисты Римма Гайсина.

24

Түбән Камадан Гөлнара Мәҗитова әзерләгән татар бию күлмәкләре жете төсләре, матур бизәкләре белән сокландыра.

И сез, энҗе бөртекләре безнең, Тарихлардан гүя килгәнсез!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● «Мәдәни мохит» федераль проекты кысаларында Татарстанда ун объект, шул исәптән Түбән Камада Яшь тамашачы театры, төзеләчәк, реконструкцияләнәчәк һәм капиталь ремонтланачак, «Мәдәният һәм туризмны үстерү» программасы нигезендә Чаллыда «Мастеровые» театры төзелеше дәвам итәчәк.

● Түбән Кама шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр берләшмәсе игълан иткән Разил Вәлиев елы кысаларында «Киң колачлы иҗат» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция оештырылды.

● Башкорт дәүләт педагогика университетының «Ана теле – 2022» XIV Бөтенроссия педагогик осталык бәйгесендә КФУның Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе студентлары – Илзирә Галимбикова һәм Айгөл Габделхакова икенче урын алды.

● Ульяновск өлкәсе Чардаклы районы Үрән авылында модельле китапханәгә СССРның, РСФСРның, ТАССРның халык артисты Габдулла Шамуков исемен бирәчәкләр.

● Самарада III «Мирас» Халыкара татар мәдәнияте фестиваль-бәйгесендә катнашу өчен гаризалар кабул итела.

● Казанның «Мир» кинотеатрында документаль кино көннәре узды, тиздән алар республика районнарында да үтәчәк.

● Анкара Медиполь университеты лекторы, социология фәннәре кандидаты Хаҗы Мурат Тәрзинең «Россиядә мультикультурализм һәм татар тәңгәллеге» дип исемләнгән китабы дөнья күрде.

● Нократ Аланы шәһәрендә татар мәдәниятенә багышланган «Киләчәккә караш» бишенче ачык форумы узды.

Мәдәни җомга
4 март
№8, 2022

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Заһир ХӘКИМОВ, Башкортстан татарлары конгрессының Башкарма комитеты рәисе:

«Минем балалар ни өчен телне ипи-тозлык кына белә? Алар татар теле нәрсәгә кирәк, мин аны кайда файдалана алам диләр. Миңа аларга дәлил табуы бик авыр. Чөнки мохит юк. Телне файдалану шартлары юк. Татар телендә телетапшырулар, курчак театрлары булмау да мохитне тарайта. Дөрес, «Нур» театрында ара-тирә балалар өчен тамашалар була. Ләкин бу гына җитәрлек түгел».

СЫНАМЫШЛАР

Яз иртә килсә, ашлык уңар ● Мартта яуган кар – бакча җимешенә бик ярар ● Мартта җир өстендәге салам карга эреп керсә, бер айдан кар китәр ● Язын кар кояш каравы белән эресә, бодай яхшы булыр ● Әгәр карга көньяктан ябыгып кайтса, ашлык уңар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 27 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 23 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 56 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **33 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **11 мартта 11 сәгать 29 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

4 март – шагыйрә, журналист, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киң мәгълүмат хезмәткәре Фәния Равил кызы Габидуллинага 65 яшь (1957).

6 март – композитор, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мансур Әхмәт улы Мозаффаровның тууына 120 ел (1902-1966).

8 март – язучы Үзбәк Газиз улы Саттаровның тууына 100 ел (1922-1982).

9 март – композитор, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рим Мәхмүт улы Хәсәновка 75 яшь (1947).

10 март – язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Азат Фатыйх улы Вергазовның тууына 90 ел (1932-2012).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 4 март.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(2-10 март)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 1 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ

Кеше капиталы һәм хезмәт базары



Белгечләр раславынча, кеше капиталы – икътисади үсешнең иң мөһим ресурсы. Хәзерге үсеш баскычларының үзенчәлекләре әлеге ресурсның әһәмиятен арттыра, аны беренче дәрәҗәгә күтәрә. Кеше капиталы дигәндә кешеләрдәге сәләт, белем, осталык кабул ителә, алар ярдәмендә социаль һәм икътисади уңайлыклар булдырыла.

Кеше капиталын барлыкка китерә торган төп факторларны белем һәм һөнәрен әзерлек тәшкил итә. Шулай ук аларга куллану дәрәҗәсен, яшәү сыйфатын, медицина хезмәте күрсәтүне һ.б. факторларны кертеп карыйлар.

Татарстанда икътисади яктан актив халык саны 2 миллион 56,7 мең кеше, ягъни республика халкының 53,8 процентын тәшкил итә. Аларның 1 миллион 975,9 меңе икътисад өлкәсендә шөгыльләнә, 80,8 мең кеше хәзергә эшләми, әмма актив рәвештә эш эзли.

Республика хезмәт базарындагы вәзгыять чагыштырмача тотрыклы. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм программасы чараларын гамәлгә ашыру эшсезлекне киметүгә зур ярдәм итә. Иң зур эшсезлек Кама Аланы бистәсендә. Халыкның 3,58 проценты эшсез. Яшел Үзәндә халыкның – 2,32, Алабуга – 1,28, Менделеевта 1,04 проценты эшләми. Ел дәвамында республиканың эш белән тәэмин итү хезмәтенә 182,3 мең кеше мөрәҗәгать иткән. Шуларның 47,5 меңе эшкә урнаштырылган.

Республикада инвалидларны эшкә урнаштыру өчен 472 җиһазландырылган эш урыны булдырылган. Аларның 47 процентына ел дәвамында эш табылган. Алдагы елларга Татарстанда икътисадны үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә ихтыяҗ булган белгечлекләрнең исемлеге расланды. Анда 442 һөнәр һәм белгечлек кертелгән.

Коронавирусның озакка сузылуы да хәлне нык авырайтты. Шуны исәпкә алып, киеренкелекне киметүгә юнәлтелгән өстәмә чаралар программасы эшләнде. Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында һөнәр берлекләре федерациясе, эш бирүчеләр берләшмәләренең координацияләү советы һәм Министрлар Кабинеты арасында төзелгән килешүләр яшәү дәрәҗәсен күтәрү буенча мөһим адым булды. Аның нигезендә республика бюджеттан тыш секторы оешмалары өчен минималь хезмәт хакы аена кимендә 6420 сум күләмендә билгеләнде.

Социаль көндәшлек кысаларында башкарыла торган эш, социаль хезмәт өлкәсендәге четерекле мәсьәләләр турында фикер алышулар, алар буенча карарларны үз вакытында кабул итү социаль тотрыклылык саклануның төп сәбәбе булып тора. Татарстан һөнәр берлекләре федерациясе, эш бирүчеләр берләшмәләренең координацияләү советы һәм Министрлар Кабинеты арасында социаль партнерлыкны үстерү турында чираттагы килешү имзаланды.

Соңгы еллар хезмәтне саклау һәм аны оештыру өчен шартлар тудыру өлкәсендәге җитди үзгәрешләр белән истә кала. Хезмәт шартлары махсус бәяләү гамәлләре системасы кертелде. Производствода имгәнү күрсәткечләре буенча тискәре якка бара торган динамика туктатылды. Эш вакытында һәлак булучылар саны беркадәр кимеде. Республикада эш урыннарында хезмәт шартларын махсус бәяләү системасы кертелде. Мондый гамәл 58 меңнән артык эш урынында уздырылды. Ел дәвамында хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча 40 мең кеше укып чыкты.

Хезмәт һәм белем бирү тармакларын җайга салу максатларында республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан икътисад тармакларының кадрлар әзерләүдәге ихтыяҗына җыелма фараз төзелде. Елына 37 меңнән артык белгеч кирәк дигән фикергә киленде. Алардан 32 процентка якыны - эшчеләр. Урта һөнәри белем белән кешеләрнең 34 процентка якыны, калганнары югары белемле.

Шәһәр хуҗалыгы һәм транспорт, хезмәт күрсәтү өлкәсе, төзелеш, агросәнәгать комплексы тармакларында шул исәптән төзү һәм агач-балта эшләре мастеры, түбә ябучы, универсал тимерче, слесарь, эретеп ябыштыручы, шәһәр электр транспортын йөртүче, җиһазларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер, сатучы, контролер-кассир, торак-коммуналь хуҗалыгы мастеры, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче трактор-машинистлар, пешекчеләр, кондитерлар һ.б. һөнәрләр буенча кытлык бар.

Урта һөнәри белемле белгечләр арасыннан шәфкать туташлары, биналар һәм корылмалар төзүчеләр, алардан файдаланучылар, эчке сантехниканы көйләүчеләр, автомобиль юллары, аэродромнар, шәһәр төзелеше архив эшчәнлеге, мәктәпкәчә белем бирү, урман-парк хуҗалыгы кадрларына ихтыяҗ зур.

Югары белемле кадрлардан транспорт технологиясе өчен җаваплы затлар, архитектура, шәһәр төзелеше, информатика һәм хисаплау техникасы, машина төзелеше, металлургия, җылылык энергетикасы, финанслар һәм кредит, педагогик белем бирү, сатучылык, дәвалау юнәлешләре буенча белгечләр кирәк.

Татарстан Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы икътисадының кадрлар әзерләүдә ихтыяҗын фаразлау, югары, урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә дәүләт заказын булдыру регламентын раслау турында" карары кабул ителде. Аның нигезендә республикада икътисад кадрларын әзерләү ихтыяҗын фаразлау, дәүләт заказын булдыру системасы үзгәрә.

Элекке системадан аермалы буларак, хәзер инвестиция җәлеп итүчәнлекнең стандартлары таләпләренә бәйле рәвештә, фаразлау чоры 3 елдан 7 гә кадәр артты, шулай ук кадрлар фаразы эшенә эре предприятиеләр генә түгел, ә җирле үзидарә органнары җаваплылыгындагы кече һәм урта бизнес предприятиеләре дә җәлеп ителә. Әлеге эшнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен автоматлаштырылган махсус система эшләнде.

Фаразны булдырганда предприятиеләрне үстерү перспективалары, яңа эш урыннары булдыру, табигый кимү һәм штатлар кыскартуга бәйле рәвештә хезмәткәрләрнең китүе, чит ил эшче көчләрен алыштыру исәпкә алынды.

Кадрлар әзерләүгә дәүләт заказын булдыру механизмын камилләштерү максатларында Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан республика икътисадының өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган ихтыяҗ булган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеге ел саен яңартыла.

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" федераль закон нигезендә бюджет акчалары исәбеннән укытуга кабул итүнең контроль саннары мәгариф оешмалары конкурсы нәтиҗәләре буенча бүленергә тиеш.

Дәүләт акчалары булган мәгариф оешмалары арасында Татарстан бюджеты акчалары исәбеннән урта һөнәри һәм югары белем уку-укыту программалары буенча укыту өчен гражданнарны һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре буенча кабул итүнең контроль саннары мәгариф оешмаларының конкурс нәтиҗәләре буенча бүленергә тиеш.

Дәүләт теркәве булган мәгариф оешмалары арасында республика бюджеты акчалары исәбеннән укыту өчен гражданнарны һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс уздыру тәртибе республика хөкүмәте тарафыннан раслана.

Максат – урта һөнәри һәм югары белем уку-укыту программалары буенча кадрлар әзерләүгә республика дәүләт заказын гамәлгә ашыру өчен мәгариф оешмаларын сайлап алу һәм укытуга гражданнар кабул итүнең контроль саннарын үзара бүлешүдән гыйбарәт. Конкурсны республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы оештыра.

Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә Татарстанның өч һөнәри белем бирү оешмасына – Бөгелмә машина төзелеше техникумына, Алабуга политехника һәм Түбән Кама нефть химиясе көллиятләренә федераль инновацион мәйдан статусы бирелде.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Джаз җырларын өйрәнер өчен

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Лидия Әхмәтованың «Джазлы Казан» дип аталган ноталар һәм романслар җыентыгын тәкъдим итү кичәсе булды.

«Балачактан ук күңелемдә көйләр туа иде, мин аларны үз-үземә көйләп, җырлап йөрдем. Музыка училищесын тәмамлап, Казан дәүләт консерваториясендә белем алгач, музыканы нотага салырга өйрәндем. Профессиональ җырчы буларак, репертуар да тупларга кирәк иде. «Галәм кызы» дигән беренче җырымны Гөлшат апа Зәйнашева сүзләренә яздым», – диде җырчы.

Татарстан филармониясенең джаз-оркестры директоры Л.Әхмәтова үзенең җыр һәм романслар җыентыгын профессиональ иҗат эшчәнлегенең 30 еллыгына багышлаган. Китапка композиторның 41 әсәре тупланган. Ул Фәнис Яруллин, Роберт Миңнуллин, Флера Тарханова, Гәрәй Рәхим, Разил Вәлиев кебек шагыйрьләрнең шигырьләренә көй язган.

Җыентыкның музыкаль редакторы Ильяс Камал җырларның профессиональ һәм гади, аңлаешлы иҗат ителүен билгеләп үтте. «Дуслыгыма» дигән җырның сүзләрен композиторның коллегасы – Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев язган. «Лидия белән дуслыгыбызга 40 ел булды. Дуслык хакына җыр язарга тәкъдим итте. Шигырьне болай гына язып булмый, ләкин дуслык диюгә миңа илһам килде», – диде ул.

«Казанда джаз яши һәм ул һаман үсештә. Джаз оркестры бүгенге көндә барлык концертларыбызны бизи. Лидия Әхмәтова илебез музыка мәдәнияте һәм педагогикасының алдынгы казанышларын Татарстан филармония джаз оркестры эшчәнлегенә зур осталык белән кертә бара»,– диде филармония директоры Кадим Нуруллин.

«Джазлы Казан» ноталары җыентыгы, вокал башкару сәнгатенә ярдәм итү һәм аны үстерү өчен, Татарстанның музыкаль белем бирү учреждениеләренә бүләк ителәчәк.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Җиңүче рәссамга – 200 мең сум

Татарстанда рәсем сәнгате һәм сәнгать белеме өлкәсендәге иң абруйлы бәйгеләрнең берсе – Бакый Урманче исемендәге премия 2003 елдан бирле оештырыла. 2009 елдан башлап, премия ике елга бер тапшырыла. Элегрәк бәйгене декабрьдә игълан итеп, рәссамның туган көнендә – 23 февральдә нәтиҗә ясасалар, быел – 23 февральдә игълан иттеләр.

Бәйгегә эшләр 1 марттан 1 апрельгә кадәр кабул ителәчәк. Аңа соңгы өч елда иҗат ителгән әсәрләрне юлларга мөмкин. Бу хакта Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә хәбәр итте.

«Без быел Бакый Урманче исемендәге премиянең акчалата бүләген арттырдык. Биш номинациядә һәр җиңүче 200 мең сум акча алачак», – диде Дамир Натфуллин. 2017 елда җиңүчеләргә 100 мең сум бирелгән.

Министр урынбасары башка төбәкләрдә иҗат итүче профессиональ рәссамнарны, сынчыларны, сәнгатьне өйрәнүчеләрне дә бәйгедә катнашырга чакырды.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова жюри әгъзалары бәйгегә килгән эшләрнең, беренче чиратта, миллилегенә игътибар итәчәген белдерде.

«Әсәрләр хәзерге көн сәнгате таләпләренә дә туры килсен, милли образлар да булсын. Рәссам үзенең осталыгын да күрсәтергә, милли тормышыбызны да яктыртырга тиеш. Без монда шундый ике яклы максатны күздә тотабыз», – диде галимә.

Жюри номинантлардан шорт исемлек төзи һәм билгеләнгән әсәрләрдән күргәзмә ясала. Жюриның икенче утырышында язылган рецензияләр, экспертлар фикере һәм матбугатта чыккан язмалар буенча фикер алышына.

Рифат КАЮМОВ.

Театрлар дөньясында

Чаллы шәһәрендә үтә торган гастрольләре кысасында Камал театры артистлары Әзһәр Шакиров, Илдус Әхмәтҗанов, Миләүшә Шәйхетдинова, Эмиль Талипов М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназиясендә иҗади очрашу уздырды. Артистлар һөнәри осталыкларының серләре белән уртаклашты, иҗат юлларының ничек башлануы хакында сөйләде.

Гастрольләр алдыннан гына «Адымнар» полилингваль комплексында Камал театры оркестры «Күңелле классика - безнекеләр!» проектын ачып җибәрде. 700дән артык бала С. Сәйдәшев, Р.Яхин, Р.Еникеев, Э.Низамов, Моцарт һәм Бетховен әсәрләре белән танышты.

Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры Гомәр Мәрдәнов исемендәге театраль фестивальгә старт бирде. Фестиваль район мәктәп укучылары арасында үткәрелә. Вәкаләтле жюри – спектакльләрне карап, бәяләгәннән соң җиңүче мәктәпнең спектакле 19 мартта Әтнә татар дәүләт драма театры сәхнәсендә тамашачыларга тәкъдим ителәчәк. Әлеге фестиваль белән Әтнә театры легендар режиссеры, Марсель Сәлимҗанов исемендәге беренче Республика премиясе лауреаты Гомәр Мәрдәновның исемен мәңгеләштерә.

Минзәлә театры А.С.Пушкинның «Кечкенә трагедияләр» әсәре буенча «Хәтәр мәҗлес» драмасын чыгарды. «Пушкинның 1870 елда язылган «Пир во время чумы» әсәренең бүген дә ни дәрәҗәдә актуальлеген күрәбез», – диде премьераны карарга килгән Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Бердәм Россия» партиясенең «Кече ватан мәдәнияте» проектының Татарстандагы кураторы Людмила Рыбакова.

М.Гафури исемендәге Башкорт академия драма театры Ризаэтдин Фәхретдин китабы буенча беренче спектакль куя. Бу көннәрдә театр сәхнәсендә Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Әсма» спектакленең премьерасы була. Спектакльнең инсценировкасын Шәүрә Шәкүрова иҗат иткән.

Тинчурин театры «Умай» лабораториясендә язылган эскизлар буенча опера спектакльләре әзерләп репертуарга кертергә планлаштыра. Умай хатын-кыз алиһәсе исеме белән аталган лабораториянең максаты — татар телендә өч кыска камера операсы булдыру. Оештыручылар феминистик дип атаган лабораториядә шагыйрьләр Лилия Гыйбадуллина, Эльвира Һадиева, Миләүшә Гафурова, драматурглар Энҗе Гыйззәтова, Динә Сафина катнаша. Алар белән шагыйрә Йолдыз Миңнуллина һәм Энҗе Дусаева кураторлык итә. Спектакльләр татар хатын-кызының татар мәгърифәтенә, тарихи үзгәрешләргә керткән өлешенә багышланган.

● «Ул әле өйләнмәгән иде» спектакле күренеше.

Әлмәт театрында Гаяз Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәре буенча спектакль тәкъдим ителде. Режиссер Айдар Җаббаровның бу спектакле Камал театрында куелган «Тормышмы бу?» спектакле белән башланган Исхакый циклын үстерә. Режиссер бу драмасында катнаш никахлар һәм милли үзаң темасын күтәрә, сораулар куя һәм җавап эзли.

Казан «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә «Апуш» балалар татар театр студиясенә кастинг узды. Анда башкаладан, Лаеш, Балтач, Арча районнарыннан 9-15 яшьлек 100 гә якын бала катнашты. Аларның сәләтен «Сәйдәш» мәдәният үзәге сәнгать җитәкчесе Лима Кустабаева, театр актеры, «Апуш» студиясе җитәкчесе Алия Фәйзрахманова, театр актеры Резедә Сәләхова, вокал буенча педагог Лилия Зәйнуллина, театр актеры, җырчы, музыкант Ильяс Фәйзрахманов бәяләде.

Яшь артистлар педагоглар белән бергә татар телендә спектакльләр әзерләячәк, шулай ук осталык дәресләрендә катнашачак. Беренче спектакльне балалар 1 июньдә күрсәтәчәк.

Түбән Кама татар дәүләт театры Татарстанның атказанган артисты Наил Сәйфетдиновны соңгы юлга озатты. Театрның җырчы, гармунчы артисты 60 яшендә вафат булды.

«МОҢ» театраль мәйданчыгында чыккан «Педсовет» спектакле «Алтын битлек» фестиваленең конкурстан тыш балалар программасы кысаларында Мәскәүдә күрсәтелә. Оештыручылар программада документаль театрның аерым урын алып торуын ассызыклый. Әлеге спектакльдә укытучылар катнаша – алар сәхнәгә чыгып укыту системасындагы проблемалар турында сөйли. Эскизда катнашкан 13 укытучы арасында Ләйлә Хәбибуллина – Казан мәктәпләренең берсендә татар теле укытучысы. Аның дүрт минутлык текстында татар теле укытучысының соңгы дүрт елы сурәтләнә.

1 нче биттә – журналист Эльза Газизова кызы Латыйфә белән «Тат-аватар» проекты кысаларында Сөембикә һәм аның улы Үтәмешгәрәй образында.

Ш.Камал премиясе тапшырылды

Татарстан Мәдәният министрлыгы, Милли музей, Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры (Татар китабы йорты) тарафыннан яшь иҗатчылар арасында булдырылган Шәриф Камал исемендәге республикакүләм әдәби премиягә йомгак ясалды. Татар китабы йортында «Чәчмә әсәр» һәм «Әдәби тәрҗемә» номинацияләрендә җиңүчеләр тантаналы шартларда игълан ителде.

Бәйге Ш.Камалның әдәби мирасын популярлаштыру, чәчмә әсәр иҗат итүче талантлы яшь авторларны барлау, аларны әдәби эшчәнлек белән тагын да кызыксындыру, кече жанрларны үстерү максатыннан үткәрелә. Шул ук вакытта ул остазлык мәктәбе дә булып тора, яшь авторлар өчен киләчәккә юл ярырга ярдәм итә торган башлангыч, әдәбият аксакалларыннан дәрес алу мөмкинлеге дә.

Быел «Чәчмә әсәр» номинациясенә – 18, «Әдәби тәрҗемә» номинациясенә 34 эш кабул ителгән. Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев чәчмә әсәрләр арасында хикәяләр өстенлек итүен, яшьләрнең туган телгә мәхәббәт белән язуларын, иҗаталарында телнең нечкәлекләрен ачарга, камилләштерергә омтылуларын искәртте. «Конкурсның яшьләрнеке булуы сөенечле», – диде ул. «Әдәби тәрҗемә» номинациясенә рус, төрек, инглиз, алман, гарәп, белорус, украин, испан, корея, япон теленнән тәрҗемә эшләре килгән. КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр һәм Көнчыгышны өйрәнү югары мәктәбе деканы Эльмира Хәбибуллина быелгы тәрҗемә эшләренең тирәнрәк, камилрәк булуына игътибар иткән.

Ш.Камал премиясенә «Чәчмә әсәр» номинациясендә Айзилә Абдрахманованың үсмерлек якын кешесен югалтуы турындагы «Нихәл, әнкәй?» дигән хикәясе җиңүче дип игълан ителде. Кайбыч районы Борындык авылында туып-үскән кыз иҗат белән сигез яшеннән шөгыльләнә башлаган. Ул хәзер КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институтының беренче курсында белем ала. «Әдәби тәрҗемә» номинациясендә җиңүче исеменә КФУның Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбендә инглиз һәм алман телләрен өйрәнүче Лилия Муллагалиева лаек булды. Ул Ш.Камалның «Сукбай» хикәясен алман теленә тәрҗемә иткән. Чаллыда туып-үскән кызга Алманиягә барып ел ярым укып кайтуы бу телне белүен камилләштерергә ярдәм иткән. А.Абдрахманова һәм Л.Муллагалиева традиция буенча Ш.Камалга Дәрдемәнд бүләк иткән алтын каләм белән, язучының кәнәфиенә утырып, музейның истәлекле язмалар журналына хис-тәэсирләрен теркәп калдырды. Җиңүчеләрне Казан шәһәре Башкарма комитеты рәисе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, әлеге премияне гамәлгә кую идеясе авторы Луиза Янсуар, жюри әгъзасы, халык шагыйре Разил Вәлиев һәм Татар китабы йорты директоры Айдар Шәйхин котлады.

Сөембикә КАШАПОВА.

Журналистлар остазы китте

Татар җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде. Журналистика ветераны, филология фәннәре докторы, профессор Илдар Низамов вафат булды.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, республиканың атказанган фән эшлеклесе Илдар Малик улы Низамов 1936 елның 3 сентябрендә Әтнә районы Олы Бәрәзә авылында туа. Башкорт дәүләт университетын, КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый. 1957 елдан Уфа шәһәрендә яши: Агыйдел елга пароходчылыгында, «Кызыл таң» газетасында эшли. 1968 елдан Казанда «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә, Татарстан китап нәшриятында хезмәт куя. 1987 елдан Казан университетында белем бирә.

Хезмәтләре массакүләм аралашуда татар сөйләм системасы функциясенә, социолингвистикага карый. Журналистика теориясенә караган дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы. «Мәхәббәт хакы», «Бер карадым ...» дип аталган хикәя һәм повесть җыентыкларын бастыра. Газета-журналларда бик күп мәкаләләре дөнья күрә. И. Низамов «Мәдәни җомга» газетасының да даими авторы булды, күп еллар дәвамында «И Туган тел!» кушымтасын алып барды.

Гомеренең соңгы елларында галим Әтнә районында яшәде. Аның җәсәде шушы районның Чишмәле Сап авылында җир куенына иңдерелде.

Милли сәнгатебез сагында

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, профессор Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор музыкасы дәүләт ансамбле «Туган телем – татар теле» исемле проект белән республикабызның егермегә якын төбәгендә чыгыш ясады. Бу концерт-кичәләрдә ансамбль белән татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның «ТАТАР СҮЗЕ» халыкара бәйгесе лауреатлары: Фәннур Мөхәммәтҗанов, Ришат Әхмәдуллин, Резеда Сәлахова, Данис Хисмәтуллиннар да күренекле татар шагыйрьләренең шигырьләрен башкара, һәм әле дә бу концертлар дәвам итә.

Күптән түгел алар «Үткәннәрне барлап» дип исемләнгән концерт программасы белән Түбән Кама шәһәрендә Халык иҗаты йортында чыгыш ясады. Республика күләмендә узган әлеге матур кичә «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе кысаларында үтте.

Кичәнең беренче өлеше А.Фәйзрахманов белән иҗади әңгәмә рәвешендә барды. Сәнгать остасы үзенең бай һәм күпкырлы иҗади эшчәнлеген җавап рәвешендә тамашачыга җиткерде, баянга кушылып татар халык җырларын, үзе язган җырларны башкарды, татар әдипләренең шигырьләрен сөйләде. Экран аның сәхнә эшчәнлегеннән төзелгән төрле сюжетлар белән яктыртылды. Кичәнең икенче өлешен А.Фәйзрахманов җитәкләгән Татарстан Республикасы фольклор музыкасы ансамбле гөрләтте, милли җәүһәрләр – фольклор әсәрләрен, җыр-биюләрен тамашачы көчле алкышларга күмде. Кичәнең азагында Түбән Кама шәһәре һәм муниципаль районы башлыгы Рамил Муллин А.Фәйзрахмановка һәм ансамбльгә рәхмәт сүзләрен һәм җылы теләкләрен шигъри юллар белән ирештерде:

«...Кайтты диләр, кабат кайтты,-
диләр,
Яшәде ул безнең күңелдә.
Тарихларда калган, онытылып барган
«Җидегән чишмә» сәхнә түрендә.
Җырлый Айдар, үзе баян уйный,
Бөтен җаннар моңга урала.
Онытылмаган, «Җидегән чишмә» исән,
Тыеп булмый күздән яшь тама.
Чиптери чишмә, аның җырларына,
Түзеп буламыни кул чапмый!».

Февральдә ансамбль Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә «Туган телем – татар теле» проекты кысаларында «Хәрәкәттә-бәрәкәт» концерт программасы белән Казан дәүләт медицина көллияте студентлары каршында чыгыш ясады. Милли сәнгатебез, Ана телебез сагында торучы иҗат коллективының киләсе концерты Саба районында планлаштырылган.

Алсу ХӘКИМОВА.

● Британия империясе таҗын 2868 алмаз, 273 энҗе, 17 зәңгәр якут, 11 зөбәрҗәт һәм 5 кызыл якут бизи.

● Байлар өчен махсус "Бугатти" чәйнеге чыгарыла. Аның термометры, дисплее, су күләме индикаторы, суның кайнау температурасын 45 тән 99 градуска кадәр көйләү җайланмасы, таймеры бар. Корпусы 8715 Сваровски кристаллы белән бизәлгән. 150 мең сумлык мондый чәйнеккә нинди су салалар икән?

● Diamond Armor ("Алмаз броня") – дөньяда иң кыйбатлы костюм. Швейцариянең Suitart фирмасында тегелгән әлеге тиңсез костюм 3 миллион 200 мең долларга бәяләнә. Ул бары тик шәхси заказ буенча гына тегелә, һәм аны айлар буе көтәргә туры килә. Костюм дым үткәрми, тән температурасын җайларга сәләтле һәм бер үк вакытта бронежилет та булып тора. Ул гомуми авырлыгы 140 карат булган, һәркайсының диаметры 4 миллиметрлы 600 кара бриллиант белән бизәлгән.

Кеше капиталы һәм хезмәт базары

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Андый статус бирелгән мәгариф оешмаларына төбәк бизнесы белән бергә эшләнгән инновацион уку-укыту программаларын булдырырга, белем бирүне хезмәт базарының заманча таләпләренә ныграк яраклаштырырга мөмкинлек тудырачак.

Булган барлык тәҗрибәне гомумиләштереп, республика предприятиеләрендә остазлыкны өйрәнү тәҗрибәсенә багышланган нигезләмә эшләнде. Республикада югары уку йортларыннан соң алынган белемне үстерү, әлеге өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү программасы тормышка ашырыла. Әлеге программа кысаларында икътисадның әйдәүче тармаклары өчен кирәк квалификацияле белгечләр әзерләүче ресурс үзәкләре төзелде. Шул исәптән П.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте – Россия Федерациясенең оборона-сәнәгать комплексының авиа һәм машина төзү өчен ресурслар үзәге, Чаллыдагы Кама дәүләт автомеханика техникумы автомобиль тәзелеше тармагы өчен кадрлар әзерләүнең ресурслар үзәгенә әйләнде. Түбән Камадагы нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы республиканың нефть химиясе комплексы ресурслар үзәге, Сарман аграр көллияте Татарстан авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләү үзәге вазифасын үти.

Матди-техник базаны һәм бюджеттан тыш эшчәнлекне үстерү максатларында һөнәри белем бирү оешмаларының бизнес проектлары конкурсы да уздырылды. Мәгариф оешмаларына конкурс нәтиҗәләре буенча икешәр миллион сумлык 5 грант бирелде.

Ресурслар үзәкләрен ачу буенча проектлар исемлеге дә расланды. Финанслау күләме кимендә 3 миллиард сум булган 25 заманча үзәк ачу планлаштырылды.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, һөнәри белем бирү системасын мәгълүматлаштыру чаралары комплексын гамәлгә ашыра. Төрле тармаклар буенча Татарстанның 15 пилот оешмасы билгеләнде.

Г.Тукай туунын 135 еллыгы – 2021 елның бер бизәге булды. Шул уңайдан 1914 елда «Мәгариф» нәшриятында 463 битлек булып дөнья күргән «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре»нең үзгәртелмичә, әмма Кирилл хәрефләрендә чыгуы әдәбият сөючеләр өчен икеләтә куаныч китергәндер. Басманы гарәп имлясыннан Кирилл хәрефләренә күчереп әзерләүче, идея, кереш сүз, искәрмәләр һәм аңлатмалар авторы – Г.Тукай әдәби музее директоры, филология фәннәре кандидаты Гүзәл Төхвәтова. Шушы көннәрдә ул әсәрнең Кирилл хәрефләрендәге варианты Тукай музеенда Казан җәмәгатьчелегенә тәкъдим ителде.

Тукай үзе туплаган җыентык

Белгәнебезчә, үзе исән чагында Тукайның юка гына китаплары нәшер ителә. Алар нибары 20-70 битле басмалар була. «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» җыентыгын әзерләү тарихы исә 1912 елның көзенә килеп тоташа. Бу уңайдан Г.Төхвәтова нашир Шәһер Шәрәф истәлеген искә төшерде. Ул шагыйрь Клячкин хастаханәсендә ятканда, вафатына 40 көн кала, аның янына барган. Ш.Шәрәф Г.Тукайның «Мәгариф» көтепханәсе тәкъдиме буенча, үзенең бөтен язган шигырьләрен бер тәртипкә китереп, «Мәҗмугаи асар» әзерләгән вакытына туры килә. Шул вакыт бәгъзе шигырьләрен бозып, төзәтеп утырган Тукай үзенең иҗатын «Яшьлек берлә әллә нәрсәләр язылган, кайсыбер шигырьләремне күрәсем дә килми» дип бәяли. Бу китапта, Г.Тукай үзе билгеләп узганча, «халкына калдырырга теләгән әсәрләре» генә тупланган. Тукай шигырьләрне урнаштыру тәртибенә нык игътибар бирә. «Үзенең әүвәлдәрәк, хосусән төрекләргә тәкълид берлә язылган шигырьләренең телен яратмаенча, шуларны бөтенләй мәҗмугадан төшереп калдырсам ничек булыр икән дип киңәшләште. Нәтиҗәдә ул шигырьләрне мәҗмуганың башларына куймый, урта бер йиренәрәк кертергә, һәрхәлдә, бөтен шигырьләрең язылу тарихларын гыйлавә итеп бастырырга карар бирелде», – дип яза Ш. Шәрәф.

Кирилл хәрефләрендә чыккан китапның фәнни мөхәррире, филология фәннәре кандидаты Эльмира Галимҗанова шагыйрьнең «Г.Тукай мәҗмугаи асаре»ндә басылган кайбер шигырьләренең куплетлары төшереп калдырылуына, ә беришенең строфалары үзгәртелгән булуына игътибар иткән. Галимә «Г.Тукай үзе исән

● **Гүзәл Төхвәтова.**

вакытта аның шигырьләрен кискәләп, бастырырга җөрьәт иткән кеше булыр иде микән», – дип, бу хәлнең дә басманы шагыйрьнең үзе әзерләп калдыруына дәлил булуын әйтте. Тукай музее директоры Г.Төхвәтова «Г.Тукай мәҗмугаи асаре» китабын әзерләгән вакытта «Туган тел» шигыренең үзгәртелгән варианты да булуын күргән. «Туган тел»нең беренче варианты тулы килеш «Балалар кыйсеме» өлешенә кертелгән. «Халык әдәбияты» әсәре дә «Туган тел» шигыре белән тәмамлана. Әмма биредә аның икенче дүртьюллыгы төшереп калдырылган һәм соңгы өлешендә «үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам» гыйбарәләре үзгәртелеп, «Ярлыкагыл дип, үземне, Әткәм-әнкәмне, Ходам», диелгән. «Мәҗмугада аерым бер сүзләрнең лексик-семантик яктан үзгәртелүе, синонимнары, гарәп-фарсы алынмаларының татар сүзләре белән алышынуы һ.б. күзәтелә», – диде Г.Төхвәтова.

Шулай ук, шигырьнең алтынчы юлы «Балалар күңеле»нең беренче басмасында «Кечкенәдән тышка чыккан шатлыгым, кайгым минем» дип, ә «Халык әдәбияты»нда «Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем» дип бирелгән булган.

Филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина Тукайның «Мәҗмугаи асар»е нәшер ителү ул заманда татар әдәбияты тарихында зур вакыйга булуын искәртте. Аңа кадәр бер генә язучы, шагыйрьнең дә күләмле әсәрләр җыентыгы басылмаган. Беренче булып әлеге эшкә нашир Гыйльметдин Шәрәф, шагыйрьнең үзен әсәрләр сайлауга җәлеп итеп, затлы рәсемнәр белән бизәлгән, темаларга бүленгән китап эшләүгә алынган. Мәҗмугаи әсәрләр «Җитди шигырьләр», «Көлке вә һөҗү кыйсеме», «Балалар кыйсеме» дигән өч темага бүлеп урнаштырылган. Болардан тыш «Шүрәле», «Халык моңнары», яңадан «Балалар кыйсеме», «Нәсер кыйсеме» дип аталган өлешләр дә бар.

Җыентык 1914, 1918 елларда – Казанда һәм 1933 елда Токиода басылып чыга. «Г.Тукай мәҗмугаи асаре» китабының фәнни мөхәррире Э.Галимҗанова басмалар арасында аермалар да шактый булуын ассызыклады. Әйтик, 1918 елгы басмада Җамал Вәлидинең кереш мәкаләсе шактый кыскартылган. Тукайның шигырьләре дә азрак бирелгән, бүлекләргә бүленеш тә үзгәртелгән, кайбер әсәрләр төшереп калдырылган. Гомумән, 1918 елгы басма 168 биткә кимрәк. «1914 елдагы басмада гына Тукай рухы бар һәм ул Тукай үзе төзеп калдырган җыентык дип әйтә алабыз, шуңа да ул басманың кыйммәте зуррак», – ди ул.

Тукай музее директоры Г.Төхвәтова китапның Г.Тукай үзе тәкъдим иткән, Җамал Вәлиди төзеп калдырган вариантын халыкка тәкъдим итү төп бурыч итеп билгеләнелүен әйтте. Яңа басмада бер генә шигырьнең дә урыны үзгәртелмәгән, алар арасындагы бизәкләр дә элекке рәвешендә кертелгән.

«Г.Тукай мәҗмугаи асаре» – татар китап графикасының үрнәкләрен кулланган басмаларның берсе булуы белән дә кызыклы. Шуңа да китапның 1914 елгы бизәлешләре сакланган. Г.Тукайның 1908 елда төшкән фотосы «Г.Тукаевның матбугат галәменә беренче чыккан рәсеме» дигән аңлатма белән китапның беренче битенә урнаштырылган. Әлеге рәсемдә шагыйрь бүгенге көндә Г. Тукай әдәби музеенда саклана торган түбәтәендә сурәтләнгән. Шулай ук басмада Кушлавычта Г.Тукайның туган йорты, Кырлай авылында Фәтхрахман хәзрәт, Өчиле авылында Зиннәтулла хәзрәт йортлары, Кырлайда Тукай укыган малайлар мәктәбенең фотосурәтләре бирелгән. «Ләкин басмаларның берсендә дә фотографның исем-фамилиясе күрсәтелмәгән», – диде Г.Төхвәтова.

Җыентыкта 33 иллюстрация бар. Галимә Ольга Улемнова алар элегрәк эшләнгән иллюстрацияләр кебек үк, шагыйрьнең турыдан-туры үзе катнашында әзерләнгән булуы ихтимал икәнлеген әйтте.

Д.Заһидуллина «Г.Тукай мәҗмугаи асаре» – XX йөз башы татар яңарышының ачык мисалы булуына да игътибарны юнәлтте. Бу вакытта татар әдәби мохитендә 500 битлек әсәрләр чыгарырлык Тукай һ.б. язучылар, шагыйрьләр үсеп җитешкән. «Алар җыентыклары белән халкыбызның милли үзаңын тагын да биеккә, яктыга өндәрлек иҗатчылар дәрәҗәсендә булган дип әйтергә мөмкин», – диде.

Татарстан Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре Рәмзия Абзалина «Г.Тукай мәҗмугаи асаре»нең басылып чыккан елларда бик кыйммәт – 5-10 сум тирәсе торуын, бу бәягә ул вакытта бер сыер сатып алырга мөмкин икәнлеген белдерде. Ә инде китапның Советлар хакимлеге чорында бер тапкыр да нәшер ителмәве, каршылыклар булуы турында да искәртә.

Әмма кыйммәт булуына карамастан китапны сатып алганнар. КФУ профессоры Фоат Галимуллин Г.Тукайның «Мәҗмугаи асаре» китабын Кукмара районы Арпаяз авылындагы бабасының йорты чормасыннан тапкан. Аның Галимулла бабасы үз чорында нәшер ителгән китапларны җыйган. 1930 елларда аларның бабаларын, тормышлары җитеш булгач, йортларыннан куып чыгарганнар. Барлык кирәк- яракларын алып киткәннәр. Әмма кайбер әйберләр, шул исәптән китаплар, чормада сакланып калган. Фоат ага 1970 елларда аларны өйнең түбәсен алыштырган вакытта табып ала. Китаплар арасында «Мәҗмугаи асар» дә була. КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов «Мәҗмугаи асар»ен беренче тапкыр 1990 елның февралендә Хельсинки университетының Көнчыгыш бүлегендә очрата. Аннары берничә нөсхәсен Финляндиядәге милләттәшләребезнең өендә күрә. Алар китапның берсен галимгә бүләк итеп тә җибәрәләр. Ә Хатип ага аны, Казанга алып кайткач, Тукай музеена бүләк итә.

Әлбәттә, Г.Тукайның иҗатын, мирасын барлау дәвам итә. Китапны тәкъдим итү кичәсендә әдәбият галиме Зөфәр Рәмиев шагыйрьнең бүгенге көнгә кадәр ике кулъязмасы табылмавы турында белдерде. «1929 елларда Китап палатасында (15 еллар элек Татарстан Китап палатасы бар иде) Тукайның ике кулъязмасы барлыгы турында әйтелә. Аларның бүгенгәчә табылганы юк. Матбугат архивында шактый материаллар әле тикшерелмәгән», – ди галим. Шулай ук «Фикер» газетасының да берничә саны табылмаган. З.Рәмиев бу газеталарда да Г.Тукайның әсәрләре булырга тиешлеген искәртә.

Сөембикә КАШАПОВА.

Гүзәллек шагыйрәсе

Узган гасырның 74-79 нчы елларында Казан дәүләт университетының татар бүлегендә укыган студентлар арасында Башкортстаннан килгән, шомырт кара күзле, чая, үткен телле Фәния Сәетгәрәева (Габидуллина) да бар иде.

Дүртөйле районының Нажытамак авылында туган кыз күрше Әсән авылындагы урта мәктәпне тәмамлый. Биредә Шәехзадә Бабич рухы белән сугарылган мохит, укытучыларының әдәбият һәм шигърияткә җылы мөнәсәбәте аның кулына да каләм тоттыра. Бишенче сыйныфта ук «Кошлар кайта» исемле шигырь язып, республика матбугатына юллый. Мәктәптә әдәби түгәрәкнең иң актив әгъзасы була. Унынчы сыйныфны тәмамлагач, сабакташы, хәзер танылган язучыбыз Галимҗан Гыйльманов белән бергә Казан дәүләт университетына юл тота. Татар бүлегендә укыганда язучы-шагыйрьләр мохите, танылган әдипләр белән якыннан аралашу, «Әллүки» әдәби түгәрәгенең актив әгъзасы булу аны иҗатка якынайта. Университетны тәмамлагач, бер ел Казанның 10 нчы интернат-мәктәбендә укытучы булып эшли ул һәм... көтмәгәндә, беребезгә дә хәбәр итмичә, Уфасына кайтып китә.... Башта комсомолда чарлана, аннары "Кызыл таң" газетасына килә. 28 ел буе шушы редакциядә корректор, әдәби хезмәткәр, соңрак әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. 2013 елдан 2021 елга кадәр Башкортстан язучылар берлеге рәисе урынбасары, татар әдипләре берләшмәсе җитәкчесе буларак хезмәт итә. Фәниянең төрле чорларда иҗат ителгән 7 шигырь китабы, газета-журналларда күренекле шәхесләребез турында бихисап саллы язмалары басылып чыкты.

Уфасына кайтып китсә дә, Фәниябез Казан белән бәйләнешен өзмәде. Татарстан матбугатына мәкаләләр язды. Башкортстанның күренекле артистлары Фидан Гафаров, Илсөяр Газетдинова, Гөлли Мөбәрәкова, драматург Флорид Бүләков, композитор Байрас Абдуллин хакындагы язмаларын татарлар бик яратып укыды. «Мәдәни җомга», «Казан утлары», «Мәйдан», «Идел» кебек басмаларда шигырьләре басылды. Алай гына да түгел, аны М. Гафури исемендәге башкорт академия драма театры үзләренең корреспондентлары рәвешендә коллективлары белән Казанга гастрольгә алып килә иде. Театр коллективын пропагандалау бурычын күпләргә йөкләмиләр. Фәниянең Казанда дус-танышлары күп булу да моңа этәргеч ясагандыр.

Фәниянең Казан белән бәйләнеше көннән-көн ныгыды. Бер елны Татарстан Язучылар берлегендә башлап язучылар семинары уздырылды. Бу семинарга Башкортстаннан бер төркем күренекле язучы-шагыйрьләр белән яшь иҗатчыларны алып килде ул. Әдәби бәйрәм рәвешен алды ул семинар.

Икенче тапкырында Фәния Бөтендөнья татар конгрессы тәкъдиме белән Казанга егермегә якын Башкортстан шагыйрьләрен алып килде. Бу чара «Казанда Башкортстан шигърияте көннәре» дип аталды. Башкортстан кунаклары арасында халык шагыйре Марат Кәримов та бар иде. Ике көн дәвамында Башкортстан татарларының иҗади десанты Казанны чын мәгънәсендә «яулады»: «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе «Татарлар», «Манзара» тапшырулары яздырып халыкка тәкъдим итте. Бөтендөнья татар конгрессының «Дөнья» видеостудиясендә Римзил Вәлиев кунаклар белән җитди сөйләшү оештырды. Язучылар берлегендә очрашу, аннары милли-мәдәни үзәктә «Шигырь һәм җыр» бәйрәме узды.

Тагын сабакташыбыз Фәния оештырган бер күңелле вакыйгада катнашырга туры килде. Ул «Туган моң илчеләре» дигән китап туе иде. Бу китапка Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучылары турында фотосурәтләре белән биографик белешмә, аларның иҗат җимешләре тупланган. Фәниянең «Без татарлар бит әле» исемле мәкаләсе белән башланып киткән, Башкортстанда яшәүче татар авторларының үз акчаларына чыгарылган бу җыентык гаять зур әһәмияткә ия. Моңа кадәр мондый китап чыкканы булмаган. Иҗат белән шөгыльләнүчеләр өчен генә түгел, әдәбиятны яратучылар, җәмәгатьчелек өчен дә зур вакыйга булды ул. Бу хезмәтен Башкортстанда югары бәяләгәннәр: Ф.Кәрим исемендәге премия биргәннәр!

Фәния Казан дәүләт университетында укыганда ук үзен оста оештыручы итеп күрсәтте, дигән идем. Төркемебезнең комсоргы иде ул. Башкортстаннан Казанга мондый әдәби десантлар оештыру җиңел түгеллеген аңлыйбыз. Әле болар без күргән, ишеткән аның эшләренең бик азы гына. Уфасында башкарган эшләре белән матбугат аша танышбыз. Ул хезмәтләре өчен дә бик күп бүләкләргә ия булды.

Татар телле әдипләр берләшмәсе җитәкчесе буларак Ф.Габидуллинаның эшчәнлеге аеруча игътибарга лаек. Хәсән Туфан, Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Гамил Афзал, Зөит Мәҗитов, Ркаил Зәйдулла, Галимҗан Гыйльманов, Нәҗибә Сафина һ.б. татар-башкорт шагыйрьләренең иҗат җимешләрен сыйдырган «Җырның булмый соңлаганы» дигән китапта Наҗар Нәҗмигә багышланган шигырьләр тупланган. Матбугатта әлеге җыентыкка югары бәя бирелде. Фәния ул елны бертавыштан Наҗар Нәҗми исемендәге премиягә лаек булды.

Рим Хәсәнов белән.

Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин Ф.Габидуллинаның моннан алдагы юбилее уңаеннан «Егетлек ул хатын-кызларга да килешә» дигән мәкаләсендә аның иҗатына һәм эшчәнлегенә бик югары бәя биргән иде. «Егетлек ир-атларны гына түгел, хатын-кызларны да бизи торган, аларның мәртәбәсен арттыра торган матур бер сыйфаттыр ул. Егетлек ул хатын-кызларга да бик килешеп тора!» Әдип Фәниянең «Язмышлар ярында» исемле китабын яшь иҗатчылар турында энциклопедик материал дип атый.

Фәниянең шигърияте гүзәл затларга хас күңел дөньясы, хыял-омтылышлары, илаһи сиземлеге, сагыш борчулары, әниләр җылысы, дәү әниләрнең иманы, иң мөһиме – хатын-кызның дөньяга булган мәхәббәте белән кереп урнаша. Шагыйрә беренче карашка ук эчкерсез, һәрвакытта ярдәмгә атлыгып торган, хуш күңелле булуы белән җылы тәэсир калдыра. Күңел иркен, дөнья киң, кояш астында барыбызга да урын җитә дигән принцип белән яши ул. Авыл һәм әни темасы Фәния Габидуллина иҗатында аерым бер нур, сагыш-моңнар, нечкә төсмерләр белән балкып китә. Шигырьләреннән туган җиргә, туган йортка, әнкәйләргә, авылдашларга үзгә бер җылылык бөркелеп тора. Язучылар арасында, шигърияттә кайнаган каләм иясе беркайчан да ясалма рифмалар язу белән шөгыльләнми. Укучысына юл табар өчен аның теле дә, каләме дә шома. Шагыйрәнең көче – ихласлыкта, иҗатта үз сукмагын яра белүдә, дөньяны үзенчә нәфис төсләрдә күрүендә, күргәннәрен садә күңеле аша үткәреп, гәүдәләндерә белүендә. Фәния Габидуллина да меңнәрчә каләм кагылган шул ук авыл, әнкәй темасын ала да нәкъ үзенчә яктырта, сагыну, ярату хисләренә яңа гамь, яңа төсмерләр бирә.

Мин-минлекнең эзе дә юк Фәния-шагыйрә иҗатында, ул акыл өйрәтүдән дә, дидактикадан да ерак, хәтта акыллы күренергә тырышып фәлсәфәгә дә чуммый. Аның тормыш фәлсәфәсе фикер сөрешенә сеңгән, аның әхлакый кануннары шигырь юллары арасында яшерелгән.

Җирне салкыннан саклыйм дип,
Шәрә калды тал-тирәк.
Газизләрне уйлап шулчак,
Сулкылдап куйды йөрәк...

Башка каләм ияләре кебек үк, язучының рухи кыйбласы, иҗат чыганагы – авылда, аның табигатендә, кешеләрендә. Әнә ич ул туып-үскән урамда күпме кызлар! Барысы да уңган, булган, тормышта югалып калмаган. Алар арасында гомер буе туган нигезен сагынып, әти-әни тәрбиясен кыйбла итеп, алар җылысына сусап яшәгән Фәния дә бар.

Кулларыма агач көрәк алып,
Юллар ачар идем туган йортка...

Меңнәр шигъриятендә урын алган табигать манзарасын Фәния Габидуллина үзгә бер төс-хәрәкәтләрдә күрә. Аның өчен яңа чыккан каз бәбкәләре дә, әни белән бергә каз оясына салам түшәү ихтыяҗы да балачакны, туган нигезне сагыну тойгылары белән үрелеп, иҗади шәхес формалашуга ишарә ясый. Еш кына шәһәр гамьсезлеге, анда эзсез үткән фасыллар заялыгы авылның кабатланмас яшәеш сурәтләренә каршы куела. Автор илһам эзләп авылга кайта, тик монда гына иҗат дөньясына лаеклы төс-хәрәкәтләрне, манзараны таба.

Гөрләвекләр җырын тыңлар өчен
Кайтам әле, кайтам авылга;
Шәһәрләрдә кары күп булса да,
Көйсез генә эри, тын гына.
Авылымда һавасы да бүтән,
Җилләреннән килә тал исе...

Балачак – шагыйрә өчен илаһи мизгел, шигъриятенең таяну ноктасы. Иҗатының чишмә башы шушындадыр төсле аның. «Бал бабайлы балачак» шигырендә:

Бал бабайлы булган өчендерме,
Татлы булып хәтерләрдә калган
Ялан тәпи үткән балачак, –

дип шагыйрә бу мизгелнең тере сурәтен тудыра.

Көрткә чумып, таулар шуар өчен
Әй кайтасы иде балачакка, –

ди ул «Әллә кар елый микән» шигырендә, әкияти бер манзара тудырып. Гомумән, Ф.Габидуллина шигъриятенә динамика, вакыйгалар хәрәкәтчәнлеге, тере сурәтләлек хас. Ул мавыктыра, күңелгә тирән үтеп керә, истә кала.

Нурия **САФИУЛЛИНА-ХӘЙРУЛЛИНА.**

Кулымда әйләнә орчыгым, Гомерем җепләре урала...

Дилә БУЛГАКОВА

СУ АНАСЫ ВӘ ШҮРӘЛЕ ГЫЙШКЫ

Якын безгә әкиятләр –
Балачакка охшаган.
Әкиятләр тыңлап үстем,
Әкияткә ышанам.

Каләм-кәгазьләрем алып,
Әкияткә барыйммы?
Ышанырлык бер әкият
Мин дә язып карыйммы?

Көтеп алган җәебездә,
Кошлар иле – матурлык.
Бәпкә үлән өсләрендә
Тәкмәч атып ятарлык.

Бакчага чыгып утырдым,
Имән төбе – өстәлем.
Каурый каләм һәм кәгазем,
Чынаяк тулы чәем.

Алдым каләм-кәгазьләрем,
Мине беркем тапмасын.
Яңа әкияткә үзем
Кердем ачып капкасын.

Үләннәрне яра-яра,
Әкият иленә үттем.
Яңа туган әкияттән
Төрле могҗиза көттем.

Утырдым да күл буена,
Карыйм йолдыз бәйрәмен.
Камышлы күл басмасында
Су анасын шәйләдем.

Алтын чәчен сүтеп тарый,
Басмасына баскан да.
Тирә-ягына карана –
Мин үләннәр астында.

Кулында кызның тарагы
Көмештәнме коелган?
Йолдызлар, күлгә атылып,
Камышларга сыенган.

Озын толымы ураган
Су анасының сынын.
Су анасының моңнары
Өзәрлек йөрәк кылын.

Ялгызлыктан моңланадыр,
Еламыйча яшь йота.
Күрмәгән дустын юксына,
Яна ялкынсыз утта.

Ашамый, эчми, йокламый,
Ялгызлыктан моңлана.
Ничекләр ярдәм итәргә,
Кайда соң дусты, кайда?

Өметләнеп көтә дустын,
Тау артыннан – ерактан.
“Көттеңме?” – дип сорар әле,
Төшкәч канатлы аттан.

Җиләкләр җыеп ашадым –
Сизмәде барлыгымны.
Башымнан салып калдырдым
Ак батист яулыгымны.

Башына эссе капмасын,
Куансын Су анасы.
Үлән ярып киттем әле,
Барасы да барасы.

Үзем каурый каләмемдә
Атламый – очып барам.
Пәйда булды юлларымда
Үтмәслек кара урман.

Каурыема тотындым да,
Урманга кердем кинәт.
Шүрәлеләр дөньясы бу,
Яшиләр бергә, күмәк.

Уеннары кети-кети,
Алар өчен чикләр юк.
Капчык-капчык киптерәләр
Бергә җыеп чикләвек.

Уңган тиеннәр күмәкләп,
Чикләвек чиртә бергә.
Җыеп алып коелганын,
Сыйландым әле мин дә.

Караңгы түгел урманда,
Ут яна күзләрендә.
Такмак әйтеп әйләнәләр,
Ят түгел сүзләре дә.

Бергәләп биеп әйләнә,
Барысы да ут күзле.
Койрыклары озын түгел,
Маңгайлары мөгезле.

Сөрмәле күзле берсенең
Үсмәгән, ди, мөгезе.
Уйнамыйлар аның белән,
Утыра ул берүзе.

Шүрәленең дәү әтисе
Утыра әнә түрдә,
Мөгезсез, сөрмәле күзнең
Яшен йотканын күрә.

Борчылма син, сөрмәле күз,
Сабыр, акыллы бала.
Юлларыңда адашмаска
Күзеңдә утлар яна.

– Минем дустым юксынадыр,
Хәлен барып белмәдем.
Ничек барыйм соң янына,
Өстемдә юк күлмәгем?

Дәү әтисе сандыгыннан
Читеген алып бирде.
Хәзер безнең Шүрәлебез
Киез читекле инде.

Барсына да үзем шаһит:
Шүрәле сабыр итте;
Канатлы атында җилеп.
Ерак авылга китте.

Каурый каләмдә җиләмен,
Урманнар калды артта.
Шүрәлебез өмет белән
Оча канатлы атта.

Авылга килеп кергәндә,
Төн уртасы – караңгы.
Һәммәсе тирән йокыда,
Сизмәделәр каракны.

Шүрәлебез читәннәрдән,
Өй алдыннан сикерде.
Кипкән керләр арасында
Ыштан, күлмәкне күрде...

Тиз генә шылды Шүрәле,
Мин артыннан китәмен.
Читәнгә эләгеп, минем
Калды ярты итәгем.

Уянды авыл, урамнар,
Килгәнме төнге карак?
Этләре ярсып өрәләр,
Юлга, урманга карап.

Ул да оча, мин дә очам,
Шәйләмәде, күрмәде.
Ыштанлы, киндер күлмәкле
Әкияттәге Шүрәле.

Үзе сагынып Су анасын,
Төшкән канатлы аттан.
Сагышлы, тозлы яшеннән
Күлнең сулары арткан.

Үткән вакытны санамый,
Очраштылар бит тәки!
Су кызы - киез итектән,
Шүрәле ялан тәпи.

Әкияттән чыгыйм әле,
Балачак хыялымнан.
Каурый каләм өстәлемдә,
Сызылып ата яңа таң.

Әкиятем ошадымы,
Сезнең, безнең балачак?
Рәсемнәрен ясасагыз,
Әкияттә калачак.

ЮЛАУЧЫЛАР КЕРСӘ...

“Бисмилла”лап кына пакьлән әле,
Намазыңны укы, калмасын.
Яшең йотып, Аллаһыдан сора,
Кабул булыр теләк-намазың.

Юлаучылар керсә, казаның ас,
Табыныңа укып, шөкер кыл.
Рәхмәтеңнән бәрәкәтең артыр,
Нәнәләрең кебек сабыр бул.

Юлаучылар керсә, казан асып,
Каршы алыйк ихлас күңелдән.
Арасында, бәлки, кунакларның
Хозыр-Ильяс бардыр, кем белгән.

Юлаучылар намаз укып китсә,
Сарылып калыр азан-догалар.
Хушлашканда хәерләрең өләш,
Бабалардан калган йола бар.

* * *

Бу дөньяда ташның була күп төрлесе:
Шомарганы, ярылганы йә серлесе.

Кайчагында таш астыннан елга чыга.
Көтмәгәндә таш астыннан елан чага.

Кайберсенә кояш нуры сеңеп калган,
Кайсы яна мең-мең төстә, ләкин ялган.

Гәүһәр бу, дип үрелгәнче уйла башта,
Гади таш та охшаш була асылташка.

ЧАҢ КАГА КЫҢГЫРАУЛАР

Каен тузлары ята,
Зифа буйлы каеннарны
Чапкалап киткән балта...

Каеннар кара көйгән.
Иманнәре горур, диләр,
Алар да башын игән...

Акланнарда шомлы аваз,
Үләннәрдә изелә наз,
Чаң кага кыңгыраулар:

Себерке сындыралар, –
Каеннарның кул-ботагын
Өзгәләп тондыралар.

Урманны шом биләп үтә,
Җиккән атлар дертләп китә,
Чаң кага кыңгыраулар.

ИЗГЕ КОШЛАР

Хушлашмыйча ак торналар китә,
Ояларын җилләр тараткан.
Моңсуланып калган якты дөнья,
Көз авазы килә ерактан.

Киткән чакта туган якларыннан
Ни кичерә икән торналар?
Кай тарафта тукталырлар инде,
Ничек каршы алыр ят яклар?

Озатамын изге кошчыкларны,
Болытлар да яшькә тулгандыр.
Моңсуланган, сагышланган җиргә
Шуңа көзләр килә торгандыр.

Сәфәрегез ерак, ак торналар,
Язмышыгыз безгә билгесез.
Киткән кебек парлап кайтыгызчы,
Язлар урап килмәс, юк, сезсез.
Язлар килмәс безгә, юк, сезсез!

ӘЙЛӘНӘ ОРЧЫГЫМ

Китәләр, китәләр кошкайлар,
Офыкка сарылып моң кала.
Кулымда әйләнә орчыгым,
Әйләнеп, бәйләнеп тын кала...

Орчыгым җебенә тезелә
Гомернең мизгелләр сәйләне.
Ачышлар, югалту, табышлар
Өзелеп-ялганып бәйләнде.

Озата чыкканда кошларны
Тоямын күзләрнең сулышын.
Буш калган оялар чайкала,
Җил ала аларның җылысын.

Кулымда әйләнә орчыгым,
Гомерем җепләре урала...
Кошларның моңына бәйләнеп,
Офыкта ак җебем югала...

Уфа.

■ **Атнаның сәяси мизгелләре**

ФАКТЛАР ТЕЛЕ НИ СӨЙЛИ?

Узган атнаның төп сәяси вакыйгалары, әлбәттә инде, Украинадагы хәлләр белән бәйле. Бу җәһәттән хәбәрләр күп һәм каршылыклы булды. Шуңа күрә, аларны шәрехләп тормастан, төп вакыйгаларны факт буларак телгә алу белән генә чикләнербез. Украинада хәрби объектларга ракета һөҗүме башлангач, илдә хәрби хәл режимы кертелде, гомуми мобилизация игълан ителде, президент В.Зеленский Россия белән ике арада дипломатик мөнәсәбәтләр туктатылуы турында да белдерде. БМО Генераль секретаре А.Гуттериш Россиянең Донбассны яклап үткәргән хәрби операциясе БМО Уставы принципларына каршы килүе турында белдерде һәм Россия президенты В.Путинны, бөтен кешелек дөньясы хакына, үз гаскәрләрен Россиягә кире кайтарырга чакырды. Европа шурасы һәм Европа комиссиясе, шулай ук НАТО җитәкчелеге һ.б. халыкара оешмалар Россия үткәрә торган хәрби операцияне гаепләп чыкты. Шундый ук гаепләүләрне АКШ, Алмания, Бөекбритания, Израиль, Финляндия, Франция һ.б. ил җитәкчеләре дә белдерде. Күп илләр Россия очкычлары өчен һава киңлекләрен япты һәм башка чикләүләр дә кертте. Хәрби операциянең тәүге көнендә үк Россиянең 42 шәһәрендә стихияле митинглар үтте. Рөхсәт ителмәгән акциядә ул көнне Мәскәүдә генә дә 600ләп кеше тоткарланган.

Ә алга таба инде дөнья җәмәгатьчелеге кискенрәк чараларга да күчте. Әйтик, Европа Шурасы Россиянең оешмада әгъзалыгын туктатып тору турында карар кабул итте. Европа Берлеге үзенең һава киңлекләрен Россия өчен тулысынча ябуы турында белдерде һәм аның банкларына карата чикләүләр дә кертте (сүз кайберләрен SWIFT системасыннан аеру турында да бара). Халык 25 февральдә (бер көндә!) генә дә банклардан 1,4 триллион сум акчасын алган булып чыкты. Россия Үзәк банкы төп ставкасын 20%ка кадәр күтәрде. Кайбер илләр Россиянең югары җитәкчелегенә карата да санкцияләр кертте. Нәтиҗәдә, С.Лавров хәтта Женевага БМО комитеты утырышына да бара алмый. Россия президенты әмере белән илнең атом-төш коралын куллану "өчлеге" сугышчан кизү торуның махсус режимына күчерелде. Украина исә 2014 елдан Кырымда һәм Донбасста кеше хокукларын бозуны тикшерү өчен БМОга резолюция юллады. 27 февральдә БМО КШ, БМО Генераль Ассамблеясенең Россиягә кагылышлы махсус сессиясен чакыру буенча, резолюция кабул итте. Чөнки бу көнне анда, Мәскәү вето хокукын куллану сәбәпле, Россияне гаепли торган резолюция кабул ителмәгән. Ә 28 февральдә, ниһаять, Украина белән Россия арасында тәүге сөйләшүләр үтте. Яклар анда 5 сәгать уртак нокта эзләгән. Әмма әлегә андый бер генә нокта табылмаган. Ул - сөйләшүләрне алга таба да дәвам итү.

Фоат УРАЗАЙ.

Галимнәр мәдәни

Рәсем сәнгате, халык һөнәрчелеге, театр, музыка өлкәсендә республикабыз мирасын саклау ни дәрәҗәдә куелган, дигән сорауга җавапны берникадәр Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының үткән елга нәтиҗә ясау уңаеннан һәм Россиядә халык сәнгате һәм матди булмаган мирас елына багышлап уздырылган «түгәрәк өстәл» утырышында табарга мөмкин иде. Фикер алышуда Г.Ибраһимов институтының Тасвирый һәм гамәли бизәү сәнгатьләре, театр һәм музыка бүлекләренең фәнни хезмәткәрләре, музей белгечләре, сәнгать буенча белем биргән уку йортлары вәкилләре, рәссамнар катнашты.

● Сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова.

Китап күңел үстерә

Сәнгать белгечләренең максаты – мәдәни мирасыбызны өйрәнеп, киләчәк буыннар өчен китаплар аша мәңгеләштерү. Шөкер, үткән ел китапларга бай булган. Республикабыз районнарына экспедицияләргә барып, андагы мәдәни мирасны төрле яклап өйрәнгәннән соң бастырып чыгарылган «Калейдоскоп культур» мәкаләләр җыентыгы, тукучылык буенча халыкара симпозиум материалларына нигезләнеп бастырылган махсус җыентык, сәнгать белгече Динә Хисамованың әнисе сәнгать фәннәре докторы Динә Кәрим кызы Вәлиевага багышланган монографиясе, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанованың күренекле рәссамыбыз Олег Кульпин турында затлы альбомы елның бик нәтиҗәле узганын чамаларга мөмкинлек бирә.

Кайбер китап-җыентыкларга аерым тукталмыйча мөмкин түгел. Шуларның берсе – сәнгать белгече Р.Солтанова Мәдәният министрлыгы каршындагы «ТатКультРесурсЦентр» белән берлектә төзеп чыгарган Татарстанның һөнәрчеләре, гамәли бизәү сәнгать осталары турында каталог. Республикабызда һөнәрчеләребезне табу, эшләрен өйрәнеп, реестрга теркәү байтактан алып барыла. Әлеге мәҗмуга – шул эшнең бер нәтиҗәсе. Каталогка республикабызның 12 иҗат берләшмәсе, 40 кул остасы турында мәгълүмат кергән. Биредә каюлы күн, зәркән, агачны сәнгатьле эшкәртү, киез басу, тукучылык, чигү, челтәр бәйләү һ.б. урын алган. «ТатКультРесурсЦентр»ның директор урынбасары Гөлназ Латыйпованың сүзләренә караганда, башка еллардагылардан аермалы буларак, бу мәҗмугада мәгълүмат беренче тапкыр тарихи үсештә күрсәтелә. Берләшмәләрнең урнашу урыннары, телефоннары күрсәтелүе шулай ук бик мөһим. Алга таба каталогны төбәкләр турында аерым чыгару каралган, чөнки бу беренче томга сыймыйча бик күп бай мәгълүмат калган. Каталогның затлы кәгазьдә күз явын алырлык матур рәсемнәр белән бизәп бастырылуын билгеләп үтәргә кирәк. Дөрес, аның тиражы зур түгел – нибары 500 данә. Әмма һөнәрмәндләрне барлау эше алга таба да уңышлы дәвам итсә, тиражларның да артуына өмет бар. Иң мөһиме, халык сәнгатен саклау эше тукталмый һәм белгечләребез аларның үзләре белән тыгыз элемтәдә торып, гамәли бизәү сәнгатенең югары дәрәҗәсен сакларга ярдәм итә ала.

Сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанованың Казан сәнгать училищесының – 125, Театр училищесының 100 еллыгы уңаеннан чыгарылган сәхнә рәссамнары, костюмерлар, бутафор, гример һ.б. турында «Школа мастеров» китабы ел вакыйгасына тарта, дисәк һич арттыру булмас. Чөнки бүген чорлар, буыннар арасында бәйләнеш өзелү нәтиҗәсендә сәхнә бизәү сәнгатенең сыйфаты түбән төшү күзәтелә. Кап-караңгы, буп-буш сәхнәләрдән тамашачы да туеп бара. Бу вәзгыятьтә татар театрларында могҗиза тудырган П.Сперанскийны, В.Никитин, М.Сутюшев, Ә.Тумашев һ.б. искә төшерү бик урынлы. Рецензент сәнгать белгече Екатерина Ключевскаяның әйтүенә караганда, осталар турында бай мәгълүмат, бериш мөгаллимнәрнең истәлекләре, төрле архивлардан җыелган документаль фотолар, рәсемнәр китапның кыйммәтен тагын да арттыра төшкән. Моңа кадәр бутафор, гример, реквизит ясаучылар театраль белемнең бер өлеше буларак өстән-өстән генә өйрәнелсә, бу һөнәрләрне беренче тапкыр аерым актырткан әлеге китап киләчәктә тагын да тирәнрәк эзләнүләр өчен бәһасез җирлек булып тора.

Галимә Наталья Герасимованың 1920-1930 елларда Татарстан музейларында коллекцияләр туплау турында өр-яңа китабы да зур кызыксыну уятты. Ник дигәндә, үткән гасырның егерменче елларында музей кору эше бик югары куелган була, әмма ни кызганыч, 1930 елларда илдә идеология үзгәрү сәбәпле ул чорда ачылган күп музейларның ябалар, тупланмаларны саталар. Аннан соң байтак вакыт үтсә дә, проблема бүген дә көн үзәгеннән төшкәне юк, бигрәк тә районнардагы музейлар бу хезмәт белән кызыксынуларын белдергән, чөнки музей коллекцияләрен туплау, музейлар төзү эше бүген дә дәвам итә, кадрлар мәсьәләсе әле һаман да кискен тора.

Музей төзү эше ни хәлдә?

Бүген яңа музейлар төзү эше зур авырлык белән бара. Беренчедән, яңа экспонатларның булмавы, икенчедән, борынгыларын реставрацияләү эше бик сүлпән баруы кыенлык тудыра. Мәсәлән, Болгарда Икмәк музее һәм Тегермәнче йорты экспозицияләрен корганда Алексеевск туку фабрикасы һәм Кукмара киез итек фабрикасы ярдәмендә борыңгы үрнәкләргә охшаш яңа экспонатлар булдырганнар. Бу тәҗрибә Алексеевск һәм Кукмара фабрикалары өчен үсешкә бер этәргеч булса да, музейларны гел яңа экспонатлар белән генә корып булмаячагы көн кебек ачык. Быел, мәсәлән, Буаның үзендә 125 еллыгы уңаеннан олуг рәссамыбыз Бакый Урманченең музеен ачу ниятләнә. Әмма ул музейны нәрсә белән тутырачаклары әлегә кадәр билгесез. Гел цифрлы копияләр чыгарып куймаслар бит.

Галимнәрдә музейларга кагылышлы сораулар күп. Милли музей тупланмаларында татар милли костюмнары күп булуына карамастан, ни өчен тамашачы игътибарына шуның бик аз өлеше генә тәкъдим ителә? Милли музейда әйтүләренә караганда, күргәзмә мәйданнары бик чикле булу сәбәпле, бөтесен күрсәтергә мөмкинлек юк. Озакламый, мәсәлән, коллекционерлар Андрей Лихачев, Григорий Вульфсонга багышланган күргәзмәләр ачылачак. Лихачев турындагы экспозиция тәмамлангач, Петр I турында күргәзмә ачылыр дип көтелә. Анңары Болгарда Ислам кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан экспозиция корачаклар. Әнә шулай татар костюмы һаман читтә кала бирә. Дөрес, моннан ике ел элек Милли музейда төрле төбәкләрдән китереп бик зур күргәзмә оештырганнар иде. Әмма милли костюм сирәк-мирәк түгел, даими рәвештә зурлап күрсәтелергә тиеш ләбаса. Көн саен Казаныбызга күпме турист килә. Милли байлыгыбызны алар да күреп китәрлек булсын. Ел саен училище, институтлардан ничаклы дизайнер, костюм белгече чыгарыла. Көне-төне музейда милли костюм өйрәнмәгәч, нинди белем алып чыга ул яшьләребез? Киләчәктә кемне киендерәчәкләр: үзебезнең татарнымы, әллә марҗаннымы? Сәнгать белгече Р.Солтанова да бу өлкәдәге вәзгыятькә карата борчылуын белдерде. Аның сүзләренә караганда, бездә нибары ике-өч хәситә сакланган. Өрпәкне ни икәнен оныта барабыз. Экспедицияләр күрсәткәнчә, әбиләрнең сандыкларында, мәдәният йортлары, мәктәп музей экспозицияләрендә бәяләп бетергесез зур байлык саклана. Кичекмәстән Мәдәният министрлыгында халыктан сатып алу мәсьәләсен күтәрергә кирәк. Халык сәнгате музеен ачмый торып, без милли мирасны тиешенчә саклый алмаячакбыз. Олуг рәссамыбыз Бакый Урманче боларны 1980 елларда ук күтәргән була. Әмма әлегә кадәр максатыбызга ирешкәнебез юк. Галимә бу җәһәттән халык сәнгате алга киткән Үзбәкстанны мисалга китереп үтте. Алар бөтен дөньядан үзбәк халкының милли мирасын туплап 20 томлы хезмәт тә нәшер иткән.

Урманче мирасы борчу уята

Рәссам Б.Урманче исеме сөйләшү дәвамында телдән төшмәде. Быел кылкаләм остасының юбилее билгеләп үтелү мирас саклауда байтак проблемалар барлыгын күрсәтте. Әмма сүзне шатлыклы хәбәрләрдән башлап Чаллы картиналар галереясы хезмәткәре Марат Мингалиевнең Б.Урманченең графикасына багышлап чыгарылган китабы турында искәртәсе килә. Соңгы елларда сәнгать белемендәге авыр мәсьәләләрне өйрәнү-чишү күбрәк хатын-кыз галимәләребез җилкәсенә төшкәнгә, бу өлкәдә яшь, эшләргә ыжгырып торган ир-атның пәйда булуы үзе куаныч бит. Өстәвенә, Марат – үзе үк рәссам да, сәнгать белгече һәм галерея хезмәткәре дә. М.Мингалиев Урманченең графикасына беренче тапкыр игътибар юнәлтеп кенә калмаган, картина, скульптуралар кебек үк, график рәсемнәрнең дә Урманче иҗатында зур, мөһим урын тотуын дәлилләгән. Моңа

мирас сагында



Бакый Урманче музее.

кадәр күпләр графиканы зур картиналарга яки скульптураларга әзерлек кенә дип караган булса, М.Мингалиев Б.Урманченың графикасы мөстәкыйль тәмамланган әсәрләр икәне һәм сәнгати кыйммәте ягыннан картиналар һәм скульптуралары белән бер тиң булуын тәгаенләгән. Моннан тыш китапта олуг рәссамның шактый күп рәсемен һәм график эшләренең чагыштырмача тулы исемлеген китергән.

Галимнәребезнең Б.Урманче мирасын өйрәнүләре сөендерсә, рәссамның Казандагы музее чынлап торып борчуга сала. Беренче татар профессиональ рәссамыбызның музее ел әйләнәсенә, бигрәк тә юбилей елында гөрләп эшләргә тиеш түгелмени? Мәктәп балалары төркем-төркем килеп, өзелеп тормаска тиеш. Музейның сүлпән эшләве генә җитмәгән иде, безгә бөтенләй Бакый ага мирасыннан колак кагу куркынычы яный, чөнки музейдагы күпчелек экспонатлар Мәскәүдәге Ш.Мәрҗани фондыныкы икән! Фонд аларны алып китә калса, Казан бөтенләй музейсыз калачак. Б.Урманче музееи югалту исә Мәскәүнең Пушкин музееи югалтуына тиң. Казан музее ни өчен шундый хәлдә калган, моңа кем гаепле?

«Ретроспектива» антиквар галереясының хуҗасы Гадел Фәйзуллинның да сүзләре күңелгә шом өстәде. Галереяда Б.Урманченың рәсемнәре саклана. Аның кайберләре «түгәрәк өстәл» узган Татарстан Фәннәр академиясе бинасында күргәзмәгә дә куелган иде. Экспозициянең корылышыннан ук рәсемнәрне кадерләп саклауларын чамаларга була. Әмма Гаделнең бер нәрсәгә җаны әрни: рәсемнәрне берән-сәрән сатып бетерәсе килми, бөтенесе дә бер урында – республикабыз музейларында саклансын иде, дип тели. Бу җәһәттән республикабызда мәдәният өчен җаваплы җитәкчеләргә хатлар да язган, әмма Гаделнең сүзләрен әлегә кадәр җитдигә алган кеше юк. Дөрес, сынлы сәнгать музеенда Бакый ага Урманченың картиналарыннан зур тупланма саклана. Әмма гади тамашачы аларны көн саен күрә аламы соң? Рәссамның картина, скульптура, графикасы һәм каллиграфиясе көн саен даими экспозициядә күрсәтелеп торса гына, без мирасны тиешенчә саклыйбыз, дип горурланып әйтә алачакбыз. Аңа чаклы Б.Урманче, дип авыз чайкавыбыз бер файдасыз. Татар профессиональ рәсем сәнгатенә нигез салган рәссамның мирасы Сынлы сәнгать музееның караңгы почмакларында яшеренеп ятарга тиеш түгел! «Ретроспектива» антиквар галереясының рәсемнәр коллекциясе исә Б.Урманченың Казандагы музее өчен бер дигән. Аны да Мәскәүдәге Ш.Мәрҗани фонды эләктергәнче, ашыгырга кирәк!

Композиторлар мирасын бастыру җитенкерәме

Музыка белгече Гүзәл Юнысова музыкаль мирасны саклау эшенең барышы белән таныштырды. Аерым алганда, Солтан Габәши турында өр-яңа китапның әзер булуын әйтте. Моңа кадәр бу композитор турында ике басма – Г.Ибраһимов институтында Гөлнур Гобәйдуллина һәм Геннадий Макаров туплаган китап һәм Йолдыз Исәнбәтнең «Газиз Әлмөхәммәдов һәм Солтан Габәши Казанда» дип исемләнгәне чыккан була. Өченче китапның алдагыларыннан аермасы – татар телендә нәшер ителүендә, яңа материаллар белән баетылуында. Г.Юнысова композиторларыбызның музыкаль мирасын нәшер итүдә җитешсезлекләргә әрни. Бүген безнең Салих Сәйдәшев һәм Рөстәм Яхинның музыкаль мирасы гына нәшер ителгән, алары да тулы түгел. С.Габәши, В.Виноградов һәм Г.Әлмөхәммәдов өчесе иҗат иткән «Сания» һәм «Эшче» опералары М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры куймаса да, Казан консерваториясе каршындагы опера студиясе бервакыт сәхнәләштерер дигән өмет бар. Гомумән, аларның партитураларына әледән-әле ихтыяҗ чыгып тора. Былтыр, мәсәлән, Г.Әлмөхәммәдовның юбилее уңаеннан Башкортстаннан соратучылар булган. Моннан тыш Лас Вегастан бер фән докторы беренче татар операларының партитуралары белән кызыксынган. Бүтән композиторларның опера мирасы шулай ук Гүзәл ханымны борчуга сала, чөнки Н.Җиһановның байтак опералары сәхнәләштерсә дә, Бөек Ватан сугышы елларында һәм бүтән сәбәп белән татар композиторларының егермеләп операсы бер дә куелмый кала. Егерме опера! Никадәр байлык! Галимә бу бәһасез мирасны нәшер итеп халкыбызга кайтару һәм сәхнәләштерү юлларын эзләү кирәклеген әйтте.

Гыйләҗетдин Сәйфуллинның нота җыентыгын һәм аудио тәлинкә чыгару мәсьәләсе шулай ук көн үзәгендә тора. Сәйфуллин 600 татар җырын беренче тапкыр тимер тәлинкәгә яздыра. «Тәфтиләү», «Баламишкин», «Әрбет», «Ончы Фәхри», «Казан сөлгесе», «Былбылым», «Салкын чишмә» җырлары да шулар арасында. Сәйфуллин революциягә кадәр башлаган бу эшен аннан соң да дәвам итә. Нәтиҗәдә, төрек, үзбәк, чуаш, рус җырларын да яздыра. Музыкаль мирасыбызны саклаган шундый шәхеснең үзенең мирасын мәңгеләштерү мактаулы, изге эшләрдән булыр иде.

Бию турында фән кирәк

Әстерхан татары Дәүләт Үмәров менә 17 ел инде татар биюен өйрәнә. Шул гомер буе ул бию турында фән юклыгы, белем бирү җайга салынмаганы, сәнгатьнең алга китмәвен әйтеп чаң кага. Үзенең фикерләре белән ул «түгәрәк өстәл»дә дә уртаклашты. Ни өчен Казан мәдәният һәм сәнгать университетында татар халык биюе кафедрасы юк, дигән сораудан башлады ул сүзен. Ни өчен университетта Идел буе халыклары һәм заманча биюләр өйрәтелә, татар халык биюенә аерым игътибар бирелми, дип галимнәрне сорау алдында калдырды. Яшьләребезгә хореограф белгечлеге биреп чыгарабыз икән, димәк, алар биюне яза белергә тиеш, чөнки «хорео» - бию, «графия» язу дип тәрҗемә ителә. Юкса без аларга биюче белгечлеге генә бирергә тиеш. Бездә 1960 еллардан бирле күренекле балетмейстер Гай Таһировтан соң татар биюе өйрәнелми. Таһиров та бию сәнгатенең каймагын гына өйрәнгән, тирәнгә керергә вакыты да, мөмкинлеге дә җитмәгән. Ни өчен бөтен дөнья буенча сибелгән татарларның нибары йөз халык биюе, төрекләрнең исә кырык мең халык биюе билгеле, дип шаккатырды Д.Үмәров. Үзе исә ул коры сүз сөйләп кенә йөрмәгән, Әстерхан, Саратов, Самара, Ульяновск, Түбән Новгород, Себердәге милләттәшләребездән бик күп биюләр язып алып кайткан. 2012 елда Мәскәү гранты отып, Түбән һәм Урта Идел татарларының биюләре турында китап чыгарган һәм ул Мәскәүдә бию китаплары арасында беренчелекне алган. Татар биюенең Мәскәүгә кирәк булып та, үз Татарстаныбызга кирәкмәве җәһәтеннән ачына ул.

Бүген интернет, компьютер заманында күпләр китаптан бизә бара, биюләрне дә китапта бастырмыйча, видеога яздырырга кирәк, диючеләр байтак очрый. Бу сөйләшүдә дә бию мирасын видео аша саклау турында сүз булды. Бервакыт Мәскәүдә фольклорчылар конгрессында да Дәүләт Үмәровка шулай дип ябырылганнар. Шунда Әстерхан татарын итальян белгече яклап чыккан, чөнки алар үзләренең лабан атлы биюләрен 1940 еллардан бирле бик җентекләп өйрәнәләр икән. Интернетка да, компьютерына да ышанмыйлар, фәкать китапларга язалар, кешелекнең әле китаптан да озаграк саклана торган чыганак уйлап тапканы юк.

Татар балет сәнгатен өйрәнергә алынган Луиза Петрова үзе уноч ел белем биргән Казан мәдәният һәм сәнгать университетын яклап маташты. Хәзерге глобальләшкән заманда яшь хореографлардан универсал булу таләп ителә дип, татар биюе укытылмавын үзенчә аңлатмакчы булды. Ләкин Татарстан уку йортларында глобальләшкән дөнья өчен белгечләр әзерлибезме, әллә глобальләшү шартларында татар мәдәниятен саклап калу өчен тырышабызмы, дигән сорау туа.

Гомумән, кадрлар мәсьәләсе күпләрне борчый. Мәдәният һәм сәнгать университеты укытып чыгарган мәдәният менеджерлары, сәнгать белгечләре кая китеп олагадыр – билгесез. Г.Ибраһимов исемендәге институтның Тасвирый һәм гамәли бизәү сәнгатьләре бүлегендә хезмәткәрләрнең уртача яше – 53, театр һәм музыка бүлегендә – 52 яшь икән. Глобальләшүгә таба барган заманда милли сәнгать өчен көрәшү өчен беләкләрдә көч, егәр дә кирәк. Кая сез, 30-35 яшьлек белгечләребез?..

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Фатих Әмирхан иҗатын өйрәнәләр

Төркиянең Кастамону университетында Фатих Әмирхан әсәрләре буенча фәнни хезмәт язылган, ул якын көннәрдә китап буларак дөнья күрәчәк.

Яшь галимә Күбра Шәйма Айдын Фатих Әмирханның «Тигезсезләр» һәм «Яшьләр» пьесаларын анализлаган. Ул бу әсәрләрне иң элек төрекчәгә тәрҗемә иткән.

«Фатих Әмирхан әсәрләрен диссертациямнең темасы итеп фәнни җитәкчем Самәт Азап тәкъдим итте. Татарчаны үзлегемнән өйрәндем. Мин укыган университетта безгә татар теле дәресләре кермәде. Шунлыктан пьесаларны тәрҗемә итү җиңел бирелмәде», – дип сөйләде ул.

Галимә XX гасыр башында татар халкының театрга карашын, сәхнә әсәрләренең татар иҗтимагый тормышындагы әһәмиятен тикшергәндә 1926 елда «Төрек йорты» исемле төрек журналында чыккан хәбәрләрдән файдаланган. Анда әлеге елларда татар театр бинасы салу, татар театр мәктәбе ачу, татар опера театрын булдыру кебек театр сәнгатен борчыган мәсьәләләр телгә китерелгән.

Күбра Шәйма Айдын фәнни хезмәтендә шул ук басмада дөнья күргән Гаяз Исхакыйның «Шимал төркиләрендә театр» дигән мәкаләсеннән кайбер фикерләргә урын биргән, күренекле язучының XX гасыр башында татар театрының милли булырга тиешлегенә басым ясавын билгеләгән.

Күбра Шәйма Айдын хезмәтендә Фатих Әмирханның тормышы һәм иҗатын, пьесаларының сценарий төзелешен, персонажларын, экспозициясен, вакыйгалар үсешен, кульминациясен, чишелешләрен, диалогларын, театрның әдәбият белән мөнәсәбәтен анализлаган.

«Фатих Әмирхан – социалистик карашларын милли аң белән берләштергән язучы. Аның фикеренчә, милләте өчен хезмәт итүче һәркем, нинди карашка ия булуына карамастан, бергә эшли һәм яши торган бер дөнья ярата ала. Ул әсәрләрендә җәмгыятьнең алга баруына комачаулаган, алгарышына киртә булган бөтен әйберне иләк аша үткәреп, каләме белән җәмгыятенә юл күрсәтүче булган», – дигән нәтиҗә ясаган.

Рушания АЛТАЙ.

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ

Спрут заманы

(Дәвамы. Башы 5-7 нче саннарда).

Артур Александрович аны Яңа ел белән котлады, эшләренең барышы белән кызыксынды, бары тик Джиоев кына аңлый торган читләтеп сөйләү алымы белән әйтте: биредә аның койрыгына басып өлгергәннәр икән. Ул Мюнхенның «Бавария» стадионында үзе белән үзбәкчә сөйләшкән кешенең төс-кыяфәтен сурәтләп бирде. Аңа «кунакның» кем икәнлеген, иң мөһиме – аның артында кемнәр торганлыгын белергә кирәк иде. Костаның уйлавынча, Югары суд хезмәткәре Сәлим Хашимов йортында сүз нәкъ шул хакта барачак та.

Миршабның чакыруы ни өчен булуына карамастан, Коста аннан баш тарта алмас иде: ул Сәлим белән аның дусты сенаторның, үзен травматология институтыннан урлап китеп, төрмәдән коткарып калганлыкларын һәрвакыт исендә тота, ул аларга гомере буе бурычлы. Костаның хуҗасы Шубарин да алар булышлыгы белән генә сакланып кала алды: үтерелгән прокурор Азлархановның республикадагы һәм Мәскәүдәге, хәтта Кремльдәге бик зур түрәләр өстеннән җыелган үтә яшерен гаепләү материаллары-компромат салынган кейсын да Миршаб белән сенатор урлаган иде бит.

Коста Миршаб янына Шубаринның тыйнак кына ак «Волга»сы белән килде, әмма машинада «Вольво»ның дизель двигателе, Рәшидовның элекке машинасыннан алынган караңгы яшькелт, пуля тишә алмаслык пыялалары, ә дүрт ишеге автоматтан атуга да түзәрлек икәнлеген бик азлар гына беләдер. Шефының машинасы белән Джиоев күптән түгел генә файдалана башлады, хуҗасы Германиягә китәр алдыннан нинди дә булса шәп автомобиль алып кайтачагын әйткән иде – Ташкентта, көнләп түгел, дигәндәй, зиннәтле кәттә машиналар арта, ә сәүдә банкы хуҗасына башкалардан калышу килешми.

Коста машиналарны яхшы белә иде, шуңа күрә ул берничә шарт куйды: пуля тишмәслек пыялалары, бер булса да броня ишек, – илдә хәзер әнә ниләр генә булмый! Һәм, әлбәттә, кондиционер, аннан башка машина җәй көннәрендә Урта Азиядә әҗәл тагаргына әйләнә.

Бүгенгә кадәр Костаның әле Миршаб өендә булганы юк иде. Ул көмеш төсенә буялган авыр капка янында машинасын кычкыртуга, өйдә автоматика төймәсенә бастылар, авыр капка йомшак кына ике якка ачылып китте, бу ишегалдына шактый еш килеп йөргән машина эчкә үтте. Сәлим ишек төбендә көтеп тора иде инде, Коста җитди сөйләшү генә түгел, кичектергесез эшләр дә булачагына тагын бер кат ышанды. Хуҗа аны бизәлгән чырышлы зур зал аша туп-туры үз кабинетына алып кереп китте, анда ике кәнәфи арасындагы кечкенә өстәлдә кайнар чәй утыра, янәшәсендәге вазаларда -бераз карала-шиңә төшкәнрәк йөзем, кипкән җиләк-җимешләр, чикләвек, печенье – бик тыйнак һәм зәвыклы күренеш иде бу.

Кабинетка килеп кергәч, Коста күңеленнән генә Сенатор белән Миршабка да үзенең хуҗасы Шубаринның нинди уңай йогынты ясаганлыгын уйлап алды. Бик һәйбәтләп яңартылган узган гасырның зиннәтле җиһазы; дивар буена тезелгән китап шкафларының пыялалары аша борынгы фолиантлар янәшәсендә Кытай һәм Бенинның борынгы бронзалары, аларның бик рәтен белеп җыелганлыклары күренеп тора; төрле уенчыклар һәм немец фарфорына ясалган рәсем-күренешләр, Кузнецов һәм Гарднер заводларында эшләнгән, ватылырга гына торган рус фарфоры сыннары. Ә каршы яктагы яшел биллиард поставы белән тышланган диварга гаҗәеп матур алтынсу рамнарда биш-алты картина эленгән – болар һәммәсе ирексездән Шубаринның эш кабинетын хәтерләтә иде. Күрәсең, җирле таможня хезмәткәрләре Миршаб өчен чит илләргә китүчеләрне җитәрлек җилгергәндер, мондый диварны комиссион сатудан да таба алмыйсың.

Костаның хәл-әхвәлен, сәламәтлеген, кәефен сораштыргач, – ә шәрекъгә, нинди генә ашыгыч һәм мөһим сөйләшү булса да, шунсыз сүз башламыйлар, – Миршаб аңа «Лидо» ресторанында прокурор Камалов белән очрашканын, «матур-матур» сүзләр алышканнарын тәфсилләп сөйләп бирде. Коста үзе өчен көтелмәгән нәтиҗә ясады: Хашимов Мюнхен стадионында Артур Александровичның ниндидер бер якташ кеше белән сәер очрашуы турында бернәрсә дә белми икән...

Хашимов кинәт туп-туры бәрдереп сорады: бер атна эчендә прокурор Камаловны җитди генә пычратып буламы? Коста уйлап та тормастан җавап бирде – юк. Коста фикеренчә, бер генә юл кала – тегене, җәмгыятьчелекне кузгатмаслык итеп, тавыш-тынсыз гына юк итәргә кирәк – Камалов республикада танылган шәхес.

Сәлимгә ризалашырга гына калды, чынлап та прокурорны пычратып-буяп торырлык вакыт юк, бары шул бер чара гына... Ул, сүз уңаеннан гына, КГБ изоляторында утыручы Бармаксызга турында телгә алды. Прокурор Камалов кулындагы бу мөһим шаһитпан Сәлимгә дә, Артур Александровичка да, Костаның үзенә дә җеп сузылырга мөмкин…

Джиоев аның сүзләренә күңеленнән генә көлемсерәде. Ул Парсегянны яхшы белә: алар икесе дә законлы карак, димәк, тегесе моны беркайчан да сатмаячак. Коста ни өчен Арсенның Сенаторны гына тоттыруын да аңлап алды: утыртып куйгач, Сенатор туганнары һәм дуслары аша Миршабны өркетүне оештырачак, тегеңә исә ирексездән ярдәм итәргә туры килачәк – Югары судта эшләгәндә моны башкару катлаулы түгел. Бармаксыз дөрес юл сайлаган шикелле, әмма... Үзенең башында кайнаган уйларын ул чыгарып түкмәде. Джиоев тагын шунысын да төшенде: Парсегянның язмышы хәл ителгән, үзенең дә сайланып торыр чагы түгел – җавап тотар сәгать суккан. Кичә аның үзен коткарып калган булсалар, бүген Сенатор белән Миршабны ул коткарырга тиеш.

Коста дөрес уйлаган булып чыкты: Миршаб чынлап та Парсегянны юк итәргә кирәклеге турында сөйли башлады. Ләкин эш КГБга барып терәлә -аннан Бармаксызны эләктерү мөмкин түгел шикелле. Алар өч сәгатьтән артык төрле юллар эзләп утырдылар, әмма берсе дә барып чыкмас төсле... Инде китәргә генә җыенганда, Костаның башына кинәт бер фикер килде:

– Без баштa ук дөрес уйланмаганбыз, – диде ул. – Юкка гына КГБдан киңәшер кеше эзлибез. Хәтта шундый кешене тапсак та, ә бу бик катлаулы эш, ул, никадәр тырышса да, Парсегян янына үтеп керә алмаска мөмкин... Димәк, безгә Бармаксыз янына керердәй кешене КГБдан түгел, башка җирдән эзләргә кирәк... Әйтик, табиб яки мунчачы…

Үзенең әйбәт фикергә юлыкканын аңлагач, Джиоев яңадан кәнәфигә килеп утырды һәм бер өч минут дәшми торды. Миршаб бу тынлыкны бозарга базмады. Коста кинәт кенә сүрән тавыш белән: «Амин» – дип мыгырдап куйды, кулы белән мәгънәле генә хәрәкәт ясап алды: мөселманнар мәетне соңгы юлына шулай озаталар.

– Бетте, Парсегян килеп терәлде. Мин аннан ничек котылу юлын хәзер беләм инде, ләкин бер-ике атна бик яхшылап әзерләнәсе булыр...

– Яле, яле, аңлатып бир... – дип җанланды Миршаб.

– КГБның үз хезмәткәрләре өчен бик шәп медсанчасте бар, ул шәһәр үзәгендә, үзләренең төп биналарына терәлеп тора, тимер Феликс һәйкәле каршысында. Минем белүемчә, бөерләр авыруын тикшерү өчен кирәкле бердәнбер япон аппаратурасы бары тик шунда гына, шәһәрдә башка юк. Анда күпләр танышлык белән генә керә. Сездән шул таләп ителә: иртәгә үк медсанчастьнең баш табибенә шылтыратасыз да бөерләрегезне тикшерүләрен үтенәсез. Башка авыру-фәлән дисәгез, ышанмаслар. Сез бит шул аппараттан башка һәммәсе дә булган хөкүмәт поликлиникасында исәптә торасыз. Башымны кисәргә бирәм – нәкъ шулай. Сез медсанчасткә ике барып кайтырга тырышыгыз. Башта барып сөйләшкәч, анализларсыз гына барасыз, өйдә онытып калдырганмын, дисез – кыскасы, анда никадәр озаграк торсагыз, шулкадәр яхшы булыр.

Баруыгызның максаты – күбрәк табибләрнең фамилияләрен белешү, әйтик, ун-унике кешенекен. Бу миңа алар арасыннан кайсысының изоляторга керү мөмкинлеге барлыгын исәпләп чыгару өчен кирәк. Мин беләм, Парсегянның кышларын аяклары бик сызлый, радикулиты да көчле, төрмәдә ул төннәрен акырыпмы-акыра иде, аны камерадан конвойсыз гына чыгаралар. Ә калганын мин сез биргән исемлектән берәрсен сайлап алгач кына сөйләрмен. – Сүзе беткәнгә санап, Коста урыныннан кузгалды. Миршабның күзләреннән аңа да өмет уты үрләгән иде. Хуҗа аны озата чыкты. Машинасын кабызганда, Джиоев әйтеп куйды:

– Ә «мәскәүле» белән эш җиңел булачак – ул бит һаман да өченче катта ята, тәрәзәсе дә караңгы ишегалды ягына карый.

* * *

Яңа елның беренче эш көнендә үк Сәлим, иртән республика КГБсының медсанчасте баш табибенә шылтыратып, үзен тикшерү турында сөйләшеп килеште. Сөйләшүдән ул шуны аңлап алды, Костаның мәгълүматлары дөрес икән, поликлиникага барып кайтуы шик тудырмаска тиеш, хәтта сау-таза булсалар да, ул бөерләрен тикшертеп карарга хаклыдыр иҗ.

Медсанчастька барырга җыенгач, Хашимов пинҗәгенең эчке кесәсен капшап карады, анда һәрвакыт йөртә торган, шырпы кабы кадәр генә диктофоны бар аның, еш кына файдасы да тиеп куя. Бу юлы да көтмәгәндә генә диктофонның файдасы чыкты.

Медсанчасть ишек төбендә аңа әзерләп куелган пропуск тоттырдылар, вахтер баш табибнең кабинеты дүртенче катта икәнен әйтте. Хашимов, үзен беркем дә озатып тормаячагын белүгә, нишләргә кирәклеген төшенеп алды. Бу очракта аңа икенче кабат килеп йөрисе дә булмаячак, башка әгъзалары шикелле үк, аның бөерләре дә сәламәт иде.

Ул лифтка утырып өченче катка менде дә, кирәкле ишекне эзләгәндәй кыланып, озын коридор буйлап китте. Кабинетларның ишекләрендә табибләрнең нинди белгеч булуы, исем-фамилиясе, атасының исеме язылган иде. Хашимов пышылдап кына диктофонына, Коста сораганча, ун гына түгел, ә унсигез фамилия язып алды, дүртенче катта аларга тагын унике өстәлде. Хәзер инде баш табиб янына кереп йөрисе дә калмаган иде, әмма күңеле күтәрелеп киткән Миршаб, бераз уйлагач, шулай да кереп чыгарга булды. Соңыннан ул үзенә көтмәгәндә килеп туган уңышы турында кат-кат уйланды. Кабул итү бүлмәсендә озын чират тезелгәнен күргәч, ул борылып китәргә дә уйлаган иде, әмма аны нәрсәдер тыеп калды, түземлеге уңыш та китерде. Кыска гына әңгәмәләшеп, гадәттәге шәрекъчә бер-берсенә матур-матур сүзләр әйтешкәннән соң, баш табиб бу дәрәҗәле кунакны экспресс-анализга үзе озатып куярга булды. Миршаб бер ун минут кына элек буеннан-буена йөргән озын коридорга килеп кенә чыкканнар иде, аларны, гафу үтенеп, чик сакчысы формасындагы бер итагатьле офицер туктатты һәм ике генә минут көтеп торырга кушты.

Сәлим кайсыдыр табибнең кабинетыннан ике ир кешенең бергәләп чыгуын күреп алды, аларның берсе хәрби киемнән иде, алар коридорның аргы башындагы лифтка таба атлап китте, анда да погонлы бер кеше көтеп тора иде. Миршабның тәҗрибәле күзе бу ике кешенең берсе офицерга богауланганын абайлады – куркыныч җинаятьчеләрне шулай озатып йөриләр. Һәрвакыт салкын канлы булган Сәлим телдән калды: лифтка шундый сак белән алып барылган җинаятьче ул... Бармаксыз, ягъни Арсен Парсегян иде...

Бу хәл бер генә минут булгандыр, әлеге күренешкә игътибар итүче дә юк иде шикелле, әмма Сәлим аптырашта иде, аның үзен чеметәсе килеп китте – юк, ул ялгышмады: чал бөдрә чәчле арестант, һичшиксез, ул аулап йөргән кеше иде. Парсегянны алып чыккан кабинет яныннан узганда Миршаб хәтта үзе фамилиясен язып алган теш табибен дә күреп алды. Бәлки, дәшми генә калырга кирәк булгандыр, ләкин Сәлим түзмәде, телчән баш табибтән:

– Сездә кулда булган кешеләрне дә дәвалыйлармыни? – дип сорады.

– Юк, монысы очраклы гына, пациент, дөресен әйткәндә, безнеке түгел. Республика прокуроры аны безгә яшергән, диләр, ниндидер бик мөһим шаһит икән, күз карасы кебек саклыйлар. Бүген беренче алып килүләре бугай...

Шул көнне кич белән теш табибе әңгер-меңгердә эштән кайтып барганда, аңа арттан, юл читендә торган машинадан эндәштеләр:

– Ильяс Әхмәтович, утырыгыз, илтеп куям...

● Хәрби өйрәнүләр вакытында.

● Ш.Гыйниятуллин.

ГЕНШТАБТА – ТАТАР ГЕНЕРАЛЫ

Бөек Ватан сугышыннан соң СССР Кораллы көчләренең Генераль штабында байтак татар генералларының хезмәт итүе мәгълүм. Аларның иң күренеклесе – хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы, Хәрби фәннәр академиясе президенты армия генералы Мәхмүт Гәрәев. 1974 елдан ул – Генштабның Хәрби-фәнни идарәсе башлыгы вазифасында, тагын өч елдан – Баш оператив идарә башлыгы генерал-полковник Сергей Ахромеевның урынбасары. 1979 елдан Генштабның әлеге төп идарәсен армия генералы Валентин Варенников җитәкли. 1984-1989 елларда Мәхмүт Әхмәт улы Генштаб башлыгының фән һәм оператив эшләр буенча урынбасары вазифасында Советлар Союзы Геройлары, Советлар Союзы Маршаллары Николай Огарков һәм Сергей Ахромеев кул астында хезмәтен дәвам иттерә. 1974-1984 елларда техник фәннәр докторы, ГРУ генерал-лейтенанты Фирьяз Ханцеваров Генштабның Баш разведка идарәсенең Үзәк аппаратында эшли. 1985-1986 елларда тагын бер техник фәннәр докторы, генерал-майор-инженер Рафаэль Юсупов Оператив-стратегик тикшеренүләр үзәгенең Стратегик операцияләрне модельләштерү юнәлеше башлыгы кәнәфиен били. Кызыл Армиядәге хезмәтенең 20 елы хәрби разведка белән бәйле булган, Бөек Ватан сугышында укчы дивизия һәм укчы корпуслар белән командалык иткән хәрби фәннәр докторы генерал-майор Минзакир Әпсәләмов 1949-1959 елларда Генштаб карамагындагы К.Е.Ворошилов исемендәге Югары хәрби академиядә (1958 елдан – Генштабның Хәрби академиясе) өлкән укытучы булып хезмәт куя, ә аннары 1971 елга чаклы шул ук академиядә фәнни-тикшеренү бүлеге башлыгы, өлкән укытучы, консультант вазифаларын башкара. Халкыбызның каһарман улы Якуб Чанышев Генштаб академиясенең оператив сәнгать кафедрасында өлкән укытучы һәм төп курс башлыгы вазифаларын башкарып запаска чыга. Исемлектә Советлар Союзы Герое, генерал-лейтенант Мидхәт Салихов та бар. Милләттәшебез Генштаб академиясенең гаскәрләр белән идарә итү кафедрасында укыта, фәнни дәрәҗәсе – доцент. Яңа гасырда Генштабта хезмәт итүче иң күренекле татар хәрби эшлеклесе – генерал-полковник Хәлил Арсланов. Ул 2013 елдан алып 2020 елга чаклы РФ Кораллы көчләренең Баш элемтә идарәсе башлыгы – Генштаб башлыгы урынбасары вазифаларын башкара. Чөнки кертелгән тәртип буенча илнең өч төр гаскәрләренең (Коры җир гаскәрләре, Хәрби-диңгез флоты һәм хәрби-космик көчләр) элемтә гаскәрләре белән җитәкчелек итүче Баш элемтә идарәсе башлыгына бер үк вакытта Генштаб башлыгы урынбасары вазифасын башкару да йөкләнә. РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының авиациясен оештырган Казан егете генерал-лейтенант Рафаил Закировның 2014 елдан Генштаб башлыгының киңәшчеләр төркеменә әйдәп баручы аналитик вазифасына билгеләнүен ассызыклау да урынлы.

Ә менә ил язмышы сыналган Бөек Ватан сугышы елларында тагын бер татар генералы Шакир Гыйниятуллин Генштабта төрле җаваплы вазифалар башкарып үзен хәрби данга күмә. Милләтне данлаячак Шакир атлы малай 1895 елның 15 мартында Самара губернасының Бөгелмә өязенә керүче Керәшле авылында (хәзерге Оренбург өлкәсенең Төньяк районы) ярлы игенче гаиләсендә дөньяга аваз сала. Әлбәттә, патша армиясендә гренадер булып хезмәт иткән, олыгайган көннәрендә колхоз рәисе булып эшләгән чагында, авылдашларының гозерләрен җиткерү өчен Мәскәүгә барып Михаил Калининның үзе белән очрашып кайткан Нигъмәтулла абзый үз малаеның хәрби тормыш юлында үр арты үрләр яулаячагын һич кенә күз алдына китерә алмагандыр. Яшәү шартлары соң дәрәҗәдә авыр була аларның, нәкъ шул сәбәпле Шакир кечкенәдән авыл байларына батрак булып бил бөгә. Шуңа да карамастан, авыл мәдрәсәсенә сабакка йөрергә дә вакыт таба. Пенза губернасының Керенский өязеннән күченеп килүче татарлар тарафыннан 1830 еллар тирәсендә нигезләнгән һәм баштагы мәлләрне Аит атамасында йөргән Керәшле бик тиз үсә башлый. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә,1859 елда 98 хуҗалыктан торган авылда 800 кеше яшәгән, күркәм бер мәчет ислам нуры иңдереп торган. Ә инде Октябрь түнтәрелеше алдыннан мәчетләрнең саны өчкә җитүе һәм мәдрәсә дә булуы мәгълүм. Кызганыч, Совет хакимияте елларында авыл үсүдән туктый, ә инде Бөек Ватан сугышына киткән 350 ир-атның 195е яу кырында ятып калуы халык санының тәмам кимүенә китерә. Шуннан бирле Керәшле кечерәйгәннән-кечерәя бара: 1995 елда яңа мәчет сафка баскан авылда яшәүчеләр саны 2010 елда 423 кешедән артмый, халыкның 99%ы – татарлар.

Авыл мәктәбен тәмамлаган Шакир Гыйниятуллин эш эзләп Самара һәм Оренбург калаларына китә, ә аннары Ташкентка ук барып чыга. Биредә ул патша армиясенә мобилизацияләнә һәм 1 нче Себер укчы полкында хезмәт итә. 1918 елның февралендә үз иреге белән Кызыл Армия сафларына баскан егет Ташкенттагы кызыл командирлар әзерләүче мәктәпне тәмамлый һәм тормыш юлын хәрби хезмәткә багышларга карар кыла. Әүвәл ул 2 нче Төркестан укчы дивизиясе составындагы полкта эскадрон белән командалык итә. Бу – Гражданнар сугышының утлы өермәсе Урта Азияне дә чолгап алган чор. Баштагы мәлне бар да Төркестан республикасы армиясен төзү белән бәйле хәл-вакыйгаларга барып тоташа. 5 миллионнан артык халык яшәгән һәм башкаласы Ташкент саналган Төркестан совет федератив республикасы 1918 елның 30 апрелендә оеша, ул – РСФСР составындагы беренче автономияле республикаларның берсе. Тарихи гаделлек өчен, Урта Азиядә беренче Төркестан автономиясе (28.11.1917- 22.02.1918) турында 1917 елның 26-29 ноябрь көннәрендә мөселманнарның Коканд каласында узган IV гадәттән тыш съездында игълан ителүен ассызыклау мөһим. Хәзерге Үзбәкстан, Казахстан һәм Кыргызстан территорияләрен биләгән Төркестан автономиясенең 12 кешедән торган Вакытлы хөкүмәтен әүвәл казах милләтеннән булган Мөхәммәтҗан Тынышбаев җитәкли, бераздан аны үзен кыпчак дип игълан иткән Мостафа Чокаев алыштыра. Безнең өчен шунысы әһәмиятле: автономия хөкүмәте рәисенең урынбасары Ислам Шаһиәхмәтҗанов белән хәрби министр вазифасындагы патша армиясе полковнигы Мәгъди Чанышев – татар милләтеннән. 1918 елның гыйнварында Чокаев Советлар хакимиятен тану турындагы ультиматумга каршы җавап бирә. Нәтиҗәдә, Төркестан автономиясен тар-мар итү өчен прапорщик Константин Осипов җитәкчелегендә Мәскәүдән 11 эшелон гаскәр килә. Тарихчылар Кызыл Армия гаскәрләре сафында килгән кораллы әрмән дашнаклары отрядларының да автономияне туздыруга зур өлеш кертүләрен раслый. Мәскәүдән килгәннәрнең җәзалау нәтиҗәсендә меңнәрчә гаепсез кеше һәлак була, 22 февральдә яшәүдән туктаган автономияне Совет Төркестаны республикасы алыштыра. Ә инде 2,2 млн халкы булган Бохара Халык совет республикасы Бохара әмирлеге туздырылганнан соң, 1920 елның 2 сентябрендә барлыкка килә. Яңа дәүләт 11 көннән РСФСР белән килешү төзи һәм фәкать 6 октябрьдә генә аның рәсми рәвештә гамәлгә куелуы турында игълан чыга.

Шакир Гыйниятуллин шушы республикаларның армияләрендә 1928 елга чаклы хезмәт итә. 1920 елның маеннан ул – 1 нче Үзбәк бригадасының уку командасы башлыгы һәм шул ук бригада составындагы 2 нче кавалерия полкы командиры. 1921 ел башыннан 3 нче Төркестан укчы дивизиясенә керүче 2 нче аерым кавалерия полкы командиры ярдәмчесе вазифасын башкара. Милләттәшебезнең хәрби карьерасында Бохара республикасы оешу аерым урын алып тора. Республиканың армиясен төзү ихтыяҗы көн кадагына менгәч, Бохарада кавалерия һәм укчы полклар оештыру турында карарга киленә. 1922-1924 елларда шактый бай хәрби тәҗрибә туплаган Гыйниятуллинны 1 нче Бохара кавалерия полкына 1 нче эскадроны командиры итеп күчерәләр, аннары ул 1 нче Бохара аерым кавалерия полкы командиры ярдәмчесе һәм командиры вазифаларын башкара.

Әлбәттә, Шакир Гыйниятуллинга сугыш хәрәкәтләре тынып тормаган шул катлаулы заманда хезмәт итүләре бер дә җиңелләрдән булмый, ул әле хәтта еш кына шәхси тормышында да авыр сынауларга, кайгы-хәсрәтләргә юлыга, хәрби карьерасында түбән тәгәрәгән чаклары да билгеле. Мисал өчен, полк командиры вазифасыннан кабат эскадрон командирына кадәр «төшерелүе»нең үз сере бар. Гаиләсе белән вакытлыча яшәгән кышлакка төнге һөҗүмнәре вакытында басмачыларның уллары Рөстәмне үтерүен Шакир Гыйниятуллин авыр кичерә. Йөрәгендәге ярсулы хисләрне тыеп кала алмый, үчен кышлакка һөҗүм иткән һәм әсир төшкән дошманнарыннан ала. Моның өчен суд каршына баса һәм «әсир төшкән басмачыларга карата тупас мөнәсәбәт күрсәтүе» өчен Төркестан фронтының Хәрби-революцион трибуналы тарафыннан, җәзаны шартлы рәвештә үтәү шарты өчен 6 айга хөкем ителә.

(Дәвамы киләсе санда).

Рәис ЗАРИПОВ.

КӨЛӘЧ ЙӨЗ

Гадәттә артист халкы беркадәр хыялыйрак, акварель буяу белән ясаган сурәт итеп күз алдына килә. Алар нәфис, өрфиядәй үтә күренмәле... Ләкин миңа майлы буяулар белән ясалган сурәтләр дә бик ошый. Куе жете төсләр. Кинәнеп, җәелеп, батырып сылаган төсләр байлыгы. Андый сурәтнең мәгънәсе еракка китеп караган саен ныграк аңлашыла.

Татарстанның атказанган артисты Римма Гыйззәтулла кызы Гайсина – икенче сурәттәге образ. Андый артистларны «кызыклы фактура» диләр. Янып, елмаеп торган күзләре, үтәли карашы, көләч иреннәр. Кыл урталай аерып тараган чәч.

– Зәй районының урман эчендәге Суык Чишмә атлы кечкенә авылында туып-үстем. Авылда өч класс укыгач, башта бер, аннан икенче авылда, аннан Зәй интернатында укыдым. Сигезенчене бетергәч, кая барырга икән дип йөргәндә, Алабуга училищесының хореография бүлегенә кердем. Тиктормас идем, биюче. Төрле конкурсларда катнашам. Укып бетергәндә, мине Әлмәткә чакырдылар һәм мин Горький клубында эшләп калдым. Шунда ике ел үтте.

Тормышта очраклылык булмыйдыр ул. Сәбәпсез сәдәп тә төшми, диләр бит. Җырчы Зөфәр Хәйретдинов концертларындагы биюче кызның нindидер сәбәпләр белән катнаша алмавы биюче Римманы драма артисты ясап куя. Театрга эшкә керергә гариза да язмаган килеш ул Чаллыга гастрольләргә чыгып китә.

– Әлмәт театрында артист булырга хыялланмаган бердәнбер артисттыр мин, – ди ул, елмаеп. Әйе, аның артист булып театрга килүенә өйдәгеләр дә сүз әйтми.

– Артист булуыма каршы килмәделәр. Гомумән, миңа каршы килеп буламы икән? Мин бит төпчек бала...

Шулайдыр, кечкенә авылда үскән кызлар шундыйрак буладыр. Кирәксә – атта, кирәксә – велосипед, мотоциклда... Алар булдыра.

– Төпчек бала – йомышчы бит инде ул. Күрше апага оеткыга да керәсең, иләккә дә, чиләккә дә дигәндәй. Сөйләшә белү дә кирәктер йомыш өчен. Интернат та кешене шомарта. Кечкенә чактан ук мөстәкыйль тормыш бит. Интернатта без бер авылдан дүртәү идек. Авылда без ахирәтләр түгел, әмма интернатта бездән дә якын дуслар юк иде.

Театр дигән сихри дөньяда үз урынын табарга шул сыйфатлары ярдәм итә аңа. Артист булырга хыялланмаса да, язмыш аны юкка гына театрга китермәгән бит. Нинди генә роль булуга карамастан, ул аны җанын–тәнен биреп өйрәнә. Режиссерлар, остазлары биргән һәр киңәшен тыңлый.

– Профессиональ актер булмаган килеш театрда авырга туры килдеме?

– Укытучыларым әйбәт иде. Зәкия апа, Дамира апа, Камил абый, Луиза апалар. Алар бит үзләре бер мәктәп. Аларның һәр сүзе, һәр хәрәкәте минем иҗат касәмә бер тамчы ширбәт булды.

– Олылар, ярый, хәерхаһлы. Син инде алар өлешенә үрелмисең. Алар яулыйсын яулаган. Әле бит яңәшәдә артистлыкка укыган яшьтәшләр дә бар. Алар ничек карады, «тешләмәделәрме».

– Мин бит интернаттан, тирем калын иде, – ди Римма ханым, көлеп.

Әйе, ул андыйларга җавап та кайтарып тормый, вакыт сарыф итми. Ул читтән торып театр училищесын тәмамлый. Ләкин театрда өлкән буын биргән мәктәп аны чын артист буларак формалаштыра.

– Иң беренче уйнаган ролегез нинди булды?

– Дамира апа Кузаева Данил Салиховның «Алла каргаган йорт» әсәрен куйды. Шунда миңа Зилә Саматовна ролен тапшырды. Аны укуга, башта утырып еладым. Карчыга оясын җиңә торган яшь хатын бит инде ул. Дамира апа мине үзе белән дублер итеп алды. Дамира Кузаева бер фикердә генә сөйләшә торган кеше түгел иде. Яшьлеккә хас үз–үзеңә ышану, яшьлек энергиясе мине шул рольгә кертеп җибәрде. Ул уңышлы барды.

Театрда узган 30 ел гомер. Азмы ул, күпме? Моңа төгәл җавап юктыр. Шул еллар эчендә кемнәр генә булып сәхнәгә чыкмаган? «Мәхәббәтем минем»дә Энҗе, «Безнең авыл кызлары»нда Зәйнәп, «Сөясеңме, сөймисеңме?»дә яшь Фатыйма, «Күк капусы ачылса»да Шәмсия. Һәркайсының үз язмышы, үз йөзе. Ләкин алар арасында да җанга якын, синең бөтен барлыгыңны биләп алганнары була. Фоат Садриевның «Безнең авыл кызлары»ндагы Зәйнәп – шундыйлардан. Римма-Зәйнәп хисләр тирәнлегенә чумып, эчке дөньясын икесенекен бер итеп яши әлеге рольдә.

Әлбәттә, һәр артистка хас булганча, Римма ханым да характерлы рольләрне яратып эшли. Аның өчен эзләнү, образны формалаштыру, аңа ит үрдерү, җан өрү процессы кадерле. Ул аны утырткан үсентеләренең шытып чыккан вакыты белән чагыштыра.

– Үзегезгә ошамаган рольне уйнарга туры килдеме?

– Туфан Миңнуллинның «Исәнмесез»ендә Антонина. Дублерым уйнаганда, аны карарга бик ярата идем. Бу образ минем җанга ятмады.

– Театрда дуслар буламы?

– Миңа калса, якын кешеләр буладыр. Мин әле шушы яшькә җитеп дусның нәрсә икәнен аңлап бетерә алмыйм, ахры. Ике кеше турында әйтә алам, берсе Гөлнара Кәшипова, икенчесе Зөлфия Газизова. Безнең арада нindидер бәйләп тора торган җепләр бар. Дөрес, без озак күрешмәскә, сөйләшмәскә дә мөмкин. Мин алардан үземә якынлык тоям. Аларга рәхмәтлемен.

● Н.Исәнбәт. «Качаклар». Сания. 2016 ел.

● И.Юмагулов. «Мәхәббәт кошлары». Сәрия. 2000 ел.



● Ф.Садриев. «Безнең авыл кызлары». Зәйнәп. 1995 ел.

●Г.Камал. «Банкрот». Гайниҗамал. 2010 ел.

●Ж.Б.Мольер. «Әҗәлгә дару бар диләр». Мартина. 2017 ел.

●К.Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар». Гөлнур әби. 2007 ел.

ИЯСЕ

● К.Тинчурин. «Назлы кияү». Нәгыймә. 2011 ел.

● Т. Миңнуллин. «Гөнаһсыз гөнаһлылар». Рәмзия – Римма Гайсина, Хәбир – Ф. Зарипов. 1998 ел.

● М.Кәрим. «Кыз урлау». Иркәбикә. 2006 ел.

Ул бервакытта да югалып калмый, эшсез утырмый. Хореограф буларак балалар бакчаларына, мәктәпләргә чакыралар аны.

– Нәрсәне эшләргә батырчылыгыгыз җитмәс иде?

– Сатучы була алмас идем, әйбер сата белмим. Бушка биреп бетерергә мөмкинмен.

– Сез алган иң кыйммәтле бүләк?

– Аллаһның бүләге – ул минем кызым. 4-5 яшендә бакчадан 8 Мартка миңа натюрморт ясап кайтты. Аны һаман да саклыйм. Ул бик кадерле, җылы истәлек.

– Балачак хыялыгыз тормышка аштымы?

– Ашты. Кечкенә чакта мәктәбе булган зур авылда яшәсәм иде дип хыяллана идем. Менә хәзер үз йортыбыз белән Иске Әлмәттә яшибез.

Чын, эчкерсез, «әртисләнми» генә аралашу. Гадилек, үҗәтлек, кыюлык тышкы кыяфәттә чагыла. Андагы яшәү көче этеп-төртеп тышка бәреп тора. Гафу... аңа карагач, хәтта үзеннән-үзе елмаясы килә. Җырдагы кебек, эчендә магниты бардыр, үзенә тартып тора...

Театр – ул сәнгать дөньясы дисәләр дә, мин аны табигать дөньясы белән чагыштырыр идем. Ул табигый, чын дөнья. Тукранбашлар, ромашкалар, ачы әрем, шайтан таягы, күкчәчәкләр, чыпчык күзе – тагын әллә нинди җанга якын чәчәк-үләннәр үскән бер болын. Римма ханымда шул урмандагы табигый гүзәллекнең тулы гәүдәләнеше яши төсле.

Рәфкать ШАҺИЕВ.

Сукыр хәзрәт һәм изге абыстай

Аpаның күңелендә бары бер уй, бер теләк: «Суык сөягеңне генә булса да таба алсам иде, Фәйзияздан балам… Бөреләнеп тә чәчәк ата алмаган гөлем бит син… Каберецне эзләп килдем, балам».

Петербург каласыннан ерак Галиция җирләрендә баласының каберен эзләгән татар хатынының исеме Мәүдүдә иде. Аның тормыш юлын ерактанрак башлыйк.

Петербургның Волков татар зираты капкасыннан кергәч тә, аерымрак торган җыйнак кына бер кабернең ташына: «Бу кабердә мәдфүн Коръән-хафиз Садретдин Сәйфетдин угылы. Вафаты 1935 елның 6 октябре» дип язылган һәм яшәгән еллары күрсәтелгән: «1863–1935».

Коръән-хафизның шәһәрдә үз буыны, якын туганнары калмаса да, кабер тирәләре һәрвакыт чиста, пөхтә итеп җыештырыла, янына утырып дога кылучылар да өзелеп тормый икән. «Ачык йөзле, керсез күңелле кешеләр гел игътибар үзәгендә булган кебек, кабер дә зиярәт кылучыларны гаҗәеп бер серлелеге белән үзенә тартып тора», — дип сөйли шәһәр кешеләре. Садретдин хәзрәтнең Казанда яшәүче оныгы, филология фәннәре кандидаты Зөлфә ханым Усманова белән танышу хәзрәтнең тәрҗемәи хәлендәге сорауларны ачыкларга ярдәм итте. «Мәшһүр кешеләрне оныткан халык сакланмас», — дип кисәтә бөек галимебез Ризаэтдин Фәхретдин. Шуны истә тотып, хәзрәтнең гаиләсе хакында халыкка ирештерү мәгъкуль.

Садретдиннең нәсел чылбыры Екатерина патша заманындагы рус-төрек сугышында русларга әсир төшкән сигез төрек офицерының берсе — полковник Нурмөхәммәттән башлана икән. Әсирләргә ул чакта морза дигән дәрәҗәле исем һәм Хан Кирмән (Касыйм) шәһәре тирәсендә җир дә бүлеп бирелгән. Гаилә корып, Россиядә яшәп калган Нурмөхәммәт нәселеннән зур гына дәрәҗәле кешеләр чыккан. Патша хезмәтендә аларның күбесе офицер чинында булуы мәгълүм. Садретдиннең үз әтисе Сәйфетдин дә Петербургта кырык биш ел буе гаскәри мәзин вазифасын башкарган.

Садретдингә биш яшь тулганда чәчәк авыруы эләгә. Тәмам тазарып җиткәндә, өйләренә кергән бер кеше: «Абау, мондый авырудан балалар сукырая бит», – дип сабый өстенә әйтә. Шул сәгатьтән бала чынлап та авырый башлый. Күп тә үтми, мәңгелеккә дөнья яктысын күрүдән мәхрүм кала. Шөкер, Ходай баланы зирәк зиһен, сәләт, тырышлык кебек күркәм сыйфатлардан мәхрүм итмәгән икән. Ул әкренләп әтисеннән сабак ала башлый. Улының искиткеч хәтеренә ышанган ата аны 10 яшендә Әстерхан каласындагы үзе бик хөрмәт иткән атаклы Габделваһаб хәзрәткә укырга бирә. Ят җирләрдә әти-әнисеннән башка яшәү күзле балага да гаять кыен. Садретдин сәләтле генә түгел, талантлы да икән! 15 яшендә Коръәнне яттан өйрәнеп, хафиз дәрәҗәсенә ирешү белән бергә, астрономия, фәлсәфә, медицина кебек дөньяви фәннәрне дә нык сукалый башлый.

● Садретдин хәзрәт.

● Мәүдүдә абыстай.

Әстерханга ул тагын берничә тапкыр бара әле. Һаман эзләнә, алган белемнәрен арттыру, яңаларын өйрәнү юнәлешендә максатчан эшли. Татар, рус, гарәп, фарсы, төрек телләрен үзләштерә, фәкыйһ (дини белгеч), мөгаллим, имам булып җитешә.

Фикъһ, ягъни Коръән-Кәрим вә Сөннәт шәрифә күрсәтмәләре җирлегендә яшәеш һәм көнкүреш кануннары, башкача әйтсәк, шәригатьне оештыручы вә гамәлгә ашыручы гыйлемне Садретдин исламиятнең бер могҗизасы итеп саный. Аның фикерен, хөкемнәрен сабакташлары, хәлфәләре сокланып тыңлый.

1885 елда имам-хатыйб, мөдәррис дәрәҗәсе алып, Петербург мәчетендә эшли башлый. 1895 елда пайтәхетнең гвардия корпусы мулласы (ахун) вазифасын алу өчен биш кеше арасындагы сайлауларда катнаша. Җиңеп чыга, тик ике елдан бу эштән китәргә мәҗбүр була. Сәбәбе — сукырлыгы. Чөнки гаскәри муллалар үз вазифаларын башкалада гына түгел, бәлки Псков, Новгород, Красное Село һәм Финляндия җирендәге гарнизоннарда да башкарырга тиеш була. Садретдин шәһәрнең икенче, өченче мәхәлләләрендә мулла вазифасын башкара башлый. Петербургның Җәмигъ мәчетен салганда да ул актив катнаша, төзү комиссиясе әгъзасы була.

Егерме биш яшендә ул инде башлы-күзле булырга тели. Дусларына мөрәҗәгать итеп: «Күземнең сукырлыгын яшермичә, авыл кызын димләгез», – ди. Дуслары аның гозеренә колак салып, хәзерге Балык Бистәсе районына кергән Югары Тегермәнлек авылының Баһаветдин мәзин кызы, 18 яшьлек Мәүдүдәне димли. Мәүдүдә – заманына күрә яхшы гына белем алган, акылы һәм уңганлыгы белән яшьтәшләре арасында аерылып торган зифа буйлы, көр күңелле кыз: «Егетнең күңел күзе күрсә, миңа шул җиткән», – дип ризалаша. Әтисе дә кызының карары ныклыгын аңлап: «Үзең хәл ит инде, балам», – дип ризалыгын бирә.

Садретдин Мәүдүдәне Ходай бүләге рәвешендә кабул итә, матур гаилә төзелә. «Никах мәҗлесеннән соң һәр икемез укыту илә шөгыльләндек», – дип искә ала хәзрәт бу хакта. Иркен генә фатирга чыгып, Садретдин ир балаларны, Мәүдүдә кыз балаларны укыта башлый. Алар ачкан мәдрәсә пансион тибында була.

Дини һәм дөньяви гыйлемнәрне бер дәрәҗәдә мөһим саныйлар. Шуңа күрә дини фәннәр белән бергә математика, география, астрономия, логика, медицина, рус һәм татар телләре укытыла. Укыту ысулларын сайлаганда, мәдрәсәнең эчке мохите хакында да ныклап уйланыла. Мәдрәсәдә елдан-ел шәкертләр саны арта бару, башкала яшьләреннән тыш, чит шәһәрләрдән, ерак калалардан килеп укучылар күбәю шул хакта сөйли. «Ерактагылары өебездә торып, якындагылары йөреп укыды, – дип искә ала хәзрәт. – Шуларның тәрбия вә хезмәтләренә абыстаем мөкәммәл итте. Укытуыбыз инкыйлабкача дәвам итеп, көндез балалар, кичләрендә зурлар – сәүдәгәрләр, хезмәттәгеләр укыды, һәр икемез төрле авырлыкларны күтәреп, иҗтиһат кылып укыттык».

Садретдин хәзрәт шәкертләренә дә, мәхәллә халкына да дини, дөньяви вә тарихи темаларга, һәм дә ата-бабалардан калган гореф-гадәтләрне саклау, халык арасында таралган бозыклыкларны бетерү турында тирән эчтәлекле вәгазьләр сөйли. Аның тәрбияви вәгазьләрен аеруча яратып тыңлыйлар. «Баланы нечкә җирләреннән үпмәгез (эч, бит, ирен, корсак, арт тирәләрен). Бу гадәт балада вакытыннан элек женси хисләрне уятуга китерә», – дип өйрәткән ул ата-аналарны.

Садретдин хәзрәт талантлы педагог була. Аның киңәшләре бүген дә кыйммәтен югалтмаган. «Бер онытылганны кабат хәтергә төшерү яңаны бар кылудан да авыррак, хәтерегезне тәрбияләгез, саклагыз», – дип кисәтә торган булган ул шәкертләрен. Хәзрәт берничә дини хезмәт тә яза. Безгә мәгълүмнәреннән – «Әүрадел мотыйгыйн» («Аллага ышанучылар») рисаләсе. Ул 1906 елда «Нур» нәшриятында дөнья күрә. Кульязма хезмәтләре, архивы Ленинград блокадасы вакытында, йортларына бомба төшеп, юкка чыга.

Садретдин белән Мәүдүдәнең унбер баласы туа. Шуларның бишесе яшьли үлеп, алтысы (ике ир, дүрт кыз балалары) исән кала. Бу олуг затлар үз балаларын милләт җанлы шәхес итеп тәрбияләргә тырышкан.

Әмма балалары дөньяга килә башлагач, Мәүдүдәгә шәкертләр тәрбияләү кыенлаша. Аңа ярдәмгә сеңлесе Мәһитап килә һәм кырык яшенә кадәр бу гаиләнең иң ышанычлы таянычы була. Аннан соң Мәһитап күренекле мәгърифәтче Фатих Халидинең бертуган энесе, Казанның Зәңгәр мәчете имамы, биш баласы белән тол калган Ибраһим Халидигә кияүгә чыга. Ибраһим хәзрәт – татарның олы бер буыны сокланган атаклы артисты Фуад Халитовның әтисе була. Олы кызлары Гөлгамбәр, әнисе мәдрәсәсендә белем алганнан соң, рус кызлары гимназиясендә укый, Бестужев курсларына языла. Петербургта укучы мөселман яшьләре түгәрәкләренә йөри. Олуг әдибебез, сәясәтчебез Гаяз Исхакыйның шәһәрдә югары белем алучы татар яшьләре белән бергә төшкән фотосында Гөлгамбәр дә бар. Алдынгы яшьләр еш җыелган Садретдин хәзрәт йортына Исхакый да килеп йөргәндер, шәт...

1902 елда туган Гөлбәһиҗәләре дә төпле белем алуга ирешә. Гимназия тәмамлаганнан соң Көнчыгыш институтына укырга керә, атаклы ориенталист академик Игнатий Крачковскийның шәкерте була.

Фәйзиздан исемле улларын Истанбулга белем эстәргә хәзрәт үзе илтә. Үз эшенең дәвамчысы булыр дип өметләнә. Фәйзиздан бик өметле, сәләтле бала була. Тик укуын тәмамлап кайткан егеткә солдат каешы буарга язган икән. Аны 1914 елны башланган Беренче бөтендөнья сугышында катнашырга мәҗбүр итәләр. Күп тә үтми, кайтуын үт йотып көткән улларының һәлак булуы хакында кәгазь килеп төшә. Бу 1917 ел була. Сукыр ата ачы хәсрәтен баласына багышланган бәет юлларында теркәп калдырган. «Хатирә» дип аталган бәеттә мондый юллар бар:

Дәрес алды Истанбулда,
Исеме Фәйзиздан иде.
Шулай зур михнәт чигәргә,
Ахры, Ходай язган инде.
Күркәм иде буе, төсе,
Күргәннәр соклана иде.
Ишеткәндә кыйраәтен
Күңелләр шатлана иде.

Анасы Мәүдүдә тирән кайгыга төшә. Бәгырьләре өзелгәнгә чыдый алмыйча, йөрәк жимешенең каберен зиярәт кылырга җыена. Тик ничек барасы соң? Кулда тәгаен адресы да юк. Өстәвенә, рус телен дә белми, сугыш вакыты, фронт ягына юллар ябык. Әмма ананың изге гамәленә, йөрәк ихтыяҗына каршы торырлык киртәләр юк икән, Мәүдүдә ихтыяр көчен җыеп, сугыш тарафына юлга чыга.

Тормышта кайчак кешеләр кылган гамәлләрне гадәттәге бизмән белән үлчәп-аңлатып булмый торган хәлләр туа. Ана газиз улы хезмәт иткән частьны эзләп таба. «Ходай Тәгалә ананың изге юлына мәрхәмәтен, изге догасын иңдергәндер», – ди оныгы Зөлфә ханым. Командир Мәүдүдә апаның йөрәк ачысын аңлап, улы күмелгән җиргә барырга рөхсәт итә, булышырга ике солдат бирә. Бүгенге аналарның кайгысына битарафлыкны искә алсак, кеше ышанмаслык хәл бу!

Солдатлар беренче каберлекне ачуга, Мәүдүдә абыстай һушыннан яза. Аңына килгәч, изге догаларын укый-укый, ачылган кабергә төшә. Туганнар каберлегә дип аталган бу чокырдагы ярым-йорты гәүдәләр, кисәлгән башлар, канлы шинельләр арасыннан аягындагы билгесе – миңе буенча улын эзли. Каберлекләрне ача торалар, ана һәр гәүдәне үз куллары белән тәртипләп, турылап сала бара. Ниһаять, соңгы – алтынчы каберлектән табып ала ул газиз баласын…

Аңа берсе цинк, икенчесе агач табут кирәклеген аңлаталар. Ниһаять, баласын табутка салып, товар вагонына урнаштыра, юлда бер ай вакыт уза. Кайткач, канәфер сулары белән мәетне юып, җеназасын мәчеттә укып, мөселманча җиргә иңдерәләр...

Совет хакимияте урнашу белән, Садретдин белән Мәүдүдәнең меңнән артык шәкерткә белем биреп чыгарган мәдрәсәләре ябыла. Хәзрәтнең Тибет медицинасын яхшы белүе, кешеләрне дәвалавы көн күрергә ярдәм итә. Шәкертләре дә онытмый, гел ярдәм кулы сузып тора. Чөнки алар Садретдин белән Мәүдүдәне изгеләр рәтендә йөртә.

Киров үтерелгәннән соң, Садретдингә «хокуксыз» дигән статус бирәләр. Балаларына югары мәктәп ишекләре ябыла. Өйләренә гел тикшерү кертеп, ГУЛАГ белән яныйлар, паспортларын тартып алалар. Мәгәр югары органнарда эшләүче үз шәкертләре хәзрәткә хокукларын кайтаруда ярдәм күрсәтә. Алар булышлыгы белән документлары да кайтарыла, хокуклары да торгызыла. Әмма гомер буе кешеләргә карата яхшылыктан башканы белмәгән олы йөрәкле шәхес бу хәлләргә түзә алмый инде: җитмеш икенче яшендә гомере өзелә.

Садретдин хәзрәтне күреп белгән, сабакларын алган кешеләр аның игелекләре хакында телдән-телгә, буыннардан-буынга сөйләп, исемен мәңгеләштергән. «Петербург татарлары» китабының авторы Даут әфәнде Әминов та хәзрәт хакында туганнарыннан ишетә. Ә тормыш юлын якыннанрак өйрәнгәч, «бөек пассионарий» дигән бәя бирә.

Садретдин белән Мәүдүдә абыстайның исән калган икенче уллары Лотфимөгыйн 1941 елгы сугышка китә. Ополчениегә эләгә, августта инде вафат хәбәре дә килеп җитә. Анага бу югалтуны да күтәрерлек көч кайдан килсен?.. Шул кырык беренче елны ул да бакыйлыкка күчә.

Тәэминә БИКТИМЕРОВА.

Бакчада ана теле ни хәлдә?

Балалар бакчаларындагы тәрбиячеләр татар теленә карата дәүләт тарафыннан игътибар кимегән саен туган телдә тәрбия бирү мотивациясе кими дип белдерә. Алар да, татар теле укытучылары кебек, 2017 елдагы вакыйгаларның кайтавазын сизә.

Казан мэриясенең Башкарма комитеты моңа кадәр дә татар теле укытучыларын туплап, аларга телне укытуның яңа алымнары нинди булырга мөмкин дип семинарлар уздырды, төрле мөгаллимнәр үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклашты. Татар теле укытучылары ул вакытта мондый чаралар мөһим, әмма алар 2017 елда кешеләрнең телгә карата кызыксынуы югары, укытучыларга теләктәшлек булганда ук кирәк иде дигән фикер белдергәннәр иде. Бу юлы эш балалар бакчаларында эшләүчеләр белән дәвам ителде. Казанда 327 балалар бакчасы бар, шуларның 85 е татар бакчасы булып санала. Араларында кушылма, татарча, русча тәрбия эшен дә алып барган бакчалар бар, аларда аерым татар төркемнәре булдырыла. Дөрес, балалар саны җыелган очракта. Саф татар балалар бакчалары саны кимеп бара, Казанда күбрәк ике телле төркемнәр булдырып эшлиләр.

Семинарда катнашучылар саны 400дән артты, алар арасында тәрбиячеләр, бакча мөдирләре һәм методистлар иде. Килүчеләр алдында дәүләт һәм хосусый татар балалар бакчалары тәрбиячеләре чыгыш ясады. Күпләр ничек рус теленә күчмәскә, татар телендә нинди уеннар барлыгын, ни рәвешле татар теле дәресендә күбрәк татар сүзләрен өйрәнү турында сөйләде.

Назлыгөл Нәкыйпова Казанның Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе каршындагы «Мәрҗан» балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Яшь белгеч. 2017 елдагы вакыйгалар вакытында белем алган чагым, татар теленә карата басым булганда да татар теле белән бәйле һөнәремнән баш тартырга теләк тумады, дип әйтә ул. Аның фикеренчә, татар тәрбиячеләренә методик кулланмаларның төрле булмавы, балалар өчен уеннарның аз һәм сыйфатсыз булуы авырлыклар тудыра.

– «Мәрҗан» балалар бакчаларына татар телендә сөйләшүче балалар яки балалары татарча сөйләшсен дигән теләк белән янган әти-әниләр белән эшләргә туры килә. Шуңа күрә, татар теле күп, русча да өйрәтегез, рус телен белми кала дигән дәгъвалар белдерүчеләрне күргәнем булмады. Ягъни ата-аналар нинди бакчага килгәнен аңлый, белә, таләпләр белән таныш, — дип сөйли ул. – Рус телле балалар бар, милләте белән рус булучылар да бар, әмма ата-аналарының балаларын татарчага өйрәтү теләге бар икән, бернинди каршылык була алмый. Гадәттә бер бала русча сөйләшсә, балалар да, тәрбияче дә аңа иярә. Аңламый дип русча аңлата. Әмма безнең принцип — тулысынча тел мохитен булдыру. Бала тора-бара күнегә ул. Принципиаль рәвештә, әмма дустанә мөнәсәбәт булганда, бала бик тиз тәрбияче нәрсә әйтергә теләгәненә дә, дуслары нинди уенга чакыруына да төшенә. Татарча гына сөйләшәбез дип кисәтеп тору кирәк. Минем шундый тәҗрибә булды, бала русча гына сөйләшә, әти-әни дә татарчаны авырдан сукалый, әмма ахыр чиктә, бер ел эчендә бала татарча сүзләр дә өйрәнде, үзенә кирәклеген аңлата да ала иде. Дәрестә иң беренче булып җавап бирә. Белмәүчеләр, киресенчә, күбрәк уңышка ирешә.

Методика төрле, кулланмалар күбрәк булган саен тәрбиячегә җиңелрәк. Әлегә телне өйрәтәм диюче белгечләргә бер-берсеннән өйрәнергә, уңышлы тәҗрибәләрне кулланырга, интернетта казынып, русча, инглизчә ниләр бар икән дип карарга туры килә. Төсле карточкалар, уеннар русча кызыграк һәм төрле. Күбрәк татарча мультфильмнар булса, безгә дә, ата-аналарга да телне өйрәтүдә җиңелрәк булыр иде. Шөкер, балалар өчен китаплар бар, алар матур, кызыклы. Минә өстәл уеннары белән проблема бар, – дип сөйләде Н.Нәкыйпова.

Гөлназ Садыйкова Казанның 115 нче балалар бакчасында эшли. Анда 442 бала йөри, татар бакчасы булып саналса да, балалар арасында төрлесе бар.

– Балалар өчен тәрбия, укыту татар телендә бара. Калган төркемнәрдә режим вакыты – татарча, ә тәрбия, уеннар, дәресләр русча бара. Бакчада гомум чаралар да күп, алар ике телдә үтә, – дип аңлата Гөлназ. – Саф татар төркемнәренә дә рус телле балалар килә. Әти-әнинең теләге – баласы татарча өйрәнсен. «Без белмибез, балалар, ичмасам, татарча белсен», – дип фикер йөртә. Әмма моның капма-каршысы да бар, ата-ана саф татар телендә сөйләшә, әмма баласын рус төркеменә яздыра. «Татар телен бездән дә өйрәнер, ипи-тозлык белсә, шул җитә, рус телен өйрәнсен», – дип уйлый. Татар төркеменә йөрүче рус телле балалар барыбер лексик базаны белә, әмма рус телле балалар белән аралашу тел мохитен боза.

2017 елдагы вакыйгаларны кичердек, мин рус бакчасында да, татарчасында да эшлим, әлегә «татарча кирәкми» дип кырт кискән ата-аналар белән очрашмадым. Бакчалар әлегә ул яктан иреклерәк булып калды. Әмма барыбер татар теленә сәдакага кебек карау бар. Җәмәгатьчелек татар теленең статусы ул кадәр мөһим түгел икәнен сизә. Шуңа да аның дәрәҗәсе үсмәсә, тәрбиячеләр, укытучыларның тырышлыгы белән генә алга китеш булмаячак. Дәүләт җитәкчелеге татар теле дигәндә принципиаль булырга тиеш. Эш ике телдә дә бертигез булсын. Бәйрәмнәрдә генә «Котлы булсын, исәнмесез!» сүзләре белән чикләнгәндә кешеләр аның кирәксез икәнен күрә. Телгә чып-чын дәүләт статусы кирәк.

Безнең Җиһан апа

(ТАССР наркомы, репрессия корбаны Кыям Абрамов хатынының ачы язмышы)

● Өченче рәттә уңнан беренче Хөснижиһан Байдамшина-Абрамова.

Хөснижиһан апа Байдамшина-Абрамова хакында Мәскәүдә яшәүче Зөһрә апа Баимбетова 1980 елларда бик сагынып сөйләгән иде. Зөһрә апа хакында матбугатта мәкаләләрем дә басылды. Ул – ТАССР төзелгән чорларда партия өлкә комитетының хатын-кызлар бүлеген җитәкләгән, бу эш өстенә ачлык вакытында балаларны коткару комиссиясенең рәисе дә булган хөрмәтле зат. «Ике бик тә уңган, ышанычлы таянычларым бар иде эшемдә. Берсе Җиһан Байдамшина, икенчесе Былбыл Ильясова иде. Алар кебек һәр эшне җиренә җиткереп башкарган ярдәмчеләрем булмады минем. Яз әле шулар хакында» дип үтенә иде. Никтер һаман сузылды бу эш. Һәм менә 1990 елда Евгения Гинзбургның «Крутой маршрут. Хроника времен культа личности». (М.: Советский писатель, 1990 ел) дигән китабында тагын Җиһан апага багышланган юлларны укыдым да хәйраннар калдым. Автор Җиһан апа хакында бөтенләй башкача бәя бирә.

Әйтеп үтим, Евгения Соломоновна Казанның югары уку йортларында марксизм-ленинизм фәнен укыта. 1937 елда кулга алына, 1955 елда аклана. Ире Павел Васильевич Аксенов (1890-1991) – партия, хуҗалык, профсоюз эшлеклесе. Шулай ук кулга алына. Исән-сау әйләнеп кайткач, «Последняя вера» дигән китабын язды. Анда татарлар хакында, бигрәк тә Осман Дивеев, Әминә Мөхетдинова һ.б. турында хөрмәт белән язды. Аксеновны гаепләү, ялгышмасам, хатынынннан баш тартмаган, аннан ваз кичмәгән өчен башланып китә кебек.

Солтангалиевчелектә гаепләнеп кулга алынган Җиһан Байдамшина белән Евгения Гинзбург Казан төрмәсенең бер камерасында очраша. Ул хакта «Крутой маршрут» китабында мондый юллар бар: «Нет, совсем невозможно узнать в этой до нутра потрясенной женщине вчерашнюю «совнаркомку», с ее сановитой осанкой. Она больше похожа сейчас на ту провинциальную татарскую девчонку, торговавшую папиросами в сельской лавке, девчонку, на которой лет за двадцать до этого женился Каюм Абрамов. Выражение ужаса смыло все детали показного грима. Обнажились и классовые (простая крестьянка) и национальные черты. Татарский акцент, с которым Зина боролась, проступил с особой силой, в первых же сказанных ею словах… Я никогда не симпатизировала вельможной Зинаиде…» (83 бит).

Репрессия еллары, ул вакытта рәнҗетелгәннәр хакында күп укыдым. Әмма бертөрле бәхетсезлеккә дучар булган кешеләрнең, исән-сау кайткач, бер-берләре хакында начар итеп язган сүзләрен бүтән укырга туры килмәде. Киресенчә, аерым шәхесләргә начар характеристика бирү алар гадәтендә юк төсле. Рәхмәт, рус язучысы Ю.И.Чирковның «А было все так» китабында (М.: Политиздат, 1991) татар хатыны, табибә Хәдичә апа Ямашеваның Коми АССРның Ухтижим лагеренда, үзенә куркыныч янаса да, бүтән тоткыннарга ярдәм итүе хакында бик җылы сүзләр белән язылган иде.

Мин, үз милләтемнең баласы. Евгения Соломоновна сүзләре белән һич тә килешә алмыйм. Шуңа күрә Җиһан апа Байдамшинаның тормыш юлы хакында язуны бурычым дип саныйм.

Ул 1898 елда хәзерге Тәтеш районының Кече Әтрәч авылында туа. Әтисе Мортаза аганың гаиләсе ишле, барлыгы 9 җан. Өлкәнрәк балаларга гаиләдә тормыш алып баруда булышу гадәти хәл булган бит инде. Бәләкәй Хөснижиһанга да Тәтештәге земство начальнигы гаиләсендә бала караучы да, йорт эшләрендә булышучы да булырга туры килгән.

Әмма әтисенең китаплар белән кызыксынган кызын укымышлы кеше итеп күрәсе килгән, шуңа күрә Тәтештәге русча-татарча мәктәпкә илтеп биргән. Ул үрнәк мәктәпләрдән саналган, ә аның директоры булып күренекле педагог, журналист һәм революционер булып танылып өлгергән Исхак Казаков эшләгән вакыт була бу. Җиһан үзенең тырышлыгы, сәләте белән укытучыларны, бигрәк тә Исхакның хатыны Нәфисә ханымны сокландырган. Алар Хөснижиһанны үз гаиләләренә алган, укуда матди ярдәм дә күрсәтеп торган. 1917 елда алар киңәше белән кыска сроклы укытучылар курсларында укыган кыз була.

1918-1919 елларда, курсларны тәмамлагач, яшь кыз Тәтеш кантонындагы Бәби авылы, Барыш, Тенкәш авылларында укытучы булып хезмәт итә башлый. Авыл укытучылары өстенә өелгән эшләрнең барысын да башкарган, барысын булдырган ул. Совет властен яклап халык арасында аңлату эшләре алып бару, үзешчән сәнгатькә яшьләрне тарту, спектакльләр, концертлар оештыру, наданлыкны бетерү мәктәбендә көч кую - ул башкарган эшләрнең бик азы гына әле.

Шушы елларда Татарстанда хатын-кызлар хәрәкәте дә җәелеп китә, аның бурычы – хатын-кызларны социалистик төзелешкә тарту. Булдыклы Җиһан да мондый хәрәкәттән читтә кала алмаган. Аны Тәтеш кантонында хатын-кызлар бүлегенең башта инструкторы, соңрак җитәкчесе итеп билгелиләр. Ачлык вакытында ачларга ярдәм оештыру, ач балаларны икмәкле өлкәләргә озату, Кызыл Армия өчен ярдәм йөзеннән кием-салым җыю, ачлар өчен ашханә пунктлары оештыру – барысы да ул елларда хатын-кызлар оешмалары ерып чыккан эшләр.

1922 елның гыйнварында Х.Байдамшинаны Казанга эшкә чакыралар. Ул Берләштерелгән Бистә (Объединенный городской) районында эшче хатын-кызлар бүлеген җитәкли башлый. Нәкъ менә шунда эшләгәндә кешеләрне эшкә тарта белүен Зөһрә апа күреп, иң югары бәяне бирә дә инде. 20 нче еллардагы ачлык газабын да, хатын-кызлар оешмаларындагы чиксез авыр хезмәт хакында да кабат язып тормыйм.

Ул еллардагы ачлык, авыр хезмәт Җиһанның сәламәтлеген какшата. Ул хезмәтеннән китәргә, җиңелрәк эшкә күчәргә мәҗбүр була. 1927 елда, бераз сәламәтләнгәч, 14 яшеннән шахтада эшләп, революциядән соң дәүләт, партия эшендә үзен танытткан, Казан шәһәренең Түбән шәһәр район комитетын җитәкләгән Кыям Алимбәк (Галимбәк) улына (1897-1938) кияүгә чыга. Өйләнешкәч, Кыямны партия өлкә комитеты Мәскәүгә, марксизм-ленинизм югары курсларына укырга җибәрергә карар кыла. Ире белән бергә башкалага киткән Җиһан тиз генә эшче яшьләр факультетына укырга кереп белемен күтәрә.

1929 елда аларны шул ук өлкә комитеты карары белән Казанга кайтаралар. Кыям – Халык Комиссарлары Советын җитәкли, ә Җиһан сәнәгать страховой кассасында башта инструктор, соңрак җитәкчесе булып эшли. 1930-1937 елларда республика сәнәгать советы Президиумы, Пленумы әгъзасы булып сайлана. Аның тырышлыгы белән шифаханә, сырхауханәләр, «Крутушка» ял йорты, олылар һәм балалар өчен санаторийлар, балалар ясләләре, бакчалары, ятимнәр өчен интернатлар ачыла.

Бу тигез, матур, ялкынланып эшкә бирелгән тормыш 1937 елда челпәрәмә килә. Бөтен күңеле белән тырышып эшләгән ире дә, Җиһан ханым үзе дә кулга алына. «Өстемдә бары бер кат күлмәкчән килеш илтеп яптылар», дип яза үз истәлекләрендә Җиһан апа. Бер гаепсез көе төрмәгә китереп тыккач, «до нутра потрясенной» булмый хәлең калмас. Кулга алынганчы бер ятим баланы алып тәрбияли башлаган булалар әле. Ул бала да урамда кала. Истәлекләрендә ул хакта үзәге өзелеп язган Җиһан ханым.

Аны милләтчелектә, солтангалиевчелектә гаеплиләр. Кыямынынан баш тартуны, аны Совет власте дошманы итеп күрсәтүне таләп итәләр. Ул баш тартмый, нык тора. Әйтергә кирәк, ирләрен халык дошманы итеп таныган, органнар белән эшләргә риза булган хатыннарны кулга алмаганнар ул чакта. Ирләренә хыянәт итмәгәннәр барысы да төрмәгә озатылган...

Кыям Абрамовның шахтада эшләгән вакытта авария туып, бер кулы сынган була. Төрмәгә эләккәч, җәзалап, аның сәламәт кулын да сындырганнар. Ә 1938 елда, революциягә, Совет властена чын күңелдән бирелеп, халык файдасына эшләгән эшләре өчен ике тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнгән татар баласы атып үтерелгән...

Җиһан Абрамованы 5 елга дип утырталар, әмма ул биш ел да тугыз елга сузылган. Казахстан лагеренда вакытта ул терлекчелектә эшләгән. Көтү дә көткән, башка төрле эшләргә дә җигелгән. 1946 елдан 1956 елга кадәр хокуклары чикләнгән «вольнонаемная» (янәсе, үзе теләп ялланган) буларак эшкә калдырылган. Ветеринария фельдшеры, аптека эшчесе булып эшләгән.

1956 елда гына ул Казанга кайта алган. Идел буе райсобесына учетка куелган. Сәламәтлеге какшаган, элек бергә эшләгән хезмәттәшләре, дуслары кайсы кулга алынган, кайберәүләр мәңгегә югалган вакыт бит. Җиһан апага өр-яңадан яши башларга туры килгән. Югалтуларны, йөрәктәге сызлануларны нәрсә белән булса да бераз онытырга, кешеләр арасында булырга кирәк бит. Ул, җәмәгать тәртибендә, хәзерге Идел буе районындагы № 22 йортлар идарәсе каршында китапханә оештыра, квартираларга йөреп китаплар җыя башлый. Бер меңгә кадәр укучылары, 9000 артык китабы була бу китапханәнең. Бәхетенә, 20 нче гасырның 60-70 нче елларында халык китап укый иде әле, шунысы файдалы булган. Күпме макулатура җыеп, никадәр чиратларны үтеп, китап сатып ала идек бит.

Тагын бер файдалы шөгыльләре бар иде ул вакытта Җиһан апа кебек пенсионерларның. Йорт идарәләре каршында оешкан балалар мәйданчыкларына килеп, балаларга экиятләр укый, төрле-төрле уеннар оештыра иде алар. Менә Җиһан апа да шундый эшлекле, актив пенсионер булып гомер иткән, үзенә шундый юаныч тапкан...

Җиһан апаның дуслары белән сөйләшкәнем булды. Аны бары яхшы яктан гына искә алалар иде. Шулай матур булып кала алды ул замандашлары күңелендә.

Ә Евгения Соломоновнага, исән булса, бары бер генә сүз – «ялгышасыз» дип кенә әйтер идем.

Тәэминә БИКТИМЕРОВА.

Авылны яшәтүчеләр

Рәзилә Хәмидуллина белән якыннан Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумында таныштык. Татар милләтенең язмышы, аның олы тарихы, туган телне саклау, халкыбыз гореф-гадәтләренә тугрылыклы булу – безнең өчен иң алгы планда булып чыкты.

Аның уллары белән күптәннән таныш идем... Олы улы Рамил Хәмидуллин Казан дәүләт университетының мин белем алган татар бүлегендә укыды, хезмәт юлы баскычларыбыз да туры килде. Ул Удмуртиядә нәшер ителүче “Яңарыш” газетасында хәбәрче булып эшләде. Газета укучылар аның мәкаләләрен һәм шигырь-хикәяләрен көтеп ала иде. Аннан соң Рамил революциягә кадәр, Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә танылу алган Иж-Бубый мәдрәсәсе традицияләрен күпмедер дәрәҗәдә дәвам иткән мәктәптә дә укытты. Әле бүгенгедәй хәтерлим: ул, Иж-Бубый укучыларының берсендә, ялкынлы чыгыш ясап, язучы Айдар Хәлимнең игътибарын да җәлеп иткән иде. Әдип Рамилгә ихтирам йөзеннән аңа үзенең өч томлык ”Хунбейвин” трилогиясен бүләк итте.

Ә энесе Радик Хәмидуллин (Рамазан хәзрәт), Россия ислам университетын тәмамлаганнан соң, хезмәт юлын яңа гына төзелгән Әгерҗе мәчет-мәдрәсәсендә башлады. Үзем дә һөнәри белем бирүче училище укучылары белән ике ел буена һәр шимбәдә Рамазан хәзрәт янына вәгазьләр тыңларга йөрдем. Бер төркемдә 30 укучы – булачак тимерьюлчылар. Төрле милләт уллары, төрле тәрбия алган егетләрнең барысы да татар телен өйрәнә. Ә Рамазан хәзрәт, аларның үзәкләренә үтәрлек итеп, татар, рус, гарәп телләрендә чиратлаштырып вәгазьләр сөйли.

Бу егетләрнең әниләре Рәзилә Миңнехан кызы – һөнәре буенча шәфкать туташы. Шуңадыр, мөгаен, алар күңелендә шәфкатьлелек, кешеләргә ярдәм итү теләге янып тора.

Гаилә башлыгы Рәсим Хәмидуллин белән бакчаларында таныштык. Мул уңышлы, кешенең күңел җылысын үзенә җыйган андый бакчаны күргәнем юк иде әле. Бакчада эшләү Рәсимнең күңел таләбе икәне аңлашылды. Ул, лаеклы ялга чыкканчы, тимер юлда эшләгән, ә буш вакытларын бакчачылыкка багышлаган. Авыл кешесенең бакчачы һөнәрен үзлегеннән укып-өйрәнеп, аның карталарын төзеп, безнең якка хас булмаган җиләк-җимеш куакларын, үсемлекләрне, агачларны үстереп тәҗрибәләр ясыйясый яшәве – гаҗәеп хәл.

Җылы як үсемлекләрен үзебезнең якка күчереп, аларның табигатебез кырыслыгына да чыдамлыкларын булдырып, төрле сынаулар аша уздырып, бакчасында үстерү өчен көч куя. Безнең якларда үсмәгән куак – үсемлекләрне күреп, аларның җимешләрен ашап туеп булмый. Рәсим “Тормышыбыз – гөлбакча, ә яшәү рәвешебез андагы һәр үсентегә тиешле тәрбия, игътибар булырга тиеш”, – девизы белән яши. Аның борчылулары – киләчәгебезне матур итеп күрергә теләве, күпләребезнең йөрәк түрендә. Рәсимне иң борчыган мәсьәлә – татарларның саны кимү. Җанисәп алдыннан да, сынауны халкыбыз җиңәргә, үзенең икенче урында торуыннан чигенмәскә тиеш, дип борчылып йөрде. Татарларның милли үзаңын үстерү кирәклеген дә искәртеп тора ул. “Без, туган телсез, җирдә аунап ятучы агач кебек. Киләчәктә дәүләтчелегебез торгызылуына да ышанам, әгәр телебезне югалтсак, аны берничек тә терелтеп булмас», – дип фикер йөртә Рәсим. Уллары, Рамил белән Радик әтиләренең дәвамчылары буларак, аның фәлсәфәсен тормышка ашыру юлында. Икесе дә Ямурза авылында әйдәп баручылар. “Авыл яшәсә генә – милләтебез яшәр” девизына тугрылыклы калып, Ямурзада тәрбия эшләре татар телендә алып барыла торган балалар бакчасы, туган телебездә белем бирә торган мәктәп эшли. Телебезне, гореф-гадәтләребезне, тарихыбызны, гомумән кешелекне саклаучы ислам диненең роленә зур игътибар бирелә бирелә. Егетләрне дә нәкъ шулар тартып китергән Ямурзага. Рамил Хәмидуллин үз хуҗалыгында мал-туар асрый. Фермер Сәхиповлар оештырган авыл хуҗалыгы артелендә иң булдыклы эшче ул. Рамил иҗат белән дә шөгыльләнә, берничә китап бастырып чыгарырлык шигырьләре дә бар, әнисе кебек көйләр дә яза, җырлый.

Рамазан хәзрәтнең дә бу яктан бәхете түгәрәк. Аны аңлап яши торган хатыны – Эльвирасы бар, өч баласы үсеп килә. “Балаларымны шушы татар мохитендә үстерә алуыма куанам. Аларның кулында кечкенәдән үк – Коръән китабы”, – ди ул.

Ямурзада яңа тормыш рәвешен, мөселманча яшәүне яңадан торгызган Илшат Сәхипов бакыйлыкка күчкән инде. Ләкин аның дәвамчылары – уллары, киленнәре, оныклары, хатыны Әнсәрия, авылдашлары, Рамил һәм Радик Хәмидуллин кебек фикердәшләре Илшат Сәхиповның эшен дәвам итә, ул кабызган утка сүнәргә ирек бирми. Аларның төп максат: халкыбызның телен, динен һәм мәдәниятен саклап, тарихны торгызып матур киләчәктә Ямурза авылында яшәү. Ямурзаның да гаять бай тарихы бар. Халык телендә йөргән сүзләргә караганда, Иван Грозный Казанны алганнан соң, Ямурза авылы кешеләрен көчләп чукындыралар, авыл башына тәре баганасы утыртып калдыралар. Иртәгесе көнгә тирә–як авыллардан мөселманнар җыелышып тәреле бағананы ындырып юк итә. Бу исә 1553-1558 елларга туры килә. Шундый авыр вакытларда да үз йөзен югалтмый калган авыл әле нишләп хәзер юкка чыгарга тиеш!

Вәсилә ХӘКИМОВА.
Әгерҗе районы.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

5 март (шимбә). ***Шәгъбән аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 7.35 сәгатьтә калка, 20.53 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.01 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Хөрмә шифасы

Йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары, гипертония булганда, көн саен 1 хөрмә (хурма) ашарга кирәк. Анемиядән дә 1 әр хөрмә ашау коткара, яисә көненә 1 тапкыр ярты стакан хөрмә йомшагына ярты стакан әфлисун согы кушып эчәргә киңәш ителә. Иртән ашалган хөрмә акыл эшчәнлеген яхшырта. Салкын тигәндә, тамакны хөрмә согына су кушып чайкыйлар. Хөрмә йомшагы яра төзәлүен тизәйтә. Тик шикәр чире белән авырганда бу җимешне артык күп куллану тыела.

6 март (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,7.44 сәгатьтә калка,22.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.06 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Карабодай кайнатмасы

Диабеттан интегүчеләргә чәй, су һәм башка сыеклык урынына гел карабодай шулпасы эчәргә кирәк. Бик сыек итеп карабодай боткасы пешерәләр, сөзәләр һәм шул кайнатманы көн буена эчәләр.

7 март (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 7.54 сәгатьтә калка,23.33 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.11 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә эти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

8 март (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,8.06 сәгатьтә калка,0.51 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.15 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказаның һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Куркум сихәте

Бронхиаль астмадан (бума чиреннән) интеккәндә, 1 чәй кашыгы куркум порошогын 1 стакан кайнар сөттә эретеп, ач

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

карынга көнения 2-3 тапкыр эчәләр. Бронхит вакытында ютәл җанга тисә, ярты чәй кашыгы куркумны тәлинкәдә яндырып, төтенен иснилəр, бу какырыкны сыегайта һәм сулыш алуны җиңеләйтә.

9 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,8.22 сәгатьтә калка, 2.07 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.20 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Салкын тигәндә

Иртән 2 канәфер бөресен төеп, бер чәй кашыгы балга кушалар да, кәнфит кебек суыралар. Төшке аш алдыннан кабатлыйлар. Болай дәвалану авыз куышлыгындагы патоген микрофлораны зарарсызландыра. Ютәл интектергәндә, 2 канәфер бөресен 150 мл кайнар суда 10 минут төнәтәләр. Җылытып, вак йотымлап эчәләр. Канәфер "чәе" какырык бүленеп чыгуны җиңеләйтә, карлыгуны бетерә, температураны һәм югары кан басымын төшерә.

10 март (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,8.45 сәгатьтә калка,03.16 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.24 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Аяк тирләгәндә

Аякны салкынча су белән еш юарга кирәк, тозлы су белән юу тагын да яхшырак. Аяк исе имән кайрысын порошок итеп төеп, оекбашка салалар. Даруханәдә сатыла торган ачуташ (квасцы жженые) та тир исен бетерә.

11 март (җомга). ***Шәгъбән аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 9.19 сәгатьтә калка, 4.13 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.29 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне нығыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

"Көмеш төенчекләр"

Бәйрәм табынына менә дигән ризык бу. 500 г тавыкның түш итен озынча телемнәргә турап, горчица, соя соусы, борыч, башка тәмләткечләр кушып, болгаталар, 1 сәгатькә суыткычка куялар. 500 г бәрәңгене фрига турагандай, гөмбәне – юка телемнәргә турыйлар, сырны уалар. Фольгадан 30х30 сантиметрлы шакмаклар кисеп, үсемлек мае сөртәләр, ит-бәрәңге-тоз-борыч-гөмбә-майонезны катламлап өеп, фольганы төенчек кебек төрәләр, 30 минутка газ миченә куялар. Аннары фольганы ачып, сыр сибәләр, тагын 10 минут пешерәләр. Табынга һәр кешегә аерым тәлинкәдә фольга төенчегендә килеш куялар.

Кроссворд



Сулдан уңга:

7. Бизәнү әйбере. 9. Красноярск краендагы шәһәр. 10. Тәгәрмәчләр кидерелә торган үзәк. 11.Чәчәк савыты. 12. Дәүләт башлыгы карары. 13. Яшелчә. 16. Иген кыры. 18. Вак камыр кисәкләре салып пешерелгән аш. 19. Яше зур булмаган. 20. Гомер буена, һаман. 23. Ялгышлык. 25. Эренле шеш. 26. Тузан сибергеч. 27. Угрофин телләре төркеменнән булган халык атамасы. 29. Мөселманнарда югары дәрәҗәле дин әһеле. 30. Йомшак табанлы күн итекчә. 32. Зур гәүдәле төньяк су кошы. 33. Төрле хуҗалык эшләре өчен җиңел материалдан корылган кечкенә каралты.

Өстән аска:

1. Сул кул белән яхшырак эшләүче. 2.Берәр мәсьәләне, фикерне иҗат итеп язу. 3. Тирән игътибарлы, сизгер. 4. Булган нәрсә. 5. Әзәрбайҗан башкаласы. 6. Данлыклап, мактап яки хәерле юл, уңыш теләп укыла торган дога. 8. Киемнең эченә тегелә торган әйбер. 14. Оештыручы, бүтәннәрне иярттә торган. 15. Әйләнә шәкелендәге төзелмә, әйбер. 17. Үелган урын. 18. Уеп бизәк төшерү коралы. 21. Әйтик, әгәр мәсьәлән. 22. Дуслык. 24. Товарның саф авырлыгы. 28.Аллага, пәйгамбәрләргә һәм диннең төп нигезләренә ышану. 29.Татарстандагы район үзәге. 30. Юллар кисешкән урын. 31. Күзләр өстендәге төкләр.

Нияз БИШБАЛТА төзеде.

ҖАВАПЛАР

Сулдан уңга: 7. Муенса. 9. Абакан. 10. Күчәр. 11. Ваза. 12. Указ. 13. Кәбестә. 16. Басу. 18. Умач. 19. Өлкән. 20. Мәңге. 23. Хата. 25. Чуан. 26. Себерке. 27. Мари. 29. Ахун. 30. Читек. 32. Гагара. 33. Алачык.

Өстән аска: 1. Сулагай. 2. Инша. 3. Сак. 4. Бар. 5. Баку. 6. Салават. 8. Эчлек. 14. Әйдәүче. 15. Түгәрәк. 17. Уелма. 18. Уйгыч. 21. Фаразан. 22. Татулык. 24. Нетто. 28. Иман. 29. Апас. 30. Чат. 31. Каш.

МК тамаша залларына чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

5 март – 17.00 – Шәрык клубында өр-яңа проект. 19.00 – «Дон Жуан» (Жан-Батист Мольер).
6 март – 12.00 – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров). 18.00 – «Өйләнәм. tat» (И.Зәйниев).
7 март – 12.00 – «Өйләнәм. tat» (И.Зәйниев). 18.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
8 март – 12.00 – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров). 15.30 – Шәрык клубы бинасында – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). 18.00 – «Сәфәр» (А.Шакиров).
10 март – «Театр һәм музыка» концерты.
11 март – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

6, 7 март – «Жизель» (А.Адан).
10 март – «Анюта» (В.Гаврилин).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

4 март – «Полиционер» (И.Зәйниев).
5 март – «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев).
6 март – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
7 март – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
8 март – «Беренче мәхәббәт» (Х.Вахит).
9 март – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
10 март – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
11 март – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

4 март – «Шәй-бу! Шәй-бу!» (К.Кәримов).
5 март – «Арыну» (Т.Кулов, А.Әхмәдиев).
6 март – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
7,8 март – «Матур-City» (А.Әхмәтгалиева).
9 март – «Ләйлә-Мәҗнүн» (Н.Ганҗәви).
10 март – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

4 март – 11.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл). 19.00 – «Ханума» (А.Цагарели).
5 март – 11.00, 13.00, 15.00 – «Приключения Чебурашки» (Э.Успенский). 12.00 – «И, кызык Шүрәле!..» (Г.Зәйнашева).
6 март – 10.00 – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). 12.00, 14.00 – «Приключения барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе). 13.00 – «Камыр батыр» (С.Хөсни).
7 март – 12.00, 13.30 – Не хочу, не буду» (П.Геннадьева). 18.00 – «Shurale: яңа фантазия» (Ф.Яруллин, И.Зәйниев либреттосы).
8 март – 11.00, 13.30, 16.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл). 12.00 – «Өрә белмәгән кәҗә» (Р.Мөхәммәтшин).
11 март – «Аленький цветочек» (С.Аксаков). 19.00 – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

10 март – Татарстан Республикасының А.Шутиков җитәкчелегендәге дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры башкаруында романслар яңгыраячак. Методие Бужор кушылып җырлый.
11 март – Татарстан Республикасы филармония-джаз оркестрына кушылып Олег Бутман һәм Наталья Смирнова-Бутман кушылып уйный һәм җырлый.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

4 март – Татарстан Республикасы дәүләт камера хоры башкаруында «Моя прекрасная леди» дип исемләнгән концерт.
6 март – Татарстан Республикасы кыллы квартеты концерты.
11 март – Наталья Железных ансамбле концерты.

Халык үз рәссамына лаек булырга тиеш

Бакый Урманченең тууына 125 ел

Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясында скульптор, рәссам Бакый Урманченең 125 еллыгына багышланган очрашу булды. Биредә олуг рәссамның төрле елларда иҗат ителгән картиналары белән беррәттән Б. Урманченең шәхси архивында саклланган материаллар: мәкаләләр, шигырьләр, хатлар да урын алган. Алар тамашачыга беренче тапкыр тәкъдим ителде. Хатыны Флора ханымга багышлап язылган шигырьләре белән дә танышу мөмкинлеге бар иде.

Картиналар берничә залда эленгән, шунда ук «Сагыш», «Сөембикә», «Язгы аһәңнәр» сыннары да урын алган. Кичәгә рәссамнар, Бакый Урманченең замандашлары, аның дуслары һәм укучылары да килгән иде. Беренчеләрдән булып сүз Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музее директоры Розалия Нургалиевага бирелде.

«Безгә вакытлыча саклауга Бакый Идрисовичның зур архивын тапшырдылар. Анда аның кулъязмалары, шигырьләре кергән. Бакый Урманче заманының фәлсәфәчесе, шагыйре булган», – диде ул.

Директор Бакый Урманченең «Ибн Фазланның Болгарга килүе» хезмәтенең күчермәсен аның төзәтмәләре, аңлатмалары һәм иллюстрацияләре белән бастырып чыгарырга теләвен әйтте.

«Бакый Урманченең күргәзмәләрен бик күп ясадык. 5 ел элек төрле җирләрдән җыйган идек, быел исә үзебезнең фонд әйберләре генә. Күргәзмәдә аның да 60 проценты гына урын алган. Бөтенесен дә күрсәтәсе килә, әлбәттә. Аның тормышының төрле этапларын күрсәтү теләге дә бар, ә моңа бик зур урын кирәк. Биш ел эчендә Бакый Урманченың архивын системалаштырып эшләдек. Быел без Бакый Урманченың «Ибн Фазланның Болгарга килүе» күчермәсен татар телендә эшләп чыгарырга ниятлибез.

Шулай ук Бакый Урманченың шигырьләрен дә китап итеп чыгару теләге бар. Алар гарәп графикасында да, татар һәм рус телләрендә булыр дип көтелә.

Бакый Урманче мирасының шактый өлеше әле Казахстан, Үзбәкстан музейларында кала. Хәзер аны монда кайтару бик кыен. Берничә көн элек кенә бу хакта консул белән дә сөйләштем. Тора-бара мондый мөмкинлек булыр дип уйлыйбыз. Анда ул бик күп танылган кешеләрнең этнографик портретларын ясаган. Ул андагы халык белән дә бик дус булган. Казахстанда казах телендә, үзбәкләр белән алар телендә сөйләшкән.

Рәссамның 120 еллыгына без ул җырлаган җырлардан төзелгән җыентык та чыгарган идек. Анда җыр сүзләре, ноталары урын алган һәм әле Бакый Урманченың тавышы саклланган дискы да бар иде», – дип аңлатты Розалия ханым.

Бакый Урманченың архивы белән эшләгән филология фәннәре докторы Зөфәр Мөхәммәтшин белән дә әңгәмә кордык. «Бакый Урманче кулъязмаларының 99 проценты гарәп графикасында. Ул мемуарлар өчен бик күп материал туплый. XX йөз башының бик күп шәхесләре турында язып калдырган истәлекләре дә бар», – диде ул.

Бакый Урманченың ике шигыре кунакларга да тәкъдим ителде. Г. Кариев театры артистлары Энҗе Яруллина һәм Илфат Гибадуллин «Салтык җирен узганда», «Айгөлем» дип аталган шигырьләрен укыды.

Татарстанның мәдәният эшлеклесе, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең элекке сәнгать җитәкчесе Лима ханым Кустабаева рәссамны шәхсән белгән. Бүген ул бирегә оныгы белән килгән иде.

«Бакый Идрисович – бик кызык, күпкырлы кеше иде. Ул рәссам гына түгел, бик яхшы скульптор да булды. Иң беренче урынга мин аның татар халык авыз иҗаты белемен куяр идем. Ул халык шигърияten, көйләрен дә бик яхшы белде. Берсендә, үзенең юбилее вакытында ул сәхнәгә чыгып бераз эндәшми торганнан соң, матур итеп татар халык җырын башкарды. Минә шундый иде ул: татар җанлы, татар рухлы кеше.

Безнең танышу мин җыр һәм бию ансамблендә эшләгән вакытта булды. Алар хатыны Флора ханым белән ансамбль концертларына бик еш килә иделәр. Мин аның «Биючe» картинасын күреп, татар халык милли костюмнары эскизларын сорап мөрәҗәгать иткән идем. Шуннан без дуслашып киттек. Без бик еш кунакка йөрешә идек. Шундый очрашуларның берсендә ул минем портретымны да ясады.

Соловки атауларына сөрелгән чаклары турында ул еш кына «Минем өчен ул чын академия булды. Анда булмасам, бүгенге Урманче була да алмаган булыр идем, бәлки. Мин анда бик күп белем алдым», – дия иде.

Тагын бер очракны гына сөйләп үтәм. Бакый Урманченың 90 яшьлеге тарафыннан оештырылган күргәзмәгә япон профессорын алып килгән идем. Ул аның эшләрен күреп шаккаткан, бик илһамланган иде», – дип сүзен тәмамлады Лима ханым.

Б.Урманче тележурналист, Татарстанның халык артисты Лия Заһидуллинаның ике портретын ясаган булган. «Аның 90 яшьлегенә мин 90 минутлык зур фильм эшләдем. Кызганыч, фильм сакланмаган. Анда минем шундый җөмләм урын алган иде: рәссам үз халкына лаек булырга тиеш, әмма халык та үз рәссамына лаек булырга тиеш. Бу инде аңа үзе исән чагында ук музей ачарга кирәклеге турында иде.

Аның белән аралашу үзе бер бәхет иде. Бер портретымны озак ясады ул – өч елга якын. Миңа ул портрет өчен биек үкчәдә өчәр сәгать басып торырга да туры килгәләде. Ясаганда, Бакый Урманче йә җырлый, йә фарсы телендә шигырьләр укый иде.

Икенче портретымны берничә атна эчендә ясап чыкты. Еллар узган саен мондый олы шәхесләрнең аралашуда никадәр җиңел икәнлеген аңлый барасың. Бакый Урманче – бөек шәхес. Тормыш юлында мондый шәхесләр очрату насыйп була икән, димәк, бу синә Аллаһның бүләге. Хатыны Флора ханым Себер татарлары ризыкларын бик тәмле пешерә иде. Вак кына кияү пилмәннәрен хәтерлим, аның боткалары да үзгә, башка төрле була иде», – дип искә алды легендар диктор.

Сәнгать белеме докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова Б.Урманчены мәктәптә укыган чакларыннан ук белгән. «Б. Урманче минем әтием белән бик дус булганнар. Безгә еш кына татар интеллигенциясе вәкилләре җыела иде, алар арасында хатыны белән Бакый ага да була иде. Безнең аның белән җитди сөйләшүебез мин институтны бетереп аспирантурага укырга кергәч булды. Минем дәү әтием Мәскәүдә укучы студентларга стипендия түли торган булган. Бакый ага бу хакта: «Синең дәү әтиең булмаса, мин ул вакытта ачтан үлгән булыр идем», – дип искә ала иде.

Заманында рәссамнар берлеге җитәкчелеге ягыннан Бакый агага карата салкын караш бар иде. Әзрәк көнләшү идеме ул. Бакый ага рәссамнар берлеге кысаларына сыймаган. Анда аңа берничек тә йогынты ясый алмыйлар, Бакый аганың үз фикере бар иде», – диде Гүзәл ханым.

Әдәбият галиме-текстолог, нәкышчы Нәҗип Нәккаш та Б. Урманче белән бәйле истәлекләре белән уртаклашты: «Минем иҗатымда Бакый ага белән очрашу, аннан дәресләр алу, аның шәкерте булу тирән эз калдырды. 1978 елда без 4 кеше: 2 студент һәм укытучылар аның йортына килдек, аның фатиры да, остаханәсе дә шунда иде. Ул вакытта Бакый ага Тукай музее өчен әсәрләр иҗат итеп маташа иде. Алдына калын алъяпкыч киеп, өтерге белән эшләп утырган чагы. Ул безне каләм тотарга, беренче хәрефләрне язарга өйрәтте, өйгә эшләр дә биргәләде. Каллиграфия үрнәкләрен күчереп яза идек. Бакый ага шушы гарәп язуын әзмичә саклап килгән профессионалларның иң соңгысы булгандыр дип уйлыйм мин».

Рәссам Фәрит Вәлиуллин үз хис-кичерешләре белән бүлеште: «Аның картиналарына карагач, боларны бәхетле кеше ясаган дигән уй килә. Сөргендә дә, төрмәдә дә булган дип уйламыйсың да. Шүрәлене күпләр ясап караган, ләкин нәкъ менә Бакый Урманче аны татарлар тоемлавынча тойган кеше. Шүрәле ул бит шайтан түгел, ул ирониялә, җиңел бер күренеш. Менә татарларда шушы усаллык, агрессия булмауны сизгән Бакый Урманче. Аның бар иҗаты да шундый якты».

«Б. Урманченың һәр эше күңелгә якын. Аның әсәрләре стилистик, тематик яктан да бик төрле. Иң мөһиме: ул һәрвакытта да үз сүзен әйтә белә. Моны иҗатчы өчен иң кирәкле сыйфат дип әйтер идем мин. Үз йөзен, индивидуаль манерасын тапкан һәм милли булып та калганнар бик сирәк. Бөтен төрки, мөселман дөньясы һәм Европа өчен дә ул якын, чөнки анда көнчыгыш белән көнбатыш арасындагы баланс бар.

Бакый Урманче да һәрбер рәссам кебек эволюция кичергән. Аның баштагы рәсемнәрендә импрессионистик чалымнарны, реализмны күрергә була. Урта Азиядә яшәгән вакытта сеңеп калган төрки дөньяның көнкүрешен дә тоемларга мөмкин. Алар барысы да укмашкан дип әйтер идем мин. Аңарда коры иллюстрация юк, бервакытта да. Ул – хиссиятле рәссам. Күңеленнән, йөрәгеннән чыгарып яза.

Төрле стилистик алымнарны үзләштергән вакытта аның миллилеге бигрәк тә калку булып күренә. Милли рух күп компонентлардан тора бит. Анда безнең халык сәнгатенең төсмерләрен дә тоясың, анда музыка аһәңе дә яңгырый. Безнең типажларны, сурәтләүдә дә чагылыш таба», – дип аңлатты рәссам иҗатын Розалия ханым.

Б. Урманченың 125 еллыгына багышланган кичә Казан консерваториясенең опера студиясе артистлары концерты белән тәмамланды.

Ләйсән РӘХМӘТУЛЛИНА.
Расих ФӘСХЕТДИНОВ фотолары.

Нигә шулай озак?

Америкада җинаятьчеләрне кайвакыт 100, 120, хәтта 200 елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Кеше шулкадәр озак яшәми бит, ни өчен шулай икән? Беренчедән, биредә хокук системасы башка төрлерәк, җинаятьләр өчен бирелгән берничә җәза "туплана" бара: мәсәлән, үтерү (10 ел) һәм ут төртү (5 ел) өчен хокук бозучы 15 ел ала, берничә гомерлек срок яки 120 ел да шулай тупланып җыела. Икенчедән, мондый система җәмгыятьне куркыныч җинаятьчеләрдән саклый. Эш шунда: Америкада срокларны кыскарту һәм амнистия буенча азат итү практикасы гамәлдә. Тәүбәгә килеп, тәртибе яхшы булучылар билгеләнгән вакытның яртысы үткәч иреккә чыгарылырга мөмкин. Юрисдикциягә бәйле рәвештә, гомерлек төрмәгә утыртылучы 15-25 елдан соң шартлы азат ителү турында гариза бирә ала. Әгәр инде берничә гомерлек җәза бирелгән икән, вакытыннан алдарак иреккә чыгар өчен утырылырга тиешле 25 еллык сроклар саны да арта – ике гомерлек җәза булса, үтенеч язганчы 50 ел, өч гомерлек җәза булса – 75 ел утырырга кирәк. Шул рәвешле система җәмгыятьне чыннан да куркыныч җинаятьчеләрдән саклый, ә инде гаеп-хаталарын танып, төзәлергә теләгәннәргә шундый мөмкинлекне бирә.

("The Independent").

Чәйме, каһвәме?

XVIII гасырда Швеция короле Густав III, дөньяда беренче "сынау" үткәреп, каһвәнең агулау үзлеген өйрәнмәкче булган. Моның өчен үлемгә хөкем ителгән игезәк җинаятьчеләрнең җәзасын гомерлеккә төрмәдә утыру белән алыштырган. Туганнарның берсе көн саен – чәй, икенчесе исә каһвә эчәргә тиеш булган. Король шул рәвешле кайсы эчемлекнең зыяны күбрәк булуын ачыкларга маташкан. Игезәкләрнең сәламәтлеген ике профессор күзәтеп торган. Тик, ни кызганыч, башта бер профессор дөнья куйган, аннары икенчесе вафат булган. Король үзе дә якты дөнья белән хушлашкан. Игезәк туганнар исә төрмәдә утыруларын һәм чәй-каһвә эчүләрен дәвам иткән. Чәй эчкәне алданрак җан тәслим кылган, ул чакта инде аңа 83 яшь тулып узган.

("Die Presse").

Кара мәче юлны киссә...

Һәр халыкның үз хорафатлары бар. Алдынгы карашлы европалы да, Африка аборигены да бөтенең тылсымлы көченә ышана, ә күз тиюдән курка. Кайбер ышанулар охшаш: дага – уңыш билгесе, 13 – бәхетсез сан, көзге ватылу – бәла-казага һ.б. Кайсыбер юрамалар исә капма-каршы мәгънәгә ия. Мәсәлән, Россиядә кара мәче очратуны уңышсызлык китерә дип санасалар, Англиядә, киресенчә, бер-берсенә уңыш теләгәндә кара мәче сурәте бүләк итәләр. Грециядә, күз тимәсен өчен, киемгә күз ясалган зәңгәр төймә тагалар – янәсе, зәңгәр төс явызлыктан саклый. Тик менә зәңгәр күзле кешеләрнең күзе тиючән була да инде. Англиядә, уңышка ирешү өчен, дүрт тажлы тукранбаш яфрагы табу, айның беренче көнендә "Ак куян" дип кычкыру, агачтан коела торган көзге яфракларны мөмкин кадәр күбрәк җыеп калу житә, дип саныйлар. Ә менә баскыч астыннан үтү, көзге вату яки саескан күрү – начар фал. Бусагада килеш кулчатыр ачарга, яңа аяк киемен өстәл өстенә куярга ярамый, чөнки бу гамәлләр өйгә үлем чакыра, дип уйлый инглизләр. Италиядә, мәче төчкергәнне ишетү бәхет китерә, ә менә тәрәзәдән очып кергән кош уңышсызлык алып килә, дип ышаналар. Кытайда, 8 саны – бәхетле, 4 саны исә үлем китерә, дип уйлыйлар, шуңа җае чыккан саен 4 санын төшереп калдырырга тырышалар.

("The Mirror").

Көндез йоклау файдалы

Япония галимнәре раславынча, көндез черем итеп алу балалар өчен генә түгел, һәркем өчен дә файдалы икән. Бу 50 яшьлекләрне йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан саклый, ә 35 яшьтән узган хатын-кызларга гүзәл, яшь калырга булыша. Медицина хезмәткәрләре йөрәк авыртуның нәрсә икәнен дә белмәгән 24 мең кешене берничә ел буе күзәткәннән соң шундый нәтиҗә ясаган, чөнки аларның көндез черем итеп алуы ачыкланган. Әмма бер кагыйдәне онытмаска кирәк: йокы атнага 3 тапкыр һәм 30 ар минут кына булырга тиеш.

("The Local").

● Ике якка ачылмалы Arctica islandica моллюскы.

● Гигант ташбака.

● Кои карпы.

● Европа энҗе моллюскы.

● Кызыл диңгез керпесе.

● Гуидак моллюскы.

● Гренландия киты.

Озын гомерле җиде хайван

Гомер озынлыгы буенча кеше хайваннар дөньясының күп вәкилләреннән калыша. Җирдә иң озын гомерле хайван – ике якка ачылмалы Arctica islandica моллюскы. Ул Атлантик океанның төньягында 7-400 метр тирәнлектә яши. 2006-2007 елларда Уэльсның Бангор университетында үткәрелгән тикшеренү аларның 500 елдан артыграк яшәвен күрсәткән. Альдабра утравындагы гигант ташбакалар уртача 150-200 ел яши, Калькутта зоопаркында Адвайта кушаматлы 250 килограммлысы исә 256 яшендә җан тәслим кылган. Кои яки парча карпларының гомер озынлыгы уртача 150-220 елга тәңгәл. Уртача 210-250 ел яшәүче Европа энҗе моллюскысына якын арада бөтенләй юкка чыгу куркынычы яный. Элегрәк алардан перламутр алынган, хәзер исә бу табыш китерми торган кәсебгә әйләнгән. Планетада Палеозой чорыннан бирле мәгълүм диңгез керпеләре 200 елдан артык яши һәм бер дә картаймый. Сәер кыяфәтле Гуидак моллюсклары уртача 150 яши. Аларның табигатьтә дошманнары юк диярлек (ә менә кытай һәм японнар аның итен ашый), матдәләр алмашы да бик акрын бара, шунлыктан гомерләре озын. Тышкы аталану юлы белән үрчүче бу моллюск үзенең гасырдан артык гомерендә биш миллиардлап уылдык чәчә. Кит – планетабызда иң зур хайван. Гренландия киты исә умырткалы хайваннардан иң озын гомерлесе дә. Уртача гомер озынлыгы 40 ел гына булса да, кайберләре 200 елдан артык яшәргә мөмкин. Бу имезүчеләр гомере буе үсә һәм үрчи, әлеге процессларның көче бер дә кимеми. Геронтологларны тагын шунысы да гаҗәпләндерә: иң карт китларда да таушалу, бетерешү билгеләре юк. Китның нидән үлүе дә һаман төгәл ачыкланмаган. Аның яшен күз ясмыгындагы аксым микъдары буенча билгелиләр, ул тоныклану кит картаюының бердәнбер күрсәткече булып тора. Күп еллар буе геронтология белән шөгыльләнүче галим Владимир Скулачев фикеренчә, кит башта сукырая, аннары инде, күрмәгәч, имгәнеп-яраланып җан тәслим кыла.

("Интересно.cc").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

7 март

Телевизор карауччылар игътибарына! Хоккей буенча Гагарин кубогы уеннары башлану сәбәпле, программада үзгәрешләр булуы ихтимал.

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «Болгар радиосы» Милли музыка премиясен тапшыру тантанасы. 6+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.30 «Туган җир». 12+
15.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». 6+
17.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Соотечественники». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «ЛЮБОВЬ НЕ ПО РАЗМЕРУ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00 «Манзара». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.40 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 18.20 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». 6+
12.05 «КАЙДА СИН?» 12+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 Спектакль «Искән җилләр көенә». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00 «КУРОРТНЫЙ РОМАН». 16+
16.30 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.00 «МАРИЯ ДО КАЛЛАС». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.25, 6.10 «КАРНАВАЛ».
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
8.25 «БУДЬТЕ МОИМ МУЖЕМ». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте- путешествии «Жизнь других». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
14.05 «Порезанное кино». 16+
15.15 «ЛЮБОВЬ ЗЕМНАЯ». 12+
17.05 «ВЕСНА НА ЗАРЕЧНОЙ УЛИЦЕ». 12+
18.55 Юбилейный концерт Олега Газманова. 12+
21.00 «Время».
21.20 «Голос. Дети».
22.55 «Мэри Куант». 16+

«РОССИЯ»

5.25 «НЕВЕЗУЧАЯ». 12+
7.05 «ЖЕНИХ ДЛЯ ДУРОЧКИ». 12+
11.00, 14.00, 20.00 Вести.
11.30 «МАМА ПОНЕВОЛЕ». 12+
14.30 «САМАЯ ЛЮБИМАЯ». 12+
16.55 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ». 12+
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «Я ВСЁ НАЧНУ СНАЧАЛА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
8.20 «НАСТЯ».
9.50 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.20 «БЛАГОЧЕСТИВАЯ МАРТА».
12.35 «Ехал грека... Путешествие по настоящей России».
13.25 «История снежного барса».
14.20 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.30 Государственный академический русский народный хор имени М.Е. Пятницкого. Юбилейный концерт.
17.05 «МЭРИ ПОППИНС, ДО СВИДАНИЯ!»
19.25 «Ищите женщину». Какая ты красивая, когда молчишь!»
20.05 Концерт «Признание в любви».
21.20 «Мир, который построил Пьер Карден».
22.15 «БЕРЕЗКА».
23.10 Клуб, Шаболовка, 37.

«НТВ»

5.40, 8.20 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
10.20, 16.20 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
20.00 «Маска». 12+
23.30 «Основано на реальных событиях». 16+

Сишәмбе

8 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «СЕРДЦЕ ЖДЁТ ЛЮБВИ». 12+
11.00 Творческий вечер композитора Эльмира Низамова. 6+
13.20 «Женщина года. Мужчина года. женский взгляд». 6+
15.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». 6+
17.00 Хоккей. Кубок Гагарина. «Авангард» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КИЛИМАНДЖАРА». 16+
23.30 «ПАРИЖ - МАНХЕТТЕН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.40 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 Спектакль «Люстра». 12+
12.05, 20.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». 6+
15.00 «Әниләр һәм бәбиләр». 6+
17.00 Хоккей. Гагарин кубогы. «Авангард» - «Ак Барс». 6+
19.30, 0.40 «Татарлар». 12+
21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
21.25 «Женщина года. Мужчина года. Женский взгляд». 6+
22.45 Спектакль «Алхимик». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 9.30, 11.30 «КУРОРТНЫЙ РОМАН». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00 «КУРОРТНЫЙ РОМАН 2». 16+
16.30 «О чем поют мужчины». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ДИАНА: ИСТОРИЯ ЛЮБВИ». 12+
23.00 «НАДЕЖДА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.30 «Моя любовь». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.10 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ИТАЛЬЯНЦЕВ В РОССИИ».
8.05 «ТРИ ПЛЮС ДВА».
10.10 «Будьте счастливы всегда!» Праздничный концерт. 12+
12.10 «ДЕВЧАТА».
14.00 «КОРОЛЕВА БЕНЗОКОЛОНКИ».
15.30 Праздничный концерт «Объяснение в любви». 12+
17.05 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА».
19.00 «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ». 12+
21.00 «Время».
21.20 «КРАСОТКА». 16+
23.35 «Женщина». 18+

«РОССИЯ»

5.40 «ЗАВТРАК В ПОСТЕЛЬ». 12+
9.40, 11.30 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ». 12+
11.00, 20.00 Вести.
13.05 «БОЛЬШОЙ». 12+
17.00 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН».
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «СЕРЕБРЯНЫЕ КОНЬКИ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.30 «МЭРИ ПОППИНС, ДО СВИДАНИЯ!»
9.50 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.20 «ЛЕТУЧАЯ МЫШЬ».
12.35 «Ехал грека... Путешествие по настоящей России».
13.25 «Всё, что смогу, спою... Андрей Миронов».
14.25 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.00 «Архи-важно».
15.30 «Любовь и судьба».
16.10 «ЦЫГАН».
17.35 «Пешком...»
18.05 «Эрнест Бо. Император русской парфюмерии».
19.00 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ».
20.20 Концерт-посвящение Андрею Миронову в Театре мюзикла.
22.15 «БЕРЕЗКА».
23.10 Луи Армстронг. Концерт в Австралии.

«НТВ»

5.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ». 16+
7.35, 8.20 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
10.20, 16.20, 19.40 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
22.10 «Все звезды для любимой». Праздничный концерт. 12+

Чәршәмбе

9 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Калеб».
16.00 «Переведи!» 6+
17.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Чёрное озеро». 12+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан-ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Мировой рынок». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «МУЗЫКА КРЫШ». 16+
14.30 «Люди РФ». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Инстаграмщицы». 16+
16.30 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЯНЫЧАР». 16+
23.25 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «ЗАЦЕПКА». 16+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино. Александр Роу.
7.35 «Мир, который построил Пьер Карден».
8.35 Цвет времени. Марк Шагал.
8.45, 15.50 «КАПИТАН НЕМО».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Песня остается с человеком. «Нежность».
12.05, 22.15 «БЕРЕЗКА».
13.55 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
14.05 К 85-летию со дня рождения Владимира Маканина. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
17.05 «Галина Уланова. Незаданные вопросы».
18.00 «Григ. Из времён Хольберга».
18.35 «Человек - это случайность? Что заставило мозг расти».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Светящийся след».
21.30 Власть факта. «Венецианская республика».
23.10 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
23.40 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

10 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
17.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». 6+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Күңелем назлары җырымда чагыла...» Флера Сөләйманова турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ДВА ДНЯ, ОДНА НОЧЬ». 16+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Верю не верю». 16+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЯНЫЧАР». 16+
23.25 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «ЗАЦЕПКА». 16+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Человек - это случайность? Что заставило мозг расти».
8.35 «Забытое ремесло».
8.50, 15.50 «КАПИТАН НЕМО».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Николай Симонов».
12.05, 22.15 «БЕРЕЗКА».
13.05 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».
13.20 «Архив особой важности».
14.05 Линия жизни. Александр Зацепин.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Курские кудесники».
17.00 «Самара. Дом Сандры».
17.30 Денис Шаповалов, Владимир Федосеев и Большой симфонический оркестр имени П.И. Чайковского.
18.30 «Первые в мире».
18.45 «В поисках Византии».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «31 июня». Всегда быть рядом не могут люди».
21.30 «Энигма. Лахав Шани».
23.10 «Запечатленное время».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
23.40 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

11 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Тәймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
17.00 «Гомерләр бик сизгер икән». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «БЕЗУМНЫЕ ПРЕПОДЫ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Галимҗан Ибраһимов турында телеочерк. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «СУМАСШЕДШЕЕ СЕРДЦЕ». 16+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Еда, я люблю тебя». 16+
16.30 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.30 «Голос. Дети».
23.05 «УБИЙСТВА В СТИЛЕ ГОЙИ». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «ЗАЦЕПКА». 16+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35 Цвет времени. Ван Дейк.
7.50 «В поисках Византии».
8.35 «Забытое ремесло».
8.50, 16.15 «КАПИТАН НЕМО».
10.15 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ».
11.35 Открытая книга.
12.05 «БЕРЕЗКА».
13.05 Цвет времени. Караваджо.
13.20 «Кинескоп». 72-й Берлинский международный кинофестиваль.
14.05 Юбилей Марии Ароновой. Линия жизни.
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Лахав Шани».
17.25 Зубин Мета и Израильский филармонический оркестр.
18.10 Хрустальный бал «Хрустальной Турандот» в честь Марка Варшавера.
19.45 Линия жизни. Андрей Чернихов.
20.40 «ОТЧИЙ ДОМ».
22.20 «2 Верник 2».
23.30 «ИДЕНТИФИКАЦИЯ».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «Следствие вели...» 16+
21.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
23.10 «Своя правда». 16+

Шимбә

12 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.40 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Риваять». Төрки-татар этникасы ансамбленә 10 яшь. 6+
15.00 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
16.00 «Галиҗәнап шагыйрь» циклыннан. Илдар Юзеев. 6+
17.00 «СТЭНДАПханә». 16+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «СЮРПРИЗ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Галимҗан Ибраһимов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле». 6+
13.00 «Син һәм мин». Салават Миңнехапов һәм Гүзәлем концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Очрашулар эзләп» Габделфәт Сафин концерты. 6+
22.10 «Эләктегезме?..» «Мунча ташы» спектакле. 12+

«ЭФИР»
5.00 «Это лечится». 12+
5.30 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «История образования». 12+
8.20 «МАНЕКЕНЩИЦА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «СЕЙЧАС САМОЕ ВРЕМЯ». 16+
14.45 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КРАСАВИЦА ДЛЯ ЧУДОВИЩА». 16+
23.00 «Человек - невидимка». 16+
23.55 «ВСЕ САМОЕ ЛУЧШЕЕ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00 Новости.
10.15 «Иммунитет. Идеальный телохранитель». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.10 «ШИРЛИ-МЫРЛИ». 16+
16.55 «Кто хочет стать миллионером?»
18.30 «Точь-в-точь». 16+
21.00 «Время».
21.20 «ЭКИПАЖ». 12+
0.05 «СТЕНДАПЕР ПО ЖИЗНИ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
8.55 «Формула еды». 12+
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.30 «СИНДРОМ НЕДОСКАЗАННОСТИ». 12+
14.30 «Я ВСЁ ПОМНЮ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести в субботу.
21.00 «СРОК ДАВНОСТИ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.15 «ОТЧИЙ ДОМ».
9.55 «Передвижники. Генрих Семирадский».
10.25 «СТЮАРДЕССА».
11.05 Международный фестиваль «Цирк Будущего».
12.35 Человеческий фактор. «Да будет кедр!»
13.05 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
14.05 «ОПАСНЫЙ ПОВОРОТ».
17.15 «Мозг. Эволюция».
18.25 «31 июня». Всегда быть рядом не могут люди».
19.05 «Энциклопедия загадок».
19.40 «Божьей милостью певец».
20.35 «ДАЙТЕ ЖАЛОБНУЮ КНИГУ».
22.00 «Агора».
23.00 «МУЖЬЯ И ЖЁНЫ».

«НТВ»
5.05 «ЧП. Расследование». 16+
5.30 «ДОЛЖОК». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.45 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 Ты не поверишь!. 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

13 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «60 яшь тә узып китте, 61 килеп житте...» Виталий Агапов. 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Гомерләр бик сизгер икән». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Риваять». Төрки-татар этникасы ансамбленә 10 яшь. 6+
15.00 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Чёрное озеро». 16+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «МУЖЧИНА, КОТОРОГО СЛИШКОМ ЛЮБИЛИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00 «Мәхәббәт һәм бәхет иленә сәяхәт». 6+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Гөлдания Хәйруллина турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Спектакль «Мәхәббәт турында сөйләшик». 6+

«ЭФИР»
5.00 «Клинический случай». 12+
5.30, 15.00 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Министр на доверии. Дело Сухомлинова». 12+
8.45 «История образования». 12+
9.00 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КРАСАВИЦА ДЛЯ ЧУДОВИЩА». 16+
15.25 «МАНЕКЕНЩИЦА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СЕЙЧАС САМОЕ ВРЕМЯ». 16+
22.45 «Человек - невидимка». 16+
23.40 «В ПОИСКАХ ЗОЛОТА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
4.50, 6.10 «ТЫ У МЕНЯ ОДНА». 16+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
14.00 «БАТАЛЬОН». 12+
16.25 «Леонид Дербенев. «Этот мир придуман не нами...» 12+
17.20 Гала-концерт к 90-летию со дня рождения поэта Леонида Дербенева «Между прошлым и будущим». 12+
19.10 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.00 «ТЕНЬ ЗВЕЗДЫ». 16+
23.40 «ПРЯНОСТИ И СТРАСТИ». 12+

«РОССИЯ»
5.25 «ГОСТЬЯ ИЗ ПРОШЛОГО». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.30 «СЧАСТЛИВАЯ СЕРАЯ МЫШЬ». 12+
14.30 «Я ВСЁ ПОМНЮ». 12+
17.50 «Танцы со Звёздами». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
7.45 «ДАЙТЕ ЖАЛОБНУЮ КНИГУ».
9.15 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.45 «Мы - грамотеи!»
10.25 «ДВЕНАДЦАТАЯ НОЧЬ».
11.55 Диалоги о животных.
12.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Даниил Хармс.
13.05 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
13.45 «Игра в бисер» «Василий Белов. «Лад».
14.25 Торжественное открытие фестиваля искусств в Сочи Юрия Башмета.
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.25 «Пешком...»
17.50 «Страсть уравновешенного человека».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ПАСПОРТ».
21.55 С.Прокофьев. «Золушка». Балетная сказка в редакции Рудольфа Нуриева. Постановка Парижской национальной оперы.

«НТВ»
4.50 «КОГДА Я БРОШУ ПИТЬ...» 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Маска». 12+
23.20 «Звезды сошлись». 16+

Кама Тамагы районында булган хәлне сөйләгәндә туктаусыз күпмәгънәле «сала» сүзе телгә килә. Хикмәт вакыйганың Югары Яңа Салада килеп чыгуында гына түгел, ә бәлки шушы салада яшәүче абзыйның формалы хезмәткәрләр кесәсенә акча салуы, шул сәбәпле үзен кайгыга салуы, судның аңа штраф салуы һәм башка күп кенә салу вә салмаулар турында.

Чит кесәгә акча салсаң

51 яшендәге Фәрит Вахитов ара-тирә салгаласа да артыгын тотып, башын сәрхушлеккә тыга торган кеше түгел. Соңгы җиде елда үзеннән шактый яшьрәк хатын-кыз белән яшәгән, 2016 елда уртак кызлары аваз салган, әмма узган ел февраль аенда гаилә таркалган. Ялгыз калган агай тормышын җайга салган, малларына печән салган, чиләк-чиләк сөтләр сауган, тавыкларына күкәй салган. Ләкин бар да рәткә салынмый, бигрәк тә, хатын белән кызы яшәгән йортка сукмак салынмый, чөнки әни кеше ата белән бала очрашуына каршы була, Фәрит гозеренә колак салмый.

Ир-ат 7 июнь кичендә бераз сала, әйтүенчә, литр ярым сыра эчә, иртән иртүк эшкә чума, хуҗалыгын тәртипли. Шул көнне аның элеккеге хәләл җефете Фәрит өемә килеп, яман сүзләр әйтеп сөрән салды, дип полициягә хәбәр сала. Ике хезмәткәр, Яңа Салага килеп җиткәч тә, хатын-кыз пычакка охшаган әйбер күрсәтеп шөбһәгә салды дип аңлатмага имза сала. Бу инде учакка май салуга тиң була, чөнки законда мондый гамәл үтерү белән янау дигән җинаять санала. Өстәвенә, Фәрит үзе дә пычакның сараенда икәнен әйтеп салгач, участок инспекторы Р.Нәҗмиев җинаять коралын алып конвертка сала. Аңа абзар тирәсендә йөргәндә пычранган киемнәрен салып чистаракны кияргә тәкъдим ителә, чөнки полиция бүлекчәсенә барырга кирәк була.

Әлбәттә, дөнья күргән абзый мәсьәләне уртага салып сөйләшергә, Р.Нәҗмиев белән участок инспекторлары бүлеге җитәкчесе Д.Зиновьев кесәсенә акча салып эшне җайга салмакчы була. Шул нияттән беренчесенә ун мең тәңкә акчасы булуын әйтә, өчәүләп машинада утырганда, ике бишмеңлекне алдагы утыргычлар арасына сала, тегеләрнең ошбу гамәлнең ришвәт бирү икәнен әйтеп сөйләнүләренә колак салмый, чынлыкта, алар салган ятьмәгә эләгүен сизми. Д.Зиновьев алданрак урнаштырган телефон һәрнәрсәне видеога яздырып бара, барысы да урамга чыккач машина бикләнә, ә төп дәлил эчтә кала.

Хезмәт вазифаларын үтәгән власть вәкилләренә ришвәт бирү очрагына рәсми рәвештә теркәү өчен тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Андрей Россиев килеп җитә, пүнәтәйләр алдында машинага салынган сәмәнне алырга җыена. Ләкин Ф.Вахитов ятып калганчы, салып калырга уйлый, ягъни як-ягына күз салып аулак чакны туры китерә дә, капка төбендәге эскәмиядә язып утырган юстиция подполковнигы Россиевның ян кесәсенә дә кыштырдавык кәгазьләр шудыра. Ул әйткәннәрне дә тыңламый, хәтта ошбу галәмәтне телефонына яздырып барган полиция хезмәткәрен дә күрми. Шулай итеп авыл кешесе берничә сәгать эчендә өч җинаять кылып өлгерә.

А.М.Россиев кесәсенә 5100 сум акча салынган булып чыга. Ошбу эшләрне тикшерү өчен икенче тикшерүче чакырырга туры килә. Р.Р.Абдуллин актык акчасын чыгарып салып ахырга кадәр көрәшкән 1970 елгы Ф.Вахитовка полиция хезмәткәрләре һәм тикшерүчегә ришвәт бирүдә гаепләү белдереп ике томлы җинаять эшен судка җибәрә. Хөкемдар гаебен танып, тәүбә итеп торган ир-атка 7 мең тәңкә штраф сала, ә аның 15100 сум акчасы дәүләт кесәсенә күчә.

Шулай итеп агай җәмгысе 22100 сум акчасын суга сала. Әгәр әлеге сәмәннең бер өлешен генә булса да хатыны янчыгына салса, ошбу мәшәкатьләр килеп тә чыкмас иде, мөгаен. Әлеге ыгы-зыгыга сәбәпче булган пычак белән янау мәсьәләсе тора-бара юкка чыга. Рәсми кәгазьләрдә расланмады диелсә дә, моны хатын-кыз мәрхәмәтлелек күрсәтү нәтиҗәсе дип уйларга кирәк.

Власть вәкилләре кесәсенә сәмән салу Югары Яңа Салага гына хас түгел. Күршедәге Буа районында да буа буарлык алар. 2021 елда әлеге шәһәр суды «гаишник»ларга акча төртеп хур булган дүрт шоферны бер-бер артлы хөкем итеп штраф салды. Быел гыйнвар аенда тикшерү органнары вак ришвәт төртү очраклары буенча кузгатылган тагын өч җинаять эшен хөкемдар өстәленә салды. Аларның да икесе шоферларга карата ачылган.

Шунысы күзгә ташлана, эшләре судка бирелгән шоферларның барысы да – чит төбәкләрдән килгән ир-атлар. Моның сәбәбен төрлечә фаразларга мөмкин, бары тик безнекеләр юлда акча төртми дигән нәтиҗә ясарга ярамас. Көн-төн юлда йөргән «дальнобойщик»лар кармакка җиңелрәк эләгә, күрәсең.

1962 елгы Санкт-Петербург кешесе Иван Гарбуз «Скания» машинасында Казанга килә, йөкне бушатып кире кайтып барышлый, Буа районында туктатыла. Инспектор А.Гайфуллин аңа тахограф күрсәткечләре күчермәсен алып бирергә куша. И.Гарбуз зур йөк күтәрешле машиналарның түләүле юллардан йөрүен исәпләп, димәк, моның өчен күпме акча чыгарып салырга кирәклеген күрсәткән ошбу җайланманың булмавын әйтә. Ә бу исә административ законнарны бозу санала.

Моның өчен 3-5 мең сум күләмендә штраф салу каралганын шофер үзе дә белә. Капитан Н.Мостяков патруль машинасында беркетмә төзергә җыена башлагач та, әлеге мәсьәләне үзара файдалы шартларда хәл итәргә тәкъдим итә һәм, аңгәмәдәшенең каршы килгәндәй итеп әйткән сүзләренә колак салмыйча, ике утыргыч арасына бер бишйөзлекне куя. Әлеге ришвәткә күз сала капитан, әмма әллә ни исе китмәгән кыяфәт белән машинадан чыга, аңа шофер да иярә, «Лада Веста»ның ишекләре бикләнә, ягъни төп дәлилне кире алу мөмкинлеге бетерелә.

Буадан килеп җиткән оператив хезмәткәрләр аны шаһитлар каршында ала. Бу инде И.Гарбузның кечкенә генә ришвәт биреп олы мәшәкатьле булуын күрсәтә. Тахографсыз машина йөрткән өчен административ беркетмә дә төзелү өстенә җинаять эше дә кузгатыла. Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Айрат Мөхәммәдуллин ун көннән рәсми гаепләү белдерә һәм гыйнвар аенда яңа 60 яшен тутырган Питер абзыеның эше судка җибәрелә.

Ульяновск каласында яшәүче 57 яшендәге Владимир Аридов та нәкъ шундый хурлыкка дучар була. «КамАЗ»ы белән Казанга барышлый, аның машинасының тахограф белән җиһазландырылмавы ачыклангач, шул ук Н.Мостяков беркетмә төзергә җыена. Калганы охшаш ысул белән бара. Аерма бары тик шунда, В.Аридов 500 тәңкәне ришвәт түгел, ә бәлки милиция-полиция көне уңаеннан чын күңелдән бирелгән бүләк дип атый. Чөнки вакыйга шушы бәйрәм арасында була. Әлбәттә, аның гамәле дә власть вәкилен юк бәягә сатып алырга маташу дип бәяләнә.

Таҗикстан кешесе Хөршиджан Закиров та шофер булып эшли, ләкин полиция күзенә мигрант буларак кылган хилафлыклары аркасында чалына ул. Узган ел җәендә инде Россия гражданлыгы алырга өлгергән хәләл җефете, кияүдәге кызы янына килә. Казанга пассажир транспорты оешмасына автобус йөртүче булып урнаша, Казандагы Восстание урамында вакытлы фатирда яши. Сентябрь аенда кызы белән кияве Буа районындагы Аксу авылында йорт сатып алалар.

Әйтүләренчә, ут, су, газ кертелмәгән иске өйне кышка хәтле рәткә китереп өлгермиләр, шуңа күрә яшәүче булмый анда. Аның каруы 6 кеше пропискада, шул исәптән, Таҗикстан гражданы Х.Закиров миграция исәбендә тора. Бу хәлгә участок инспекторы Равил Ларин игътибар итми калмый, ноябрь уртасында Казанда яшәүче хуҗалар белән элемтәгә кереп, ул аларны район эчке эшләр бүлегенә чакыра. 15 ноябрьдә 26 яшьлек кызы Мәдинә белән килеп төшкән Хөршидне участок инспекторлары бүлеге башлыгы Рамил Абикиев бүлмәсенә кертә.

Урта Азия кешеләре миграция кагыйдәләрен бозган, ягъни теркәлгән урында яшәмәгән өчен штраф каралганын белә, бигрәк тә, кире Таҗикстанга озатылудан куркалар. Подполковник Абикиев аларга чит ил кешеләрен ялган пропискада тоткан торак хуҗалары өчен җинаять җаваплылыгы булу турында да искәртә. Кыскасы, эшнең хөрти икәнен аңлый «кунаклар» һәм җаваплы хезмәткәрне җайлау кәсебенә керешәләр, әлбәттә, бурычлы булып калмаячакларын белдерәләр.

Шул рәвешле, Р.Абикиев эшнең кай тарафка баруын аңлый, аталы-кызлылар урамга чыгып киткәч, акча алып керәчәкләрен дә чамалый. Полиция хезмәткәрләренең өлгерлеген билгеләп үтми ярамас, чөнки шул арада кабинетка видеокамера да урнаштыралар, пүнәтәйләр дә табалар. Калганы план буенча бара. Машинадан алган «сәмән»не кыстырып, Х.Закиров килеп керә, акчаны подполковник өстәле астындагы киштәгә куя, анысы ошбу галәмәтнең законда ришвәт бирү дигән яман гамәл дип саналуы хакында әйтеп ала, яхшы кешегә җәл түгел дигән җавап ишетелә. Дустанә әңгәмәне ике шаһит иярткән кергән оперативник бүлдерә, киштәдәге 11 мең тәңкә конвертка салына. Юстиция полковнигы Дамир Әскаров 1969 елгы абзыйга карата җинаять эше кузгата.

Моннан кала, аңа карата миграция кагыйдәләрен бозган өчен административ материал да төзелә. Буа районында исәптә торып, Казанда яшәгән өчен, Мәскәү район суды аңа 2 мең тәңкә штраф салырга дигән карар чыгара, үз иленә озату мәсьәләсе телгә дә алынмый. Бактың исә, Х.Закиров ике мең тәңкә түләүдән куркып 11 меңне чыгарып салган да җинаять тә кылып куйган булып чыга.

Әлеге өч җинаять эше Буа шәһәр судында каралмаган әле. Әлбәттә, ике шофер җиңел җәза белән калдырылачак. Х.Закировны кырысрак җәза көтә. Чөнки ришвәтнең күләме 10 мең сумнан артып киткәндә, хәтта иректән мәхрүм итеп куюлары да бар. Депортацияләү куркынычы да юк түгел кебек.

Күргәнебезчә, «акча булса бар да дус та, бар да яр» дигән әйтем хаклыкка туры килеп бетми. Акча төртәм дә котылам дип тотылган кешеләр күп. Хокук саклау органнарында эшләүчеләргә вак-төяк акча алуга караганда бирүчене фаш итү кулайрак та булырга мөмкин. Чөнки бу эш күрсәткечләрен яхшыртырга, ягъни ачылган җинаятьләр санын арттырырга мөмкинлек бирә. Һәм, әлбәттә, анда сатылмый торган хезмәткәрләр дә эшләвен исәптән төшермәскә кирәк.

Наил ВАХИТОВ.

БИЕП ТОРА КҮЛМӘГЕ ДӘ...

Килешле милли күлмәктәге бу ханым – үзе бизәүче, үзе биюче! Түбән Кама районының Кама Аланы бистәсендә яшәүче Гөлнара Мәҗитова башкаруындагы татар биюенә сокланмаган кеше юк! Югыйсә ул биюче яисә хореограф булырга укымаган да. Урта мәктәпне уңышлы тәмамлауга, Гөлнара рәссамлык һөнәрен сайлап алган.

Әңгәмәдәшем – бик уңган да һәм шул ук вакытта үтә тыйнак та! «Мин Тукай районының Биклән авылында туганмын. Әтиебез Альберт гомер буе электрик хезмәтендә булды. Ә әниебез Рәзинә озак еллар сыер савучы булып хезмәт куйды. Гаиләдә без – өч кыз туган. Апам Венера хәзерге көндә Казанның иң оста тегүчеләренең берсе. Сеңлем Альмира да милли киемле курчаклар тегү белән мәшгуль. Билгеле, чигүләр чигәргә дә, тегәргә дә әниебездән үрнәк алып үстек. VII сыйныфны Биклән урта мәктәбендә укыдым. Аннары гаиләбез Кама Аланына күченде. Һәм мин шул вакыттан алып биим. Бию түгәрәкләренә дә йөрдем.

Аннан соң бистәбезнең мәшһүр «Мәхәббәт» бию студиясендә шөгыльләнә башладым. Һөнәр алу өчен Бөгелмәнең 48 нче һөнәри училищесын сайлап алдым. Училищеда ике ел гыйлем җыйгач, рәссам-бизәүче белгече дипломын алып, биредәге балалар бакчасында хезмәт куя башладым. Гаиләм бар, ирем белән ике ул үстердек. Эшем күңелемә ятә. Нәниләрне тәрбияләү хезмәте һәрчак күңелле. Бакчадагы концерт залын бәйрәмчә бизәү, балалар биюләре өчен төрледән-төрле бию кирәк-яракларын, мәсәлән, зур каләм, төсле чәчәкләрне күпләп ясау, бию киемнәрен әзерләшү – боларның барсына да житешәм, – ди Гөлнара ханым.

– Музыка җитәкчебез Тамара Андрианова белән берлектә балалар өчен бию хәрәкәтләрен төзүдә, аларны артистизмга өйрәтүдә теләп катнашам. Алар белән төрле бәйгеләргә дә барабыз. Уңышларыбыз да бар. Әйтик, былтыр XXI «Созвездие-Йолдызлык» ачык республика яшьләр эстрада сәнгате телевизион фестиваль проектында безнең «Кояшкай» бакчасына йөрүчеләрнең «Колибри» балалар ансамбле матур бию башкарып, җиңү яулап кайтты. Әлеге бәйгедә бихисап балалар катнашуын исәпкә алганда, бу – иң зур җиңүләребезнең берсе! Биюче балалар, кулларына мин ясаган күбәләкләрне тотып биеп, жюри әгъзаларын таң калдырды! Моннан кала Түбән Камада үтә торган «Музыкаль галактика» конкурсында да ун ел рәттән катнашып, төрле призлы урыннар яуладык!»

Гөлнара биюләргә гашыйк. Кама Аланында моннан унҗиде ел элек оешкан «Мәхәббәт» бию студиясен җитәкләүче Галия Гали кызы Янборисова сәләтле хатын-кызларны студиягә әйдәп тора. Бу студия аның тырышлыгы белән бихисап зур уңышларга ирешкән. «Без башта шәрык биюләренә күбрәк игътибар иттек. Хәзер инде үзбәк һәм таҗик халык биюләрен яратып биибез. Барыбыз да сәнгатькә, биюгә мөкиббән! Биюләребез өчен кирәкле баш киемнәрен, түбәтәйләрнең, калфакларның һәммәсен дә үзем тегеп бизим. Студиябезгә төрле һөнәр ияләре йөри, укытучылар, медицина хезмәткәрләре... – дип аңлатты Гөлнара Альберт кызы. – Мин татар халык биюе белән фарсы биюен башкарам. Концертларга чакырып торалар. Якын-тирәдәге авылларга да чыгабыз. Студиябез Түбән Камадагы бәйрәм чараларында: Сабантуйларда, Нәүрүз бәйрәмнәрендә дә бик актив катнаша. Үзебездәге Халыклар дуслыгы йорты тарафыннан ел саен оештырылып килгән «Халыклар дуслыгы фестивале»ндә дә чыгышлар ясарга туры килә. 2021 елның декабрендә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан Түбән Камада оештырылган зур концертта да чыгыш ясадык. Россия халыкларының традицион мәдәниятен саклау һәм үстерүгә керткән зур өлешебез өчен диплом белән бүләкләндек. Безне Казандагы «Мәдәниятләр мозаикасы» фестиваленә дә чакыралар. «И, Гөлнара, биюче һөнәренә генә укыйсың калган икән!» дигән уйлар да килгәли...»

Гөлнара ханымнан аның үтә матур, буй-сынын тагы да зифа итеп күрсәткән, татар бию костюмын ничек тегүен дә белештек! «Әлеге костюмымны үзем дә бик ошатам! Бу күлмәгем һәм калфагым өчен кирәкле, җете төсләрдәге бизәкле матур тукыманы Мәскәүдән кайтарттым. Бию костюмнарымның кайберләрен апам Венера тегеп бирә! Кайчак сеңлем Альмирадан чигүләр белән булышуын үтенәм. Минә шулай итеп һәрберебез халкыбыз мәдәнияте үсешенә үз өлешен кертә!» – дип сөйләде уңган ханым. Бию сәнгате хакында сүз чыкканда: «Биюче биюдәге үзен түгел, ә биюнең үзен яратырга тиеш», – дип искәртергә яраталар. Гөлнара ханымның бию сәнгатенә мәхәббәте инде унбиш ел дәвам итә! Шушы елларда аның биюләрен күреп сокланганнар саны да арта гына бара!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 4.03.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2742

16+